
PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2015 НОЯБРЬ № 11

СӨЕМБИКӘ

«ЯСАЛМА» БАЛАЛАР
ЭКО: миф һәм чынбарлык

БАЛА КАРАГЫ
ике юлның – берсе

АРТУР–МАРАТ ДУЭТЫ

СЫЙЛЫЙ:
бананлы торт

Гөлнара ГАРИПОВА:

«КӨНДӘЛЕКТӘГЕ «БИШЛЕ»ЛӘР ИҢ МӨҺИМЕ ТҮГЕЛ!»



PRESSA.RU



70

1945–2015

Сугыш язган хатлар

Шакирҗан ХӨСНИЕВ Буа районы Адав-Толымбай авыл советы Башкарма комитетында эш башкаручы булып эшли. Сугыш башлангач, утыз дүрт яшьлек Шакирҗан, мобилизацияләнеп, Ватанны сакларга китә. Кызылармияче Шакирҗан Хөсниев 238 нче укчы дивизиянең 509 нчы укчы полкында хезмәт итеп, Югославия башкаласы Белградка кадәр барып җитә. Ләкин, кызганычка каршы, аның гомере шушы шәһәрне азат итү өчен көрәштә — 1944 елның 19 октябрендә өзелә. Җиңү көненә чаклы нәкъ 202 көн калгач... 1944 елның 2 сентябрендә язган хаты иң соңгысы була.

«Исәнмесез барыгыз да! Сез ки илдә яшәүче әнкәйгә без ки балаң Шакирҗаннан иң беренче сагынычлы сәламнәремне язып, исәнлек теләп калам. Һәм Асия сиңа иң беренче ялкынлы сәламнәремне язып, исән яшәвеңне һәм киләчәктә бергә булуыбызны теләп калам. Шулай ук балаларым: улым Фәрит белән кызым Сәвиягә һәм улым Сәгыйтькә ялкынлы сәламнәремне язып, исән, шат һәм киләчәктә үзебезнең тәрбиядә булуларын теләп калам. Сагынычлы сәламнәрем соңында үзем әлегә исән. Һаман шул Молотов госпиталендә ятам. Бүгеннәрдә ике култык таягы белән аз гына бер аяктан йөри башладым. Алай да бик кыенлык белән. Күпме ятачагымны белмим. Менә минем хәлем шулай. Үзем 27 нче гыйнварда һәм 13 нче февральдә телеграмм суккан идем. Һәм моңа кадәр өч хат салдым. Үзем сездән бер дә җавап ала алмадым. Һич булмаса, исәнлегегез турында телеграмм сугарга иде. Минем өчен шатлык булган булыр иде. Иптәшләр телеграмм, хат алдылар. Бәлки, җибәргәнсез, мин ала алмыйм булыр. Башка язар сүзем юк. Асия, минем һаман бер сүзем булыр – балаларны тәрбиялә. Хуш, исән булыгыз барыгыз да. 20.02.1942.»

«Аягым хәзер көннән-көн алда, таяксыз йөри башладым. Монда күпме ятасын белә алмыйм. Кәмиссия аркылы үтәргә тиешбез. Шулай да, Асия, сез минем өчен хафаланмагыз... Исән булсак кайтырбыз. Әнкәй дә хәсрәтләнеп, үзен-үзе картайтмасын. Бер без генә түгел, ил белән. Без үзебез хәзер бер дә кайгырмыйбыз. Асия, менә шулай сез дә минем шикелле булыгыз. Асия, бар кадәрле икмәкләрегезне саклап тот. Үзегезнең өчен файда булыр. Госпитальдә төшкән карточкамны җибәрәм. Балаларга истәлек итеп.»

«Улым, Фәрит, үткән еллардагы кебек отличнога укы, дәресеңне калдырма һәм үзең белән беррәттән Сәвияне өйрәт. Ул да белмичә аптырамасын...»

«Сезнең барлык хатларыгызны укып бик шатланам. Чөнки алты айга якын сезнең хәбәрләрне белми идем. Хәзер бөтен эчем бушады дип әйтәсем килә. Улым, үзебезгә күлмәкләр, чалбарлар ясадык дигәнсең. Аларга мин сездән артык шатландым. Шулай булгач, әниең эшкә киткәч, йортны, терлекләрне яхшы карарсыз һәм дәресләрегезне яхшы хәзерләп укырсыз дип уйлыйм. Икенче хат язган вакытта үзегезнең шундый шатлыклы хәбәрләрегезне, илдән кемнәр киткәнне, кайтканны, колхоздагы эшләрне, кемнәр җитәкчелек иткәнне, базар бәяләрен, күпме икмәк булганны, абыеңнан хат килгәнне, әбиеңнәрнең хәлен – барысын да язарсың, дип уйлыйм. 1.04.1942.»

«Зур улым Фәрит, сиңа без ки әтиеңнән сагынычлы сәламемне язып, сәламәт булуыгызны теләп калам. Улым, әниегезгә булышыгыз һәм укыгыз, надан калмагыз. Әниеңә усал булмагыз, аны тыңлагыз. Әти исән диеп шатланыгыз. Асия, балаларым, сез мине дөньяда исән диеб белегез. Улым, исән булсам, хат салырмын тагын да. Бу хат салынды: 2.04.1944.»

(Шакирҗан ХӨСНИЕВтән килгән хатлар аның Буа районы Адав-Толымбай авылында яшәүче кызы КӘРИМОВА Сәвиядә саклана. Хатлар кыскартылып, язылу стиле үзгәртелмичә бирелә.)



Хөрмәтле укучыларыбыз! Гаиләгездә фронттан килгән хатлар саклана икән, редакциягә җибәрә аласыз. Хатларны сайтыбызда (www.syuyumbike.ru), ә иң кызыклыларын журналда бастырырбыз. Сайтыбыз аша сугыш кырларында ятып калган якыннарыгыз турында мәгълүмат таба аласыз.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2015

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Тәхвәтуллина, Розалина Шаһиева, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррире:
Сөмбел Гаффарова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Гөлнара Гарипова
Өстендәге туны – «VOZDYH» бутигы коллекциясеннән.

Фото: Гөлнара Сагиева

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Газинур Хафизов
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225x290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 10.11.2015 ел.
Заказ О-3066.
Тираж 6071.

Учредитель:
Акционерное общество «ТАТМЕДИА»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы: 73002

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



PRESSA.RU

29 НОЯБРЬ — ӘНИЛӘР КӨНЕ



Ләйсән ЮНЫСОВА

Төнге җыр

Еламачы, кызым! Балам, еламачы!
Әнә, кара, мырлап утыра соры мачы.
Ул да, ахры, балам, сине юатмакчы,
Еламачы, кызым, йокла. Еламачы.


Ә песинең күзе, кызым, шундый яшел.
Ә тизлеге, җитезлеге – инде яшен.
Уйлый бугай, сиңа карап, бәләкәчем,
Койрык белән сөртер идем, дип, күз яшен.

Ә койрыгы аның, кызым, шундый йомшак –
Ул кайчакта тиенгә дә кала охшап.
Син елмайсаң, кызым, балам, песи дә шат.
Син еласаң, ул да кала бугай каушап...

...Еламачы, кызым. Әйдә, йокла инде.
Әнә җиргә сиздермичә төн дә иңде.
Кичке шәфәкъ күптән инде сулды, шиңде,
Күк түренә түп-түгәрәк ай да менде.
Песи йоклый. Йокламаучы син дә миндер.
Йокла, кызым, йокла, балам, йокла инде.







«Мәхәббәт туганда». Виктория Егорова эше.

Харрас ӘЮП

****

Кайгырдың син, әнкәй, авырсак та,
Сызланасың – безгә авыр чакта.
Эчтән сызарыңны белеп торам,
Без ялгышып, беркөн абынсак та.

Керфек какмый чыккан төннәрең бар,
Ут йотып ла узган көннәрең бар;
Саргаясың тәрәзәдән карап –
Кай җирләрдә тагын кемнәрең бар?

Көенәсең җирдә хәсрәт барга, –
Агыласың гүя болытларда.
Тамасыңдыр көйгән иреннәргә,
Инде сулып барган минутларда...

Гаҗиз идем газап чиккәнеңә –
Чит кайгыдан яшьләр түккәнеңә.
Төшендем мин: безгә генә түгел,
Бар дөньяга ана икәнеңә!..



PRESSA.RU





БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





СҮЗ, АКБУР, КАРА ТАКТА...
Ф. Мостафина

22

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



8



ҖАНЫҢНАН ӨЗЕЛГӘНМЕ?
М. Авзалова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ



И ӨМЕТ!
Р. Камалетдинова



26

БӘБКӘЛЕ ОЯ
Г. Сафиуллина



12

30



БӘХИЛЛӘШҮ
М. Сәфәров



ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



САНДЫК — Х, Гарипова — 36

ЯШӘЕШ 



42 — **«ДӨНЬЯЛЫКТА БЕРГӘ БУЛА АЛМАДЫК...»** — Ф. Бәдамшина

46 — **БАЛА КАРАГЫ** — Л. Гәрәева



ШУЛАЙ УК: 



16 — **УҢГА КИТСӘҢ – ЭШСЕЗ КАЛЫРСЫҢ, СУЛГА КИТСӘҢ...** — А. Галиева



20 — **СӘЕР КЕШЕЛӘР** — М. Кашапова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 





60 — **ХАТЫН-КЫЗ ЙӨРӘГЕ**

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

ВАКЫТНЫ НИЧЕКЛӘР ҖИТКЕРЕРГӘ?

ПАРИЖДА ОЧРАШЫРБЫЗ! Хикәя.

«СЕРЛЕ ЙӨРӘК». Бер җыр тарихы.

ИМТИХАН. Язмыш.

ЯҢА ЕЛ ТАБЫНЫНА. Мастер-класс.



PRESSA.RU



Әнием соңгы сулышына кадәр «Азат хатын» («Сөембикә») журналыннан аерылмады. *Бик яратып укый иде. Әни укып бетергәч, безнең кулга күчә иде.*

Безне – русча гына укырга гадәтләнеп үскәннәрне туган тел белән бәйләүче бер күпер иде ул. 1952 елда әти-әнием белән без Свердлау өлкәсенең Яңа Ләлә шәһәренә килеп төпләндек. Мин шунда мәктәпне тәмамладым. Аннан соң әти безне Павлодар өлкәсенә алып китте. Иртыш буендагы «Целинный» бистәсендә яшәдек. Әтием анда парторг булып эшләде. Туган якны калдырып китүебезнең бик зур сәбәбе бар иде. Бөек Ватан сугышында катнашкан әти Җиңү көнен Венгриянең Будапешт шәһәрендә каршылый. Сугыштан 1947 елда гына кайтты ул. Анда да әле әбиебез каты авырып киткәч, Мәскәүдән рөхсәт сорап кына. Сугыштан соң Кукмарада эшләде. Сугыш турында фильмнар күрсәтсәләр, әти, дөрес күрсәтмиләр, дип ачына: «Анда җир һәм күк тоташ ут, бөтен тирә-юнь дөрләп яна иде», – ди торган иде. Аннан әтине кулга алдылар. Әнием башлангыч сыйныфларда укыта иде. Ел ярымнан соң миннән Сталин исеменә хат яздырды. Белмим, әллә шул хат ярдәм иттеме икән, әтине кайтардылар. Хәтта кабат партия сафларына да алып, Апаска ВЛКСМның район комитеты секретаре итеп чакырдылар. Әти риза булмады. Безне алып, туган илдән чыгып ук китте. Мин Апас районының Урта Балтай авылында җиденче сыйныфта укый идем. Комсомолга кергән вакытларны әле дә тыныч кына искә төшерә алмыйм. Класста комсомоллар җыелышкан. Алар алдына басып, мин үземнең биографиямне сөйлим. Директорыбыз Гыйззәтуллин Нәби абый да минем янда. Шунда бер тавыш: «Ул – халык дошманы кызы. Аны комсомолга кабул итәргә ярыймы?» – дип сорый. Нәби абый мине җилкәмнән кочып алды да: «Әтисе өчен кызы җавап бирми», – диде. Урыны җәннәттә булсын аның. Мин, кулларым белән битемне капладым да, үксеп елый-елый класстан чыгып йөгердем. 1952 елның март ае иде бу. Безнең авылдан Апаска кадәр 15 чакрым. Шунда җәяүләп барып, комсомолга кереп кайттым. Аннан инде читкә чыгып киттек.

Павлодар педагогика институтының физика-математика факультетын тәмамладым. Чирәм җирләргә килүчеләрнең балаларын укыттым. 1961 елда Башкортстан егете Кәшиф белән гаилә кордык. Бик тырыш, гаилә җанлы иде ул. Балаларыбыз Лилия белән Ренат туды. Ренат авырып киткәч, табиблар климат алыштырырга куштылар. Без Саратов өлкәсенең Балаково шәһәренә кайтып урнаштык. 39 ел мәктәптә эшләдем. Инде пенсиягә чыккач та балалар белән эшләвемне дәвам итәм – хәзер укучыларымның балаларын өйдә укытам. Олыгаеп килгән көнемдә Аллаһы Тәгалә зур сынау җибәрде: 34 яшендә улым вафат булды. Аның хәсрәтен әтисе күтәрә алмады, өч ай дигәндә ул да китеп барды. Коточкыч авыр хәл.

Туган-үскән якларымны өзелеп сагынам. Биш-ун елга бер булса да кайтып, балачагым хатирәләрен саклаган газиз урыннардан бер урап киләм. Туган илендә гомер иткән кеше – ул иң бәхетле кеше!

Римма ӘЮПОВА.
Саратов өлкәсе, Балаково шәһәре.

Безнең инәй 80 яшькә җитәрәк бакыйлыкка күчте. Үлеменә уңышсыз операция сәбәпче булды. *Аз сүзле, сабыр, бик таләпчән һәм гадел кеше иде ул.*

Мин әтине белмим. Аны сугышка озатканда әле тумаган булганмын. Заманына күрә оста гармунчы булган ул. Кичен басудан җир сөреп кайткач, чабатасын да салмыйча, баскыч төбенә утырып гармун уйный торган булган. Сугыштан кайтмады әти. Аның төсе булган гармунны инәй бер пот арышка алыштырган. Шул арыш безне ач үлемнән коткарып калган.

Инәй, ир-ат эшен үз җилкәсенә алып, бик күп еллар бригадир, ферма мөдире булып эшләде. Сөт җыючы да булды. Иртән кояш белән бергә торып, колхозчылардан 8-10 бидон сөт җыя, үгез җигеп, аны көн саен 15 чакрым ераклыктагы сөт җыю пунктына илтеп кайта. Хезмәтләре өчен түләү юк дип әйтерлек, ял көненең ни икәнен дә белмиләр. Бушлай эшләтү бер хәл, ничә төрле салым түли иде бит әле авыл халкы. Ул заем дип теңкәгә тиюләр тагын. Мал-туары бармы, юкмы, һәр хуҗалык дәүләткә елына 40-50 кг ит, 200 литр сөт, 200 йомырка, йон тапшырырга тиеш. Түли алмаучыларның сарыгын, бозавын, хәтта

сыерына кадәр алып чыгып китәләр иде.

Йорт салган елыбыз бигрәк тә истә калган. Өй салуның ние бар, мүклисе дә чутлыйсы, диләр дә бит. Алай гына булса икән! Акча җитмәгәч, өй саласы елның кышында инәй кул чанасына икешәр сарык түшкәсе салып, ике тапкыр Ижау базарында сатып кайтты. Җәяүләп 200 чакрым юл узган диген сүз бит ул. Кайткач, Красный Бор тауларына ничекләр итеп менүләрен елый-елый сөйли торган иде. Урманнан өйлек бүрәнә кисәргә рөхсәт алгач, урман каравылчысы белән икесе шул агачларны ике тәүлек буе кул пычкысы белән кисеп аударганнар. Аннары шуны 18 чакрым ераклыктан, төнлә үгез җигеп, берүзе ташыган. Без абый белән шул йортта үстек.

Хатын-кыз бәхете – пар канатлы булуда. Инәй белән әти нибарысы алты гына ел яшәп калганнар. Әтидән соң кияүгә чыкмады әни. Безнең өчен дип яшәде. Без дә инәйне бик ярата, хөрмәт итә идек. Тик тиешенчә зурлый гына алмаганбыздыр. Кичер, инәй, гафу ит!

Сугыш чоры авырлыкларын үз җилкәсендә күтәргән ул хатын-кызларга һәйкәл куярга иде дип сөйләде бер галимә телевизордан. Шул авырлыкларны күреп, шуларны кичереп үскәнгә, хәзерге тормышны оҗмахка тиңлим. Андый афәтләрне бүтән күрергә язмасын иде дип телим.

Дания БОРҺАНОВА.
Ижау шәһәре.

«Сөембикә» журналының август санынннан Асия Юнысованың «Алла бер ул» дигән мәкаләсен укыгач, кулыма каләм алырга булдым.

Мин инде пенсия яшендәге керәшен хатыны. Безгә керәшеннәр күпләп яши торган Мамадыш якларында, керәшеннәр арасында яшәү насыйп булмады. 1952 елны әтием белән әнием гел татарлар яши торган районга йорт салганнар. Гомеребез буе шунда яшәдек. Бездән башка бер генә керәшен гаиләсе дә юк иде.

Күрше балалары безне, керәшен дип кимсетеп, үртәп яшәделәр.

Мин ун ел буена саф татар мәктәбендә укыдым. Татар теле буенча олимпиадаларда катнашып, гел призлы урыннар яулый идем.

Кияүгә чыгар вакыт җитте. Татар егете белән тормыш корырга уйладык. Әмма аның әти-әнисе бер дә шатланмады. Иптәшем, мин барыбер өйләнәм, дигәч, риза булдылар. Миңа мөселман исеме биреп, никах укыттылар. Ике балабыз туды. Мулла чакыртып, икесенә дә мөселман йоласы буенча исем куштырдык. Мине белгән кешеләр шаккатты: «Нигә мондый исемнәр куйдыгыз?» – диләр. Фамилияләре – татарныкы, әтисенең исеме – чын татарча, нинди исем куярга тиеш идек соң без?! Ике балам да татар мәктәбен тәмамлады.

Инде кайнанам да исән түгел: авыр туфрагы җиңел булсын. Күптән түгел бер апа сүз ишеттерде. Кайнанам: «Кодагыйлар белән йөрешеп булмады инде. Берсе чирле булды, берсе – керәшен», – дип әйткән. Керәшен дигәне минем әнием була инде. Иптәшемә рәхмәт: 30 елдан артык бергә яшәп, авыз ачып бер генә авыр сүз әйткәне юк. Кызымны мөселман егетенә кияүгә бирдек. Мулла чакыртып, оныгыбызга чын мөселман исеме куштык. Үземнең туганнарым юк диярлек. Иремнең туганнары, кода-кодагыйларым белән бөтен мөселман кануннарын үтәп барабыз. Балаларыма, иремә әйтеп куйдым: «Үлсәм-нитсәм, мөселманча – татар зиратына күмәрсез». Ә үзем уйлап куям: «Әтием, әнием нәрсә әйтерләр иде икән?» Әнием юньләп русча сөйләшә белмәсә дә, бер мәртәбә дә чиркәүгә кергәне булмаса да, рус зиратында ята.

Пенсия акчаларымны җыеп барып, әтием белән әнием каберләрен бик әйбәтләп ясаттым. Балаларымны алып барып күрсәттем. Елына бер барып чистартсалар, бик рәхмәт.

Хәзер үземне борчыган сорауларны да язып китим әле. Бу сүзләр һәрвакыт йөрәгемә ук булып кадала. Кемнедер ачуланырга туры килсә, күпләрегез: «әй чукынчык», «әй чукынган», «чукындырасыңмыни аны» дип әйтә. Бу сүзләр – рәнҗетелгән, нахак чукындырылган керәшеннәр турында. Ачуың килгән кешене чукындырсаң, күңелгә рәхәт була микәнни?

Күңелгә тигән тагын бер әйбер бар. Шимбә, якшәмбеләрдә яңгырый торган туган көн котлауларын тыңлагыз әле. Миңсылу, Зифа, Асия әбиләрне нинди генә исемле оныклары котламый! Роксана, Радмила, Амелия, Даяна, Риана, Камиллалар... Болар барысы да татар, мөселман балаларына кушылган исемнәр. Бу оныклар да кайчан да бер әби булырлар. Олыгайгач, күпчелек халык мәчеткә, дингә тартыла. Күркәм күренеш, әлбәттә. Менә күз алдыгызга китерегез инде. Авыз ачу мәҗлесенә әбиләр җыелды, ди. Роксана, Даяна әбиләр килгән, Амелия әбине көтәләр, Коръәнне ул укырга тиеш, ди. Нигә безгә татар исемнәре куймадылар икән, безнең әниләр, әбиләр нәрсә уйлаган, дип әйтмәсләр, үпкәләмәсләрме соң бу балалар? Аларга мулла ничек итеп исем куша икән?

Хатымны укыгач, бу хатынның эчендә татарларга карата нәфрәт ята икән дип уйламагыз тагын. Килендәшләрем – алтын, кода-кодагыйларым – искиткеч кешеләр.

Инде соңгы сүз итеп хөрмәтле Асия ханымга шуны әйтәсем килә. Алла бар ул дигән уй һәркемнең күңелендә иң беренче урында булырга тиеш. Аннары – Алла бер дигән уй. Җир йөзенә төрле халыкларны чәчкән кебек, төрле диннәрне дә Алла ирештергән. Гел Алласыз, динсез яшәгәнче, Алланың бар һәм бер икәненә ышанып, үзе теләгән динне тотып, башка диндәгеләрне хурламыйча, аларга үз фикерләреңне көчләп такмыйча яшәүгә ни җитә.

Хөрмәт белән,
Нина (Наилә) апагыз КӘРИМОВА.
Әлмәт шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU



Фото интернеттан алынды



Мәдинә АВЗАЛОВА

ҖАНЫННАН ӨЗЕЛГӘНМЕ?

ТУГЫЗ АЙ УЛ СИНЕҢ БЕЛӘН... СИНЕҢ БЕЛӘН БЕРГӘ СУЛЫЙ, СИНЕ ИШЕТӘ, СИНЕҢ БЕЛӘН ЯШИ. Ә АННАРЫ...

Сентябрь урталары. Бар дөнья сары сагышта. Ул да сары сагышта. Иренең ачынып әйткән сүзләре әле һаман да колак төбендә. «Булмады инде синең белән...» Чыгып киткәндә, ул шулай диде. Әйтерсең, аның болай да кечкә эленеп торган җанын үткен пычак белән телгәлиләр. Булмады шул, булмады... Пыскып торган соңгы өмете дә сүнде. Күңелендә бушлык, караңгылык хәзер.

– Ничек яшәргә? – ди ул миннән ярдәм көткәндәй. – Юк, юк иремә һич тә үпкәләмим. Матур яшәдек, яратышып яшәдек. Алты ел сизелми дә үтеп китте әнә. Еллар узган саен, ирем һаман бер сүзне кабатлады: «Кайчан бала алып кайтабыз? Миңа бала кирәк...» Миңа кирәк түгелме, дип, бөтен дөньяга ишетелерлек итеп кычкырасы килгән чаклар күп булды. Аңа әйтмичә генә әбиләргә бардым, күренмәгән табибым калмады. Гаилә планлаштыру үзәгендә миңа, ниһаять, турысын әйтеп салдылар: «Болай тилмереп йөрмә. Син үзең бала таба алмыйсың. Табып бирсәләр генә». Миңа ул хөкем карарыдай яңгырады. Ләкин бераз вакыт үтүгә тынычландым үзе: табып бирүчеләр – суррогат әниләр турында ишеткәнем бар иде.

– Ирем белән сөйләшим әле, ул каршы килмәс, – дип ризалык биреп киттем. Соңга калдым, – дип инәлде хатын. – Ник баштарак уйламадым икән?

Республиканың күренекле репродуктологы Фирая САБИРОВА белән баласызлык, балага уза алмау проблемалары турында сөйләшә башлагач, янә суррогат әниләр агентлыгында очраткан яшь ханым искә төшеп, күңелне тырнап куя. Нигә барды икән ул анда? Кыралак әниләрдән бала таптырту өчен дә йөзәр мең акча кирәк бит.

ЭКО, кыралак әниләр турында сөйли башлавыбызга да инде күп еллар. Татарстанда экстракорпораль аталандыру ысулы моннан унбиш ел элек кулланыла башлаган булса, кыралак әниләр ярдәме 2005 елдан бирле күрсәтелә. Республикада гына түгел, илдә күренекле, иң шәп репродуктологлардан саналган әңгәмәдәшем әйтүенчә, ул җитәкләгән клиникада шушы юл белән ел саен 450–500 тирәсе бала дөньяга килә. Белмим, ни өчен Германия, Норвегия, Швеция, Франция, Австрияише үзләрен бик тә алга киткән дип санаган илләрдә баланы суррогат әниләрдән таптыруны коллыкка сатуга тиңлиләрдер? Әгәр дә бүген балага уза алмаган, алай гына да түгел, баланы карынында йөртә алу бәхетеннән мәхрүм булган хатын-кызның берсе, икесе генә булса да төшләрендә күреп саташкан шул бәхеткә – балалы булуга ирешсә дә, күп еллар буена сынатмый килгән әлеге гамәл үз-үзен аклаган дип исәпләргә булыр иде. Аннары бит ул ысул, ул чаралар тиктомалдан уйлап табылмаган. Демографик күрсәткечләрнең кинәт түбәнгә тәгәрәвен исебезгә төшерик. Эмбриология һәм репродукция мәсьәләләре белән шөгыльләнүче экспертлар раславынча, кешелекне ул хәлдән коткаруда суррогат әниләрнең дә өлеше зур.

Ләкләк чакыртабыз

Кыралак әни хезмәтен файдаланганда, бала тудыруда өч кеше: сперма биргән генетик әти, күкәй күзәнәге алынган әни һәм кыралак әни – 35 яшькәчә булган хатын-кыз катнаша. Кыралак әни баланы тугыз ай карынында йөртеп, тапканнан соң, аны шундук генетик әти-әнисе кулына тапшырырга тиеш. Тапшырырга һәм баланың барлыгы турында онытырга...

– Бала табып бирүче әниләрне сайлап алу бик җаваплы эш, – ди табиб-репродуктолог. – Безгә аларны Казандагы кыралак әниләр агентлыгы тәкъдим итә. Аннан туп-туры клиникага килүчеләр дә бар. Кыралак әниләргә җитди таләпләр куела. Аларның барысы да медицина күзәтүе уза, психик һәм эмоциональ хәле тикшерелә. Гомумән, алар һәр яктан сәламәт, иң мөһиме – аларның үзләренең балалары булырга тиеш! Бер мәртәбә дә бала тудырып карамаган хатын-кызның бала тапканнан соңгы хәлен күз алдына китерүе дә кыен. Баланы генетик әти-әнигә бирү бик кыен булачак аңа. Шуңа без «Балалы булырга тиеш!» дигән шарт куябыз. Әниләрнең кайберсе кайчак төшенкелеккә бирелә. Бала тудырганда барлыкка килгән мәхәббәт гормоннары шулай итә. Ана бөтен яратуын-назын җаныннан өзелеп төшкән сабыена бирә бит. «Бервакыт, – дип искә ала ул, – суррогат әни булырга ризалык белдергән хатыннан: «Ике малаең бар барын. Ә менә кыз туса, нишләрсең? Син аны бирергә әзерме?» – дип сорыйм. Ул моңа җавап таба алмады. Һәм без аның хезмәтеннән баш тарттык.

Еш кына ир белән хатын кыралак әнине үзе алып килә икән. «Баламны туганым күтәрсә ярыймы?» – дип мөрәҗәгать итүчеләр дә бар. Юк, ярамый. Чит кеше булса, яхшырак. Чөнки ул баланың үскәнен күрергә, аның белән аралашырга тиеш түгел. Зур күңелсезлекләр китереп чыгарырга мөмкин бу. Карап тора торгач, кыралак әнинең фикерен үзгәртеп куюы да ихтимал.

– Туганым дигәннән... – дип дәвам итә сүзен белгеч, – бала таптырырга дип, апасы сеңлесен алып килгән очракны хәтерлим. Булачак суррогат әнине УЗИга алып баргач, әйтә бу миңа: «Коткарыгыз, зинһар! Минем һич кенә дә аның баласын күтәреп йөрисем килми. Әни белән апа ирексезли», – ди. Нишлисең, янә борып җибәрдек.

Кыралак әниләр, әйткәнебезчә, 20 дән 35 яшькәчә булып, кимендә бер бала тапкан булырга һәм әгәр дә

МИФ ҺӘМ ЧЫНБАРЛЫК

ЭКО ысулы (экстракорпораль аталандыру) турында имеш-мимешләр күп йөри. Бу тирәдә йөргән төрле уйдырмаларга карата Фирая САБИРОВА түбәндәгечә аңлатма бирә.

Беренче миф: ЭКО – ул бары өлкән яшьтәге хатын-кызлар өчен генә...

Бу алай түгел. ЭКО ысулы балага уза алмаган төрле яшьтәге хатын-кызга карата кулланыла. Әйтик, яшь хатынның йөклелеге ике мәртәбә аналык көпшәсендә урнаша һәм шул сәбәпле аналык көпшәсе алына икән, экстракорпораль аталандырудан башка чара калмый. Йә булмаса, иренең спермасы начар. Бу очракта да бары ЭКО ысулы гына ярдәм итә ала.

Икенче миф: Мондый «ЭКО балалары» зәгыйфь һәм чирле туа.

– Бусы да дөрес түгел. «ЭКО балалары» башка балалардан бер яклары белән дә аерылмый. Барысы да әни кешенең йөкле чагында үзен ничек хис итүенә бәйле. Булачак әниләр белгечләрнең җитди күзәтүе астында булганга күрә, мисалга, Даун синдромы, йөрәк-кан тамырлары системасындагы үзгәрешләр табигый юл белән туучы балаларныкына караганда азрак та була әле.

Өченче миф: ЭКО – бик авыр процедура.

– Ул анестезия белән эшләнә. Мәгълүм булганча, башта булачак әнинең генетик материалы алына, шуннан соң гына әзер яралгы аналыкка куела. Түзә алмаслык авыртулар, әлбәттә, булмый.

Дүртенче миф: ... һәм һәрвакыт диярлек ике яисә өчдүрт бала туа.

– Гел шулай дип әйтә алмыйм. Әйе, нәтиҗәсе булсын өчен һәрвакыт ике яралгы утыртыла. Әгәр дә барысы да уңышлы килеп чыга икән, аның икесе дә урнашып кала.

PRESSA.RU

ирле булса, иреннән (язма рәвештә) ризалык алырга, үзе дә, ул-бу була калса, баланы ярып алуга (язма рәвештә) рөхсәт бирергә тиеш. Бу хакта «Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында»гы законда әйтелгән.

Үзе үк күкәй күзәнәкләре доноры булган хатын-кыз суррогат әни була алмый. Балага узу бары ЭКО ярдәмендә – махсус клиникаларда башкарыла. Барысы да Гаилә кодексына, федераль законга, кайбер актларга нигезләнеп эшләнә.

Бала туганда...

Казан уртасында бу кадәрле тын урам булыр икән. Менә нинди икән ул Европа дәрәҗәсе! Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов әлеге клиниканы дәүләти-хосусый партнерлыкның лаеклы үрнәге дип атады. Бездә мондый проектларны тормышка ашыру өчен бөтен мөмкинлекләр булуы хак анысы. Клиниканың төп бурычы – сыйфатлы медицина хезмәте күрсәтү. Моның өчен биредә бөтен шартлар тудырылган: камил җиһазлар, бала тудыру бүлегендә һәр әнигә аерым палаталар, бәбине суда табам дисәң, зур ваннасына кадәр бар. Һәм абруйлы, тәҗрибәле белгечләр. Ничектер гадәти түгел, бөтенләй башкача биредә. Палаталарга керергә рөхсәт итмәделәр. Бәлкем, анда суррогат әни ятадыр. Ә алар турындагы мәгълүмат сер итеп саклана. Әйтергә ярамый, күрергә бигрәк тә... Палатага башны тыгып карарга гына рөхсәт иттеләр. Койкада яткан ханым янында утыручы ирне табибы дип торам. Табиб түгел, ире икән.

– Бала туганда кыралак әни янында генетик әни дә була, – ди табиб. – Тугач та баланы генетик әни кулына бирәләр. Бу махсус шулай эшләнә. Кыралак әнинең миссиясе шуның белән тәмам. Бу аның алдан килешенеп башкарган эше генә. Шул минуттан ул тугыз ай карынында йөртеп, җаныннан өзелеп төшкән баланы онытырга тиеш. Аның каруы, ул әниләр күпме хатын-кызны бәхетле итә, хыялына ирешергә ярдәм итә.

– Безнең клиникага төрле шәһәрләрдән киләләр, – дип сөйли клиника җитәкчесе. – Мәскәүдән килгән бер парга суррогат әнине үзебез табып биргән идек. Шактый өлкән яшьтәгеләр үзләре. Хәзер миңа ике көннең берендә рәхмәт әйтеп шалтыраталар. Йә баланың фотосын җибәрәләр. Онытмыйлар.

Бүгенге көндә 5 меңгә якын пар бушлай ЭКО өчен үз чиратын көтә. Беренче омтылыштан ук йөккә уза алмаучылар да очрый икән. Алар яңабаштан чиратка баса. Ә бу – тагын ике ел вакыт дигән сүз. Чират көтәсең килми икән, 150 мең сум акча түлисең дә, ясатасың. Белгеч әйтүенчә, балага узмауның сәбәбен гел хатыннан гына эзләү дә дөрес түгел. Еш кына моңа ирләр дә гаепле була. Сперма анализы барын да уч төбендәгедәй күрсәтеп бирә. Ирләр бу хакта сөйләшергә яратмый. Алар өчен бу – ябык тема. Әмма, ничек кенә булмасын, дәваланмыйча булдыра алмыйлар.

Кыралак әни карынында яткан бәбиләр туганнан алып бер яшькәчә шушы клиниканың тәҗрибәле белгечләре күзәтүе астында була. Аның, бая әйткән бала тудыру бүлегеннән тыш, көненә 400 кеше кабул итә ала торган үз поликлиникасы, хирургия, диагностика (УЗИ, рентгенкабинет, функциональ диагностика), клиник-диагностика лабораториясе, елына 1000 циклга исәпләнгән ЭКО һәм МРТ бүлекчәсе, хәтта аптекасы бар. Бәбине биредә тапкан әниләр клиникага өйләренә кайткандай киләләр. Монда эшләүче педиатрлар аны үзара «өй клиникасы» дип йөртәләр дә. Нәни пациентлар табибка чират көткән арада, кайсы рәсем ясый, кайсы мультфильм карый. Бәбиләр өчен шунда ук ашату һәм гигиена почмагы эшләп куелган.

Шулай да... миңа – хатын-кыз, әни кеше буларак, кыралак әниләр жәл. Карынында чит бала йөртергә аларны мохтаҗлык-юклык мәҗбүр итә. Тугыз ай синең белән бергә булган, синең белән бергә сулаган, сине ишетеп яткан ул бала да җаныңнан өзеләдер бит?! Хәер, әйтә алмыйм, монысын инде кыралак әниләр генә белә, бусы инде аларның сере...

Бу очракта, аңлыйсыздыр, игезәкләр туа. Репродуктологлар иң элек әни сәламәтлеге турында кайгырта.

Бишенче миф: ЭКОдан соң хатын-кыз үзе бала тудыра алмый.

– ЭКО ысулы белән булганда да әни кеше баласын йә үзе таба, таба алмаса, баланы ярып алалар. Биредә барысы да хатын-кызның йөклелекне ничек күтәрүенә, аның анатомик үзенчәлегенә бәйле.

Алтынчы миф: ЭКОның беренчесе һәрчак уңышсыз килеп чыга.

– Тәҗрибәдән күренгәнчә, хатын-кызларның 40 проценты беренчесеннән үк авырга уза.

Җиденче миф: ЭКО — балага уза алмауны дәвалауның иң шәп ысулы.

– Бу фикер белән берәү дә бәхәсләшми. Әмма балага уза алмауның да сәбәпләре төрле. Кайчак аны дарулар белән дә дәвалап була.

Сигезенче миф: ЭКОдан соң әни кеше симерә башлый.

– Дөрес тукланса, күп ашамаса, алай булмас. Процедураның монда бер катнашы юк.

Тугызынчы миф: Хатын-кызның сәламәтлеге какшый.

– Авырга узу – ул хатын-кыз өчен зур стресс булуын онытмагыз. Әгәр дә ул йөккә узганчы да чирләп йөргән булса, аңа даими табиб күзәтүе кирәк. ЭКО бит ул балага уза алмау проблемаларын гына хәл итә...

Унынчы миф: Бу ысул белән туган балаларның 75 проценты — инвалид.

– Кабатлап әйтәм, алар башка балалардан бер яклары белән дә аерылып тормыйлар. Ә инвалид балалар ЭКО ысулы белән туучылар арасында да, табигый юл белән туучылар арасында да бар. Шунысын искәртәм: баласын ЭКО ысулы белән тапкан әни үз сәламәтлегенә игътибарлырак була.

ҖӘМГЫЯТЬ

■ **Татарстанның тарихи Болгар шәһәрендә ислам академиясе ачылды. Биредә киләчәктә Татарстан яки Россиядән генә түгел, башка илләрдән дә яшьләр килеп белем алачак. Академия көндәшлеккә сәләтле, дөньяның башка югары уку йортлары дәрәҗәсендә булачак. Бу уңайдан Истәлек билгесе бинасында «Милләт, төбәк һәм цивилизация яссылыгында мөселман дини тәгълиматы» дигән халыкара конференция оештырылды. Аның эшендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты. Халыкара конференциягә Россия мөфтиләре Тәлгать Таҗетдин, Равил Гайнетдин, Әлбир Крганов, Татарстан мөфтие Камил Сәмигуллин, Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Төркия, Сүрия, Мисыр, Дагстаннан дин галимнәре һәм әһелләре килгән иде. Ак мәчеттә Коръәнне матур итеп укырга өйрәтү курсларын ачу тантанасы үтте.**

■ **Казан Кремле янәшәсендә «Гаҗәеп Казан» велосипед маршруты ачылды. РФ мәдәният министрлыгы уздырган вело- һәм җәяүлеләр маршруты Бөтенроссия конкурсында җиңеп чыгып, 15 миллион сумлык грант откан әлеге веломаршрут иң яхшы 6 маршрутның берсе дип табылды. Ул бөҗрасыман булырга, тарихи объектлар аша узарга, шәһәр паркларына кереп чыгарга тиеш дигән төп таләпләргә җавап бирә, озынлыгы — 28 километр. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия мәдәният министры Владимир Мединский, Премьер-министр Илдар Халиков Казан Кремле, Спас манарасы, ТР Милли музее, М. Җәлил исемендәге Опера һәм балет академия театры, Казан Ратушасы, «Казан» милли мәдәният үзәге аша узган велосипед маршрутын беренче булып сынап карадылар.**





МӘДӘНИЯТ



■ Чиләбедә узган «Татар кызы-2015» Бөтенроссия конкурсы финалында Татарстан, Мари Иле, Удмуртия, Башкортстан, Пермь, Кемерово, Түбән Новгород, Томск, Төмән, Ульяновск, Чиләбедән 12 кыз катнашты. Татарстан данын яклаган Түбән Кама кызы Миләүшә Морзаханова «Иң нәфис кыз» булып тамашачы мәхәббәтен яулады: аңа 3450 кеше тавыш бирде. Миләүшәгә нәфис таҗ – чәчәкләрдән үрелгән такыя кидерделәр. Пермь краеның Барда төбәге кызы Алинә Аптукова Гран-при яулап, «Лада-Гранта» автомобиле белән бүләкләнде.

■ «Татнефть» компаниясе Әдәбият һәм сәнгать елында, моннан 10 ел элек, Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премияне булдырган иде. Беренче бүләкләр 2006 елда – шагыйрәнең 80 еллык юбилеенда тапшырылды. Бүгенге көндә әлеге премиягә барлыгы 59 иҗат әһеле лаек булды, 76 студент стипендиат булып танылды. Әлмәттә узган быелгы юбилей чарасында Ринат Батталов (Ижау), Сирень Якупова (Чаллы), Ольга Левадная (Казан) Саҗидә Сөләйманова исемендәге премия лауреатлары булдылар. Нәфисә Сабирҗанова (Әлмәт), Илдар Хәйруллин (Түбән Кама), Наил Шәрифуллин (Лениногорск) кызыксындыру премияләре белән бүләкләнде.

КОТЛЫЙБЫЗ

■ **«Сөембикә» журналының элеккеге баш мөхәррире, күренекле җәмәгать эшлеклесе, язучы һәм журналист Роза Рәхмәтулла кызы Туфитуллова юбилее уңаеннан «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале белән бүләкләнде.**



СПОРТ

■ **Казанда акробатик рок-н-ролл буенча Дөнья һәм Европа чемпионаты узды. Ярышларда Россия, Бельгия, Чехия, Молдавия, Венгрия һәм Швейцариядән килгән 600 гә якын спортчы үзен сынады. Аларның күпчелеге — 14 яшькә кадәрле үсмерләр. Ачылу тантанасында катнашкан ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Россия Президентының Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле Михаил Бабич бу спорт төрен яшь һәм перспективалы дип атадылар.**


МИГ РТ

МӘГАРИФ

■ Мәгариф һәм мәдәният өлкәсендәге татар телле интернет-проектлар арасында быел 6 нчы тапкыр «Белем җәүһәрләре» конкурсы үткәрелде. Аны «Белем.ру» интернет-белемнәр үзәге, ТР мәгариф һәм фән министрлыгы, ТР мәдәният министрлыгы һәм «Татнет»ны үстерү фонды бергәләп оештыра. Быел Татарстан, Башкортстан Республикалары, Самара, Оренбург өлкәләре шәһәр-районнарыннан 73 интернет-проект тәкъдим ителде. Җиңүчеләр 8 номинациядә ачыкланды. Алар арасында басмаларының интернет-ресурслары да бар. «Тематик ресурс – иҗади җәүһәр» номинациясендә беренче урын – «Сөембикә», икенче урын «Идел» журналына бирелде. Ә «Ялкын» журналының сайты Гран-при иясе булды.

PRESSA.RU



Фото ТР Президенты сайтыннан алынды



БӘБКӘЛЕ ОЯ

– ҮЗЕҢӘ АВЫР БУЛМАСМЫ СОҢ? ИРЕ АННАН БАРЫ БЕР ТАПКЫР ГЫНА ШУЛАЙ ДИП СОРЫЙ.

Азалия белән авырлы чакта була бу сөйләшү.
– Кыз дисәк – кызыбыз бар, ул дисәк – улыбыз бар. Бәлки, җитәр, дип әйтергә теләгәндер этиләре... Ә мин барысын да хәл иткән идем инде...



Әлмәт районының Яңа Кәшер авылында, күп балалы Раушания һәм Альберт Фазлыевларда кунакта әле мин. Зур авыл Яңа Кәшер, ләкин үзем эзләп килгән йортны табу алай кыен булмады – аларны монда һәркем белә. Биш балалы бердәнбер гаилә бит алар бу авылда!

Әңгәмәбез гел бүленә. Һәм һәрвакыт бер үк сүзләр белән:

– Әни, әнием...

Мәктәптә булган яңалыкларны, искә төшкән нинди дә булса берәр вакыйганы әйтмичә ничек түзәсең, ди? Елмаям: безнең сөйләшүгә аларның да кушыласы килә – Азалинаның, Азалиянең, Әмирнең... Шулай, бала-чагалы йортта сер тормый. Тик Раушания белән сүзебез кечкенәләр колагы өчен түгел әле.

«Әниегез үлгән...» Коточкыч бу хәбәр алар өенә иртән иртүк килеп ирешә. Әниләре Фәүзия Казанда, хастаханәдә була. Операция вакытында табиб җибәргән ялгыш әнә шулай фаҗигагә әйләнә. Кырыгы да тулмаган япь-яшь хатын мәңгелеккә күзләрен йома.

– И-и, ул көннәр... Беренче мәлдә үземне упкын каршында калган кебек хис иттем. Инде нишләргә, ничек яшәргә? Аннан үземә: «Тукта, сабыр ит, – дидем. – Кайчакта бөтенләй кечкенә балалар да ятим кала әнә, яшиләр бит. Ә мин инде эшкә урнаша алам. Димәк, энекәшемне үзем үстерә алам».

Раушаниянең урта мәктәпне тәмамлап, документларын медицина училищесына тапшырган җәе ул. Аңа әле унтугыз да тулмаган. Хыялыма бер генә адым калды, дип, канатланып йөргән мәле... Тик күрәчәкне күрми калып буламы соң?! Аның өчен барысын да язмыш үзе шулай хәл итә дә куя. 1 сентябрь көнне, башкалар студент эскәмиясенә утырганда, ул беренче тапкыр эшкә чыга. «Сөләйнефть»кә, котельныйга оператор булып.

– Ә тагын дүрт елдан әти дә мәрхүм булды. Энем Элвир белән бу дөньяда япа-ялгыз ике бөртек калдык...

Ике бөртек булганда ялгызлык читтә йөргәнен аңлыйсы көннәре исә Раушанияне алда көткән икән... Аңа кадәр әле ул әнисе үлгәндә уналты яшендә калган энекәшенә укуын тәмамларга ярдәм итә. Аның иң олы терәгенә әйләнә. Гомерлек яр итеп сайлаган кешесе белән дә башта апасын таныштыра Элвир. Кызы, улы туу шатлыкларын да аның белән бүлешә.

– Энекәшем безне ташлап киткәнгә сигез ел... Эшендә фаҗигагә тарыды, агуланды... Ике көн генә чирләп ятты. Табиблар коткарып кала алмады... Спорт белән шөгыльләнә иде, кул көрәшендә катнашып йөрде.

Ялгызлык ачысы белән бик иртә очраштым шул. Аның ни икәнен яхшы беләм... Аннан кызым Алинә туды. «Минем белән берәр нәрсә булса, ул берүзе калачак бит!» дигән уй нигәдер гел тынгы бирмәде. Шуннан... шуннан хәл иттем инде: Ходай миңа никадәр бала бирә, барысын да табачакмын. Күп булсыннар, дидем.

Киңәшләшсәк тә, безнең гаиләдә соңгы сүзне һәрвакыт ирем әйтә.

Альбертының: «Көчең җитәрме? Үзеңә авырлык килмәсме?» – диюенә дә шулай җавап бирә ул. Бу сорауга башка әйләнеп кайтмыйлар. Мәрхүм әнисенең апалары: «Бәлки җитәр?» – дип әйтеп карый, игътибар итми. («Үзем ничек дөрес дип табам, мин, гомумән, шулай яшим, бу – минем тормыш», – ди ул.)

Ә Аллаһы Тәгалә аларга өч ел саен бер бәбәй юллап тора: башта – Алинә, аннары – Алияне.







PRESSA.RU

Әмма Алия кыска гомерле булып чыга: вакытыннан алда дөньяга килә дә, ике көн генә яши. Кечкенә кызчыклары калдырган сагышны уллары Артур туып кына азрак баса. Аннан Азалияне алып кайталар. Тагын өч елдан – Азалинаны. Быел беренче сыйныфка укырга кергән бу кызга өйдә аерым мөнәсәбәт: бердәнбер энесен югалткан көннәрдә әнисе карынында шушы бала булмаса, күтәрә алмаслык хәсрәтне кичерергә Раушания кайдан көч алыр иде икән?!

Күңелем шатлыктан гына нечкәрә, балаларымны мактасалар да елыйм...

Алты ай буе елап үзәккә үткәне дә шушы Азалина була: туарга да өлгермичә шушындый олы кайгы белән очрашкач соң?! Аның шуклыкларына өйдә шуңа да хәзер дә күз йомалар. Ә оя төпчегенә – Әмиргә – тиздән биш яшь тула. Аны дөньяга китергәч, Раушаниянең үз гомере ике көн кыл өстендә тора.

– Мин үзем ул хәлләрнең берсен дә белмәдем... Ике көн реанимациядә ятканмын. Альберт ул чакта елап беткән. «Бертуктамый шалтыратам. «Бала әйбәт, ә әнисе исән каламы-юкмы, әлегә әйтә алмыйбыз», – дип кенә җавап бирделәр», – дип сөйләде соңыннан. Ничек борчылмасын, бер кочак бала бит...

Шул ук идарәгә шофер булып урнашкан Альберт белән эш урынында танышалар алар. Спорт белән шөгыльләнгән, баянда, гитарада, пианинода уйнаган егеткә гашыйк булу тиз бит ул! Хәер, кыз да төшеп калганнардан түгел: тырыш, булдыклы, үҗәт... Кавышалар. Ә яшь гаиләнең Җәлил бистәсендәге ике бүлмәле фатирны калдырып, Яңа Кәшергә яшәргә күчүләре гел көтмәгәндә кылынган гамәл.

Альбертның әбисе Мәһинур нигезе – бу йорт. Бергәләп Яңа Кәшергә кунакка кайткалап йөриләр. Берсендә әбиләре бот сөяген сындырып, урынга егыла. Алинәсе белән декрет ялында утырган Раушания шул кайтудан авылдан китеп тормый инде: ике ел буе кайнанасының кайнанасын сабый бала урынына карый. 84 яшьлек карчык кабат аякка баса, таякка таянып әкрен генә йөри башлый. Тик әбекәй сулыш юлларына салкын тиюдән мантымый. Үләренә бер сәгать кала, Раушанияне янына чакырып ала: «Кил, утыр әле яныма, – ди. Аннан аркасыннан сыйпап: – Кызым, гомергә игелек күр, ни теләсәң, барысы да кабул булсын, Ходай сиңа бала кайгысы бирмәсен», – ди. Шушы ук сүзләрне, вафатына ике ай кала, кайнатасы да әйтә аңа: «Рәхмәт яусын, син бит минем әнине тәрбияләдең, кызым», – ди.

Өлкәннәрнең фатихасын алып калу – зур нәрсә.

«Минем ярты гомер декрет ялында утырып узды», – дип көлә ул. Эшкә чыкканына ике генә ел икән әле. Раушания балалар үстергән арада, дөньялар шактый үзгәргән: аның эш урыны хәзер «Җәлилнефть»кә карый. Идарәнең химик анализлар лабораториясендә лаборант булып эшли ул бүген. «Татнефть»нең кадрлар әзерләүче үзәгендә укып кайткан. Хезмәте җаваплы! Алар алган анализларга карап нәтиҗә ясыйлар: бу урында нефть бармы, юкмы? Анализлар төрле-төрле, арадан берсен дә җиңел дип булмый: нефтьнең чагыштырмача авырлыгы, аңардагы су микъдары... Бер төрле анализда өч ай эшләгәч, икенчесенә күчәсең, аннан өченчесенә...

– Гомерлек хыялым яртылаш чынга ашты дисәм дә була: бүген өстемдә ак халат, кулымда шприц... Дәваламыйм гына...

Бер сүздән икенчесенә күчә-күчә без инде бик озак сөйләшәбез. Балалар килеп бүлдергәндә әңгә-







мәбезнең очын да югалтабыз. Тик мин бер нәрсәне бер дә онытмыйм: ул әле бер тапкыр да зарланмады! Һәм җыенмый да шикелле. Югыйсә җай чыкканда, тыңлаучы барында түгелеп калса да ярый. Маһинур әбидән калган йорт Фазлыевларның зур гаиләсе өчен күптән тарайган. Нигезе салынган йортны һаман күтәрә алмыйлар икән әле. Зур, иркен йорт булачак анысы. Моңарчы әти кешенең хезмәт хакына гына көн иткәннәр бит. Эшкә иртәләрен ирле-хатынлы чыгып китә башлагач, өйгә яңа суыткыч кайткан, кер юу машинасы...

– Дөнья малының беркайчан җиткәне юк... Мин булганына канәгать. Сиңа насыйбы барыбер сиңа керә. Булса, куанычы белән булсын. Ипотекага бер бүлмәле фатир алдык менә, аны түлибез. Фатир бурычының бер өлешен «Татнефть» тә күтәреште. Болай да ярдәм иткәләп торалар. Казанга, Президент кулыннан «Ана даны» медален алырга барганда да алар әзерләп озатты. Рәхмәт дими, ни дияргә – баштан-аяк киендерделәр.

Һәр көнне мәктәп ишеген Фазлыевларның өч баласы ачып керә. «Иң авыр чор аларны мәктәпкә әзерләү алдыннан буладыр инде, әйеме?» – дим.

– Ә мин кызларга мәктәп формасын үзем тегәм, шул коткара, – ди Раушания. – Артурга костюм тегү генә кулымнан килми, чалбарын булдырам.

Моңа кадәр мәктәптә балаларның төшке ашы өчен түләүдә ташламалар булган, бу елларда аны бетергәннәр. Алинә апасы кебек үк Азалия дә музыка мәктәбендә укый – ул да түләүле.

Чыгымнар турында сөйләүне Раушания тиз туктата.

– Безнең бакчалар бик зур, – ди ул. – Кулдан килгәннең барысын да үстерергә тырышабыз. Бик күп итеп кыяр тозладым. Азалия белән әллә никадәр салат ясадык. Кулы эшкә ятып тора аның. Токмач кисәргә дә әллә кайчан өйрәнде инде.

Бәйләү бәйләргә бик яратам. Унөч яшьтә үк өйрәнгән идем. Олы кызым мин бәйләгән кием-салымны бик күп киде. Хәзер дә сораган кешеләргә бәйләштерәм. Ничек өлгерәмме? Эштә бер сәгать көндезге ялыбыз бар – аны ничек бушка уткәрәсең? Аннан кичләрен утырам.

«Күп балалы гаиләдәге балалар башкалардан нәрсә белән аерылып тора?» – дигән сорауга җавап бирер өчен Раушаниягә уйлап торырга да кирәкмәде:

– Тырышлыклары белән. Алинәбез мәктәпне «бишле» билгеләренә генә тәмамлады. Инглиз һәм немец телләре укытучысы булырга әзерләнә. Әле Казанда бер лицейда практика узып йөри. Укытучылары шалтыратып мактады: «Балалар белән уртак тел таба белә, аларны үзенең авызына гына каратып тора», – ди. Шулай булмыйча?! Эне-сеңелләрен үстерергә әтисе белән беррәттән миңа ул да булышты бит. Азалина елак булды дигән идем инде – олы кызым белән алты айга кадәр чиратлашып аны икәү күтәреп йөрдек. Икенче әниләре кебек ул... Еракта булса да, укулары белән гел кызыксынып тора, булышырга тырыша. Дустым да, сердәшем дә ул минем. Алинә бөтен эшне белә. Аш-суны да тәмле пешерә.

Үсеп җиткәч, балаларның оядан читкә очуы табигый да бит... Бигрәк тә кыз-баланың. Әмма Раушания: «Алинәнең укырга китүен авыр кичердем, – ди. – Йөрәгемнән өзеп чыгарып җибәрдем. Күңелем бик тулганда, шигырь яза идем... Балалар гел күз алдымда, үз янымда булырга тиеш. Миңа шулай рәхәт...»

Тагын читкә киттек...

– Мактануым түгел, балаларым чыннан да тырыш. Йорт тирәсендәге эшләр менә Артур өстендә. Без, кызлар, бәрәңгене утап кына чыгабыз, ул кумә. Класс бүлмәсендә нидер эшлисе булса, укытучысы гел аны чакырта. Азалиябез «бишле»гә генә укый. Кайсы фәннән олимпиадага барасы булса да, аны җибәрәләр. Азалина да апаларыннан калышмаска тырыша. Рәсемнәрне бик матур ясый. Пластилиннан ни теләсә шуны чын сыман итеп әвәләп куя. Кызганыч, авылыбызда сәнгать мәктәбе юк. Биергә дә оста ул. Туры сүзле дә – кемне ачулансаң, шуны яклап чыга, бер туганына да сүз тидертми.

Биш бала, бишесенең дә үз холкы...

Бу йортта балалар мәктәптән кайтуга компьютер артына уен уйнарга утырмый. (Компьютер, гомумән, өстәл өстенә әтиләре рөхсәт иткәндә, дәрес әзерләргә кирәк булганда гына чыга.) Кулларында ноутбук, планшет, айпад яки айфон да күренми. Аларын – үзләре эшләп алыр. Белеп үсәләр: әтиләре белән әниләре, нәрсә генә булса да, үз көчләренә генә таяна, читтән беркайдан ярдәм көтми. Тормышта матди байлыкка ия булганчы, кеше булып калуны өстенрәк күрәләр. (Бөтен танышбелешне, туган-тумачаны шаккаттырып, Раушания әти-әнисеннән үзенә калган ике бүлмәле фатирны мәрхүм энесенең улына бүләк итә. «Ятимне сөендерәсем килде, игелеген күрсеннәр», – ди. Энесенең хатыны кабат кияүгә чыкса да, алар, якын туганнардай, аралашып яшиләр.)

– Әгәр әниең исән булса...

Раушания нәрсә әйтергә теләгәнемне аңлый.

– Мин үзем дә бу хакта еш уйланам... Укыр идем, табиб булыр идем, мөгаен. Мин бит мәктәптә яхшы укыдым, укытучыларым югары белем алмавыма хәзергәчә көенәләр. Дөрес, булган белем югалмый – балаларыма булышам.

Аның күңелендә йөргән хыяллар турында бер сөйләшкән идек инде, һәрвакыттагыча балалар бүлде:

– Яңа йортыбыз, аның янындагы бакча турында хыялланам дип әйткән идем. Тагын... китап язасым килә! Үзем турында да булыр ул, минем язмыш хакында гына түгел дә...

Гөлнур САФИУЛЛИНА

Фото: Марат Вәлиев

PRESSA.RU

УҢГА КИТСӘҢ – ӘШСЕЗ КАЛЫРСЫҢ, СУЛГА КИТСӘҢ...

ӘКИЯТЛӘРНЕҢ НӘКЪ МЕНӘ ШУЛ УРЫНЫ ДУЛКЫНЛАНЫРГА МӘҖБҮР ИТӘ ДӘ: УҢГА КИТСӘҢ НИЧЕК ТӘ, СУЛГА КИТСӘҢ? Ә ТУРЫГА ЮЛ БАРМЫ?



Язасы сүзем дә нәкъ менә шундый сайлау газабы хакында. Ничек дөрес, кайсы якка китсәң үкенмәссең, кайсы юлны сайласаң уңарсың?



Айсылу ГАЛИЕВА

Кичке «рейста»н кайтып киләбез. (Кечкенәсен – бакчадан, зурларын кичке түгәрәкләреннән кереп алу инде бу «рейс».) Машинаның арткы утыргычыннан ике балам бер-берсен уздырырга тырышып, көн яңалыкларын сөйли, дөресрәге, бер-берсен басарга тырышып кычкыра:

– Әни! Бүген математикада...

– Әни, мин беренче сөйли башладым, көтеп тор!..

11 сәгать күрешмәгәч, яңалыклары күп җыелган. Өстәвенә, янымда, алда утырып барган кечкенәсе, руль тоткан кулга ябышып, тарткалый башлый: «Әни-и-и...» артта утырган абый-апасына елый-елый, мин сөйлим, минем чират дип кычкырырга да өлгерә. Ике вариант: йә машинадагы радионы бөтен көченә кабызып куярга, йә өчесеннән дә катырак итеп кычкыра башларга. Икесенең дә дөрес түгелен беләм белүен... Кечкенәләргә – 2-3-4 яшьлекләргә – әнинең мәхәббәтен, игътибарын тояр өчен көненә 40 минут вакытны үзенә багышлау кирәк икән. Психологлар шулай ди. Эштән чабып кайтып кергәч, кайсын мәктәптән, кайсын балалар бакчасыннан җыйгач, бу 40 минутны кайчан табып була икән, әле бит кичкелек ризык ашарга әзерлисе, дәресләр карыйсы, иртәнгә киемнәр хәстәрләп куясы... Әни өйдә генә торса, бала тәрбияләү белән генә мәшгуль булса, әйбәт инде ул. Өй дә ялт иткән, балалар да караулы. Ләкин аның кире ягы да бар шул, ул да булса, өй тавыгына әйләнгән әнинең балалар алдында абруе төшү. Сүзебез ул хакта түгел, ә нәкъ менә эшләүче әниләрнең балалар белән мөнәсәбәтләрендә нинди проблемалар килеп чыгу ихтималы, алардан чыгу юллары турында.

Эшем иясе әниләрне шартлы рәвештә ике төргә бүлергә мөмкин: беренчесе – башка чара булмаганга күрә тормышны алып бару өчен эшләүчеләр, икенче төр – бала тәрбияләүдән качып, куна-төнә эштә ятучылар. Улым йөреп алган балалар бакчасында андый әтиәниләр дә бар иде: өйдә утырган яшь ханым, 3 һәм 5 яшьлек балаларын тыңлата алмагач, бакча ябылганда гына алып китә торган иде. Икенче бер күргәндә, эшкә чыкканын, тәүлегенә 12-14 сәгать эшләгәнен әйтеп мактанды. «Ә кызларың?» – «Әтиләре белән ныграк дус алар. Ул алырга да өлгерә». – «Кызларыңны ычкындырам дип курыкмыйсыңмы?» – «Үсә-үсә үзгәрерләр әле, хәзер миңа авыр алар белән...»

Менә шундый сөйләшү. Үсә-үсә, кечкенәдән әтиәнисеннән ераклаштырылган бала якыная алмый бит инде ул. Нишләргә соң? Юлда яткан тырма маңгайга бәрмәсен өчен бүгеннән ни эшләп була? Эшләп тә, балаларга җитәрлек игътибар, тәрбия биреп тә буламы? (Ярый ла ул әниләребез яшь вакытта, без бәләкәй чакта кинолар да, мәктәп тә, күрше-тирә дә, бер таныш булмаган кешеләр дә тәрбияле иде. Хәзер ул система эшләми, тәрбия бары тик гаилә тәрбиясенә генә кайтып кала. Чит балаларга кисәтү ясап кара – ишетмәгәнеңне ишетерсең, күрмәгәнеңне күрерсең.) Без тәрбияли алмасак, баланы кем үз кулына ала – ТВмы, интернетмы, чит-ятлармы, әллә үз яшьтәшләреме? Һәм бала алардан нәрсәгә өйрәнә? Балаңа бүленгән вакыт җитәрлек булмаса, киләчәктә нинди тормыш сценарийлары көтә – педагог-психолог, үзе дә җиденче сыйныфта укучы баланың әнисе Алена Федосова белән шул хакта сөйләштек.

БАЛА ҮЗ-ҮЗЕНӘ ЫШАНМЫЙ ТОРГАН БУЛЫП ҮСӘ. Үз-үзеңә ышаныч – әти-әнигә булган ышаныч, аларның чын-чынлап терәк, таяныч икәненә ышану аркылы формалаша. Үзенә ышанычы булмаган баланың бернәрсәгә дә күңеле үсми, булдыра алмам дип курка. Өйдәгеләр «булдыра алмыйсың», «кулыңнан килми» дип тә кабатларга яратса, бөтенләй кулы эш белми торган булып үсәргә мөмкин әле ул. Алай гына да түгел, үсмерлек чорында «мин шундый уңмаган инде», «миннән нәрсә көтәсең соң», «мин аңгыра инде», дип, тискәре сыйфатларын купайтып күрсәтә. 11 яшьлек Алисә кул эшләрен, кәгазь белән, сәйлән белән эшләргә ярата. Үзе тотына алмый шуңа. «Мин эшли алмыйм», «минем кулым кәкре», «эшләп күрсәт инде» – зурлардан берәрсе белән тотынмаса, ул аны башлап җибәрә алмый. Күрсәтеп биргәннән соң гына, күз-колак булып торсалар, ахырына кадәр җиткерергә мөмкин. Шулай итеп башланган да ташланган эшләре арасында бисер агачы да, чигелгән сумка да, квиллинг ысулы белән ясалган картинасы да бар. Нишләп шулай? Вакытында үзе эшли башлап та, килеп чыкмагач, ярдәм сораганда әнисе, булышасы урында, кулыңнан килмәгәч тотынмаска кирәк иде, дип ачуланганга күрә. 6-7 яшьлек баланыкы гына түгел, үзебезнеке дә килеп чыкмый бит әле.

Балачакта әле әти-әнинең абруе көчле булса да, үсмерчакта ул барлыкка килә алмый инде, шуңа күрә, һичьюгы дәрес караганда, берәр фәннән эксперт буларак (физиканы, математиканы әйбәт беләсең, ди) абруй казанырга була. Аңламаган җирләрне әйтеп җибәреп, аңлатып. Бала әти-әнинең нәкъ менә бу өлкәдә башкалардан көчлерәк икәнен белергә, аның таяныч буласын аңларга тиеш.

АРАЛАШУДАГЫ ПРОБЛЕМАЛАР. Яшьтәшләр, олылар, укытучылар белән... баланың йә аралашу тәҗрибәсе булмый, йә мәктәптә, тирә-юньдәгеләр белән аралаша белми. Әйтик, Илнур икенче класста укый, шаян, тиктормас малай үзе, тик исәнләшә белми инде! Очрашкан саен, исәнләшергә өйрәтәм үзен. Әнисе белән булганда, әнисе исәнләшә дә, Илнур дәшми тора, үзе генә булганда да авыз ачарга оныта. Тырыша торгач, ул өлгергәнче үзем беренче исәнләшә-исәнләшә, өйрәнде, ахрысы. Беркөнне мәктәптән кайтып килешли, юл аркылы ук кычкыра: «Исәнмесе-е-е-е-з!» – ди. Мәктәптә беренче сыйныф кызлары сыйныфташ малайлары Наилнең сүгенүеннән зарлана. Әти-әнисе бер-берсе белән кычкырышып, сүгенеп кенә аралашканын ишеткән малай шундый мөнәсәбәтне аралашу моделе итеп алган да, мәктәптә, урамда да шуны куа. Сыйныфташлары да, укытучысы да кисәтү ясый-ясый, орыша-орыша хәзер Наилне сөйләшергә өйрәтәләр. Шулай да була: өйдәгеләрнең сөйләшергә, аралашу күнекмәләре бирергә вакыты булмаганга, бала телевизорга, виртуаль дөньяга кереп китә, шундагы аралашу моделен үзләштерә, йә бөтенләй үз эченә бикләнә. Баш мие әзер мәгълүматны гына кабул итеп, уйлаудан, фикерләүдән бизә башлый. Социаль челтәрләр ерак аралардан аралашыр өчен уйлап табылса, безнең балалар янәшә сыйныфтагы, йә сыйныфның икенче почмагында утыра торган дуслары белән интернет аша аралаша – сөйләм теле бөтенләй кулланылмый. Көндәлек тормышта да игътибар итәм: озын-озаклап сөйләшеп утырганчы, ватцаптан үзеңә кирәкле мәгълүматны юллау, кыска гына җөмлә язып җибәрү күпкә җиңелрәк тоела башлады.

УКУ БЕЛӘН БӘЙЛЕ КЫЕНЛЫКЛАР. Үз ихтыярына куелган бала авырлыклар белән көрәшә белми. Ул аларны җиңәргә өйрәнмәгән. Әни өйдә юк – әни берни дә сорамый – берни дә эшләргә кирәк түгел. Кирәк булмагач, эшләми дә инде ул аны. Өй эшеңне эшлә, дип әйтә әни, ә кайткач тикшерергә вакыты юк. Вакытында үзләштерми калгач, үсә-үсә катлаулылана барган мәктәп программасы аңлашылмый да. Беренче класста алган иң беренче «икеле»мне хәтерлим. Бирелгәнне язарга онытып барган өчен Лилия апа куйган иде аны. Дәфтәрне алып кайттым да шкаф астына яшердем. Әнигә, югалган, дип алдадым. Бәләкәй генә авылда беленми каламы инде ул?! Әнидән дә, әтидән дә эләкте шикелле. Шул ыржаеп торган кызыл «икеле» әле дә күз алдында тора. Хәзер беренче сыйныфларга билге куймыйлар. Алай гына да түгел, өй эше дә бирергә тиеш түгелләр. Һәм алай гына түгел, мәктәптә эшләп бетермәгәнне өйдә эшләргә кушып җибәргән өчен (ә бит тиеш түгел!) әниләр зар елый. Еламас иде – баланы түгел, үзен җәлли – ул бала белән утырырга да кирәк бит.

PRESSA.RU

Вакытында дәрес әзерләп, мәктәптә үткәнен беркетеп куярга өйрәнмәгән, өстәвенә, әнисенең канәгатьсезлеген ишетеп торган бала нишли инде? Ничек тә дәрес әзерләүдән качарга тырыша. Нәтиҗәсе – өлкәнрәк сыйныфларда начаррак укый башлый. Башлангыч сыйныф укытучылары килешер: дәресне бала белән бергә әзерләргә кирәк. Әйтеп-күрсәтеп җибәрер өчен генә түгел, гадәткә кертер, дәрес әзерләү күнекмәсен булдырыр өчен. Башлангычта гына түгел, бишенче класста да бала белән утырырга иренмәсәң, аннары инде дәрес әзерләүгә бала җаваплы карый башлый.

БАЛА БӘЙЛЕЛЕККӘ ТИЗ ТӨШӘ. Компьютердан, уеннардан, социаль челтәрләрдән, телевизордан, ахыр чиктә, наркотиклардан... Бәйлелек – тормыштагы кыенлыклардан качу юлы. Тормыш – үзе кыенлык бит ул, нәрсәдер эшләргә, ниндидер бурычларны тормышка ашырырга, ни өчендер җавап биререгә кирәк. Бала үзе сайлаган дөньяга кереп бата да аннан чыга алмый. Без сабыебызның яше тулганчы ук тоттыра торган планшет та булырга мөмкин ул, бик кызык дип күрсәтә торган балалар мультигы да. Җиңел бит – баланың игътибарын җәлеп итәбез дә, үзебез башка эш белән шөгыльләнәбез. Ашарга әзерләүме ул, җыештырумы, телефоннан сөйләшүме – мөһим түгел. Бала белән утырып уйнарга, артыннан тагын бер кат юасыңны белеп, аңа да чүпрәк тоттырырга, идәнне тутырып бетерәсен белә торып, он белән уйнатырга бөтен әнинең дә сабырлыгы җитмидер шул. Ә балада бу вакытта әнигә булышу, өйдә эшләү күнекмәләре барлыкка килер иде. Планшет тотып утырганында күнекмәләр барлыкка килә – ләкин инде башка күнекмәләр. Харис абый белән Зәйнәп апа мин белә-белгәннән бирле көннәр буе эштә булдылар. Төзелештә эшләгән кешеләр – объект тапшырганда куна-төнә яталар иде. Кечкенә улларын каршы алу, ашату-эчертү, дәрес әзерләтү кызлары өстендә иде. Ул кияүгә чыккач, 13 яшьлек Руслан үз ихтыярында калды. Малай зур инде, мәктәптән үзе кайта, ашарга әзер, өй эшләрен карый, дип тынычланган әнисе өч ел узгач кына улларының наркотиклар белән шаяра башлавын белгән. Анда да чаң сукмаган, төзәлер-төзәлер, дип, әтиләреннән яшереп, малайны сазлыкка тагын да этәргән. Нәтиҗәсе: Руслан – передозировкадан, әниләре – аның кайгысыннан. Икесе ике зиратта ята. Кызганычка каршы, бу очрак беренчесе дә, соңгысы да түгел, наркотиклар урынында секталар да, оешкан җинаятьчелек төркемнәре дә, тагын әллә нәрсәләр дә булырга мөмкин. 6 яшьлек Самат белән сөйләшәбез: «Аракы эчеп карыйсың да, аннары авырый башлыйсың, – дип фикерли ул. – Башта аз гына эчеп карыйлар, аннары тагын, тагын... Аннары аннан башка тора алмыйлар. Аракы баш миендәге күзәнәкләрне үтерә башлый. Аннары кеше үзе үлә. Ә нишләп телевизордан 11 яшьлек алкоголикны күрсәтәләр? Аңа беркем дә әйтмәгәнмени соң?» Менә бу – балалар логикасы. Белми эчкән бит ул аракыны! Ник белми соң ул аны? Әти-әнисе әйтмәгән, аның белән ул хакта сөйләшмәгән, гомумән, алар эшли, аларның балалары белән сөйләшеп утырырга вакытлары булмаган!

Эштән аерылып булмый икән, әни балаларга дигән вакытны башка нәрсәләрне корбан итү бәрабәренә бүлә инде. Бергәләп утырып дәрес әзерлибез дә, бергәләп бәлеш пешерәбез, бергәләп кунакка барабыз да, аннары бергәләп бакчада эшлибез, өй җыештырабыз. Болай булганда, бала алырга гына түгел, бирергә дә өйрәнер, үз вазыйфаларына да җаваплы карый башлар. Иң мөһиме: ул әнисенең яратуын белеп торырга тиеш.

Әлеге проблемаларның барысының да нигезендә балалар белән контакт булмау, алар белән сөйләшергә вакыт таба алмау ята. Бүген мин балаларга кирәк, алар миңа яңалыкларын җиткерә, һәр адымнарын сөйләргә әзер тора, һәр гамәленә минем бәяне, фикерне белергә тели. Бүген аларга җавап бирә алмасам, гамәлләрен бәяли алмасам, иртәгә аларның минем белән уртаклашыр яңалыклары булмаячак. Алай гына да түгел, миннән – әнидән, әтидән көткән мөнәсәбәтне алар башкалардан эзләячәк. Ә ул башкалар кем булыр?

КИҢӘШ



- Көнегезне алдан ук планлаштырыгыз. «Таулар күчерергә» ашыкмагыз, вакыттан һәм мөмкинлекләрдән дөрес файдаланыгыз. Иң элек нәрсәгә игътибар итәргә кирәген чамалап, мөһим һәм кичектергесез эшләрне исемлекнең башына ук язып куегыз, ә вак-төяк саналганнарын башка көнгә калдырсагыз да була.
- Бөтен эшеңне ташлап, гел бала янында гына утырырга димәгән. Балаларны өй эшләренә тартыгыз. Бергәләп нидер эшләү мультфильм карауга караганда күпкә файдалырак. Балалар үзләре үк нәрсәгә дә булса өйрәтүне сорап килә. Бергәләп ашарга әзерләгез, агач-куаклар утыртыгыз, кош-кортлар карагыз, кул эшләре белән шөгыльләнегез.
- Эш күплекне һәм аруны сылтау итеп, баланы игътибардан читтә калдырмагыз. Кибеткә барганда да аралашып була. Балаларны үзегез белән алып йөрегез. Дусларыгызның балалары белән аралашсыннар, бергә уйнасыннар.
- Гаиләнең үз традицияләрен булдырыгыз. Шимбәдә бәйрәм табыны әзерләсәгез, чәршәмбене өстәл уеннары көне итегез, якшәмбедә киного, походка барыгыз. Болар гаиләне якынайта. Табигатькә чыгулар да бик ошый аларга.
- Көн дәвамында балагызның хәлен сорашып, яңалыкларын белешеп торыгыз. Командировкада йә башка шәһәрдә кунакта булсагыз, кичен телефон яки Скайп аша элемтәгә керегез. Көннең ничек үтүе турында сөйләшегез, тыныч йокы теләп саубуллашыгыз. Бала ничә яшьтә генә булса да, җан җылысына, әти-әни яратуына мохтаҗ.

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!
Сезгә тәкъдим иткән сорауларга җавап бирүдә катнашуыгызны көтәбез. Алар яраткан журналыбызны тагын да баерак, кызыклырак чыгарырга ярдәм итәчәк!

Җаваплар арасыннан үзегезгә туры килгәнен сайлап алып билгеләгез яки буш урынга өстәп языгыз. Сезнең һәр фикерегез, теләк-тәкъдимегез безнең өчен бик кадерле! Тәнкыйть сүзләрен тыңларга да әзер без.



УКУЧЫ АНКЕТАСЫ




*** АНОНИМЛЫКНЫ ГАРАНТИЯЛИБЕЗ!**

Сораштыру нәтиҗәләре гомумиләштереп файдаланылачак.

1. Яшегез ____________________

2. Үзегез турында:
- ☐ ир-ат
- ☐ хатын-кыз

3. Кайда, кем булып эшлисез:
- ☐ хуҗабикә (яки бала белән декрет ялында утырам)
- ☐ эшче
- ☐ сатучы
- ☐ укытучы
- ☐ менеджер, белгеч, хезмәткәр, администратор
- ☐ урта буын җитәкче (урынбасар, бүлек мөдире)
- ☐ предприятие, оешма җитәкчесе
- ☐ эшсез
- ☐ пенсионер
- ☐ студент, укучы
- ☐ башка ____________________

4. Гаиләгезнең кереме (бер айга бер кешегә исәпләгәндә)
- ☐ 15 меңнән азрак
- ☐ 15-30 мең сум
- ☐ 30-50 мең сум
- ☐ 50 меңнән күбрәк

5. Гаиләгез зурмы:
- ☐ 1 кеше
- ☐ 2 кеше
- ☐ 3-4 кеше
- ☐ 5 һәм аннан да күбрәк кеше

6. Яшәгән урыныгыз ____________________

7. Соңгы вакытта укыган китапларның кайсысын ошаттыгыз ____________________

- ☐ кызганычка каршы, соңгы вакытта китап укыганым юк

8. «Сөембикә»дән башка тагын нинди дә булса журналлар укыйсызмы
- ☐ укымыйм (11 нче сорауга күчегез)
- ☐ укыйм

9. Ни өчен нәкъ менә шул журналларны:
- ☐ алар минем кулга бушлай эләгә
- ☐ алар миңа кызык
- ☐ мәҗбүрмен (эштә кушалар)
- ☐ башка ____________________

10. Даими танышып бара торган газета-журналлар сезгә ничек килеп эләгә:
- ☐ өйдә яздырып алабыз
- ☐ эш урынында алдырабыз
- ☐ сатып алам
- ☐ бушлай таратыла торган урыннардан алам
- ☐ башкалардан укырга алып торам
- ☐ башка ____________________

11. «Сөембикә» журналын даими укып барасызмы
- ☐ почта аша яздырып алдырам
- ☐ кулга эләккәндә укыйм
- ☐ һәр санын сатып алам
- ☐ танышларымнан, туганнардан укырга алып торам
- ☐ китапханәдән алып укыйм
- ☐ башка ____________________

12. «Сөембикә» белән танышлыгыгыз күптәнме ____________________

13. Сездән кала, өегезгә килгән «Сөембикә»нең һәр санын тагын кемнәр укый
- ☐ ирем/хатыным
- ☐ балалар ____________ кеше
- ☐ туганнар ____________ кеше
- ☐ күршеләр ____________ кеше
- ☐ хезмәттәшләр ____________ кеше

14. Кайсы рубрика һәм темаларны журналдан яратып укыйсыз? Соңгы бер елда дөнья күргән язмаларның кайсылары аеруча ошады, истә калды ____________________

15. Соңгы өч елда журнал үзгәрдеме
- ☐ бизәлеше матурланды, дизайны яхшы якка үзгәрде
- ☐ язмаларның эчтәлеге кызыклырак
- ☐ үзгәреш сизмәдем
- ☐ җавап бирергә авырсынам
- ☐ башка ____________________

16. Журналда язмаларны бер үк журналистлар язуга ничек карыйсыз
- ☐ уңай карыйм, алар инде күптәнге танышларым кебек якын
- ☐ уңай карыйм, аларның язуы миңа ошый
- ☐ моңа игътибар иткәнем юк
- ☐ ошамый
- ☐ җавап бирергә авырсынам

17. Журналыбызда нәрсәне үзгәртер идегез ____________________

18. «Сөембикә» өчен нинди кызыклы тема тәкъдим итә аласыз ____________________

Әгәр сез тәкъдим иткән тема күпчелеккә дә кызыклы тоела һәм күбрәк тавыш җыя икән, сезне БҮЛӘК көтә!

Җиңүчеләр журналыбызның сайтында онлайн-тавыш бирү юлы белән ачыкланачак.

БӘЙГЕДӘ КАТНАШУ ӨЧЕН 15 декабрьгә кадәр редакциягә:

< тутырылган анкетаны

< фоторәсемегезне

< киләсе яртыеллыкка журналга язылу турындагы квитанция күчермәсен җибәрегез.

Игътибар: 3-13 декабрьдә «Сөембикә»гә почта бүлекләрендә ташлама белән язылу мөмкинлеге булачак!



Исегезгә төшерәбез, хәзер «Сөембикә»гә журналның сайтында да syuyumbike.ru язылырга мөмкин. Моның өчен «онлайн-язылу» бүлегенә керәсез һәм андагы таблицадан үзегезгә кирәк вариантны — кәгазь яки электрон версияне сайлыйсыз.

PRESSA.RU



ШИЗОФРЕНИЯ... БУ ЧИР БИК КҮПЛӘР ӨЧЕН ХӨКЕМ КАРАРЫДАЙ ЯҢГЫРЫЙ.

Чит-ят тоелган күренешләр, билгесез әйберләр безне һәрчак әнә шулай куркыта, сәбәбе булмаса да, сагаерга мәҗбүр итә. Академик В. М. Бехтерев исемендәге Республика клиник-психиатрия хастаханәсенең амбулатор-поликлиник психотерапия бүлеге мөдире, Татарстан Республикасының атказанган табибы Гомәр Мәхмүт улы ЗИАТДИНОВның: «Шизофрения диагнозлы кешене җәмгыять авыр кабул итә», – дигән фикере белән килешәм...

Мәдинә
КАШАПОВА

СӘЕР КЕШЕЛӘР

Кем дип кенә һәм ничек кенә атамыйлар андыйларны. «Түбәсе кыйшайган», «авышкан», «дивана»... Юк, алар дивана түгел: күп вакыт алар укымышлы, акыллы һәм бик тә нечкә күңелле кешеләр. Үтә сизгерлек, йөрәгенә барысын да якын кабул итү какшата да бугай аларның психикасын. Мондый авырулар төркеменә керүчеләр арасында сәнгать һәм фән өлкәләрендә җитди уңышларга ирешкән дөньякүләм талантлы шәхесләр барлыгын да онытмыйк: А. Эйнштейн, В. Ван Гог, Ф. Кафка, В. Нежинский, М. Врубель һәм башка күп кенә исемнәре дөньяга таныш галимнәр, язучылар, рәссамнар шушы чирдән җәфаланган. Бу чирне белгечләр геннар буенча нәселдән-нәселгә күчә торган чир дип атый. Бүгенге көндә психиатриянең һәр яктан өйрәнелергә тиешле төп проблемаларының берсе дә – шул. Кайчандыр инглиз галимнәре тәкъдим иткән кешелек нәселен яхшырту-яңарту турындагы тәгълиматны Гитлер да файдаланган. Ул психик авырулар ята торган хастаханәләрне юк иткән. Тик моңа карап кына акылга зәгыйфь булган кешеләрнең саны кимемәгән.

– Бүген дөньяда яшәүче халыкның 1 проценты – шизофрениклар, – дип дәвам итә сүзен психиатр. – Бу чирне башкача, «психиатрия патшасы» дип тә йөртәләр. Хәзер җир шарында, нинди расадан, милләттән булуына карамастан, 45 миллион шизофрения белән авыручы кеше бар. Әле бүген дә моңа анык кына җавап алган юк. Әмма без аның хромосомалар авыруы икәнен, чирнең нәселдән-нәселгә күчеп йөрүен беләбез. Без – шушы фикерне алга сөрүче немец псхиатрларының тарафдарлары. Шизофренияне башка кереп утырган «бәйләнчек» уйлар белән дә бутыйлар, – ди Гомәр Мәхмүтович. – Бу – шизофрения түгел, моны төзәтергә, дәваларга була.

Күзенә күренә, тавышлар ишетелә...

– Нәселдән килсә дә, чирне кулдан ычкындырмаска, вакытында кисәтеп торырга була лабаса. Аның беренче билгеләре нинди соң?

– Кеше үзен бик сәер хис итә башлый: еш кына аңа хәле беткән, эче пошкан шикелле тоела, ул гел күңелсез. Тора-бара бу чир яңа төсмерләргә күчә: әйтик, күзенә күренә (без аны галлюцинация дип атыйбыз), колагына чит-ят тавышлар ишетелә. Беренче билгеләре күренә башлаганда, пациент үзе килә. Ә инде менә ул азып китеп, яңа форма алса, саташуларга күчсә, кеше хастаханәгә үзе теләп килми. Чөнки ул инде авыруын таныр хәлдән узган. Монда инде туганнарының, якыннарының ярдәме кирәк. Саташу, галлюцинацияләр кешене шәхес буларак нык үзгәртә. Ул, әйткәнемчә, үзен сәер тота, үз эченә бикләнә, ул мәгънәсез, башкалар фикеренчә, башка сыймаслык гамәлләр кыла. Сөйләп торган җиреннән кинәт кенә туктап кала, әйтерсең, нәрсәгәдер колак сала.

Көтмәгәндә көлеп җибәрә йә йөзенә курку, кайгылы кыяфәт чыгара, игътибарын бер генә темага юнәлтә алмый. Аның кызыксыну даирәсе дә үзгәрә: яңа, гайре табигый кызыксынулары барлыкка килә. Кайчак бу шикле фәлсәфи яки дини тәгълимат булырга мөмкин. Авыруның эшкә сәләте кими, социаль адаптацияне авыр кичерә. Ә кайвакыт тормыш белән кызыксынуын югалта.

Шулай итеп, шизофрения, белгеч әйтүенчә, колакка ишетелгән тавышлар, пассивлык, фикерләрнең өзек-өзек булуы, фикеренең «минеке түгел, ә аны минем башка кемдер салды», «мин ач түгел, ә мине ач торырга мәҗбүр итәләр» кебегрәк күренешләр күзәтелә. «Мин» һәм «мин түгел» арасындагы чикләр бозыла.

Чирнең килеп чыгышы турында төрле фикерләр йөри. Аның берсен (психиатрлар да шул фикердә) инде беләбез: бу – генетик фактор. Әгәр дә әлеге чир белән ата-ананың берсе авырый икән, ул балага да (11,8 процент) яный. Ә инде икесе дә авырый икән, бу сан 25–40 процентка һәм аннан да югарыга җитә.

Саташканмы әллә...

Хыялый идеяләр бөтен аңны-акылны биләп ала, авыру чынбарлыкка туры килмәгән әйберләргә ышана. Бу очракта чирне дәвалап булмый. Андый кешене «алай түгел, болай ул» дип ышандыруның тискәре нәтиҗә бирүе бар. Авыру әйткән сүзенең дөреслегенә тагын бер кат инаначак кына. Мондый төр пациентларга гел аларны кемдер күзәтә, туктаусыз ээзәрлекли, мәкерле эшләр майтара, теге дөньяның кара көчләре тәэсир итә, сихерли-боза шикелле тоела. Еш кына ул бу проблемаларның килеп чыгуын туганнарыннан күрә. Чирле кеше бу хакта төрле инстанцияләргә, шул исәптән, полициягә дә, редакциягә дә шикаять язарга мөмкин. Өлкән яшьтәгеләргә исә күршеләре үзе югында әйберен урлый, ризыгына агу сибә, фатирыннан куып чыгарырга маташа сыман тоела. Үзен шулай сәер тоткан кешенең психик авыру икәнлеген күрү-аңлау читен түгел. Дөрес, чынбарлыкка туры килгән саташулар да булырга мөмкин. Әйтик, пациент бизнес буенча партнерының аны үтерергә теләвен, фатирында сөйләшкәнне тыңлый торган җайланмалар куелганлыгын әйтә. Озак вакытлар янәшәдәгеләр аның авыру икәнлеген сизми. Депрессия-саташу өянәге килгәндә, кеше үз-үзенә генә түгел, гаиләсендәге бөтен кешегә, шул исәптән балаларына да кул салырга мөмкин.

Шизофрениядән дәвалану турында кызыксына башлыйм да, Гомәр Мәхмүтович мине шундук бүлдерә: «Дарулар күп. Әмма алар сихәтләнүнең бердәнбер чарасы түгел, – ди ул. – Моннан тыш, психотерапия, социаль терапия, социаль адаптация, социаль тернәкләндерү дә бик мөһим. Психик авыруы булган теләсә кемне хастаханәдә тота алмыйбыз. Безнең законнар алай эшләргә кушмый. Аларны сәламәтлеге начарайганда, йә инде әйләнә-тирәдәгеләргә зыян китерү ихтималы булганда гына сала алабыз. Бу чирне кисәтү – стрессларга каршы көрәшү аеруча мөһим. Адәм баласы һәрвакыт үзенә: «Нәрсә булды әле ул кадәр баш китәрлек?» – дигән сорауны бирсен. Һәр ситуациядән чыгу юлы бар, табылмыйча калмый ул».

> *Чирнең исеме грекчадан акылның, җанның таркалуы мәгънәсендәрәк тәрҗемә ителә.*

Башкача әйткәндә, кеше төрле сынауларга каршы тора алырга тиеш. Аның яраткан эше, шөгыле, гаиләсе, балалары булсын. Җәмгыять бу чир белән интегүчеләргә ала каргага карагандай карамасын. Шизофрения, һичшиксез, зур сынау ул. Инде язмыш җилкәгезгә шундый авыр йөк салган икән, үз-үзеңне дөрес тоту юлларын эзләргә, чирне танырга кирәк. Чирне тану, аның белән килешү – бу әле тәкъдир белән ризалашу дигән сүз түгел. Чирнең үзеннән-үзе юкка чыкмавын, нindидер чикләүләр куюын гына хәтерегездә тотыгыз. Чирең белән исәпләшә башладың исә, җилкәңнән нindидер авыр йөк төшүен шундук сизәрсең! Авыру саташуларга кереп китсә, аның хыялый идеяләр дөньясыннан чыгып җитә алмавы да ихтимал.

Белгеч киңәше



Галлюцинациядән интегүче белән үзеңне ничек тотарга:

- Сак кына авыруның нәрсә ишетүе хакында кызыксыныгыз;
- Аңа ничек ярдәм итәргә кирәклеге хакында үзе белән фикер алышыгыз;
- Ул яклаучысы барлыгын тойсын;
- Аның уйларының бары тик чир билгеләре генә булуын җайлап кына аңлатыгыз һәм табибка күренергә кирәклегенә ышандырыгыз;
- Авырудан көлмәгез;
- Аның кичерешләреннән куркып калмагыз;
- Авыруны уйларының чынбарлык түгеллегенә ышандырыгыз;
- Саташу-хыялый идеяләрдән интегүчеләр янында саташып әйткән сүзләрен ачыкларга керешмәгез;
- Бәхәсләшмәгез, аның сүзләренең дөрес түгеллеген раслап азапланмагыз, болай итү чирне көчәйтәчәк кенә;
- Әгәр ул үзен тыныч тотса, ярдәмгә мохтаҗлыгын сиздерсә, табибка мөрәҗәгать итәргә күндерегез;
- Әгәр дә бу саташу курку, ярсу, шомлану, кайгы кебек көчле эмоцияләр белән барса, тынычландырырга тырышыгыз һәм, кичекмәстән, табиб белән элемтәгә керегез.

Фото интернеттан алынды

PRESSA.RU

Фәнзилә МОСТАФИНА

СҮЗ, АКБУР, КАРА ТАКТА...

Аның хезмәт юлы 1996 елда Арчадагы 3 нче мәктәптә башлана. Тәҗрибәсез дип тормыйлар – югары сыйныфларны бирәләр аңа. Сыйныф җитәкчесе итеп тә куялар. Үзен күрсәтергә нибары ике ел җитә. Аннары директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары итеп билгелиләр. Ә дүрт елдан соң, язмыш, Гөлнара Гарипова мәгариф тармагыннан китеп торсын әле, дигән карар чыгара. Район хакимиятенең оештыру бүлегендә эшләү, «Арча хәбәрләре» газетасында баш мөхәррирнең дубляж буенча урынбасары булып тору... Тик бу эшләрнең берсе дә аның каныннан Укытучыны куып чыгара алмый. Һәм 2011 елда, тугыз еллык тәнәфестән соң, язмыш аны яңадан мәктәпкә кайтара.

Кайчандыр үзе тәмамлаган 2 нче мәктәпкә директор булып билгеләнгәч, Гөлнара Фидаил кызы капиталь төзекләндерүне башкарган иң зур эше дип атый. Эшли торган кешене бик тиз күрәләр. Күрәләр һәм кулына яңа эш тоттыралар. Тагын да авырракны, җаваплыракны. Менә Гөлнараның тормышында да тагын яңа этап: 2013 елның җәендә аны Арча педагогика көллиятенә директор итеп билгелиләр. 27 июльдә эшкә чыга ул. Бу вакытта уку йортында капиталь ремонт гөрли. Ә 18 августта, төзекләндерү эшен тәмамлап, чистарынып-яңарып ишекләрне ачасы. Бу эшне дә башкарып чыга Гөлнара Гарипова. Коллектив җылы кабул итә аны – шунысы да көч бирә. 1930 елда ук нигез салынган искиткеч бай тарихлы, үзенең традицияләре, укыту алымнары булган көллият белән җитәкчелек итә башлау җиңел булмагандыр. Үзе монда укыган булса да ярар иде әле. Һәр күзәнәге белән педагог булуы гына уку йортының максатын аңларга ярдәм итә. Кайчандыр 3 нче мәктәптә башлаган эшен генә дәвам итәсе бит инде – үз һөнәренең осталары булган чын Кешеләр тәрбиялисе. Бу кадәресен булдыра ул!

Фото: Гөлнара Сагиева

Көллияткә уттай урак өстендә килеп төштек. Түбәннән татар теле укытучылары килгән – директорның кунакларны данлыклы Арча педагогика көллияте белән таныштырып йөргән чагы. Аннары ул беренче курсларга багышланган чарада катнаша, аннары Казанга чыгып китә...

Шул эшләр арасына кереп кысылырга иде бит! Гөлнара Фидаил кызы тынычландырырга ашыга: «Мондый гына түгел, әллә нинди тыгыз көннәрдә дә исән калган бар! «Сөембикә» өчен вакыт тапмыйм димени соң?!»

Үзебезгә тәгаенләнгән вакытны, ниһаять, көтеп җиткереп, директорның «түренә» узабыз. Ниятебез – Гөлнара Фидаил кызы ГАРИПОВАны яңа яктан ачу. Кем соң ул?

● **ӘНИ.** Минем әни Фидания исемле. Ул гади эшче, гомер буе май заводында эшләгән. Шулай булса да, андагы гыйлем әллә ничә кешегә бүлеп бирерлек. Ул миңа: «Кызым, тормышта үз урыныңны тап. Кешеләргә игътибарлы бул, һәркемгә ихтирам белән кара», – дип кабатлый торган иде. Ни чәчсәң – шуны урырсың! Монысы да әни биргән сабак. Әни сабаклары гомерлек була ул.

● **МӘКТӘП.** Ничәнче сыйныфта укыганмындыр инде – алтынчы дәрес бара. Татар теле. Барыбыз да арыган, уку теләге калмаган, өйгә генә кайтып китәсе килә. Тоттым да кара тактага: «күңелсез дәрес» дип язып куйдым. Дәрес башланды. Берзаман укытучы теге язуны күреп алмасынмы! «Кем язды?» – ди. Бастым. И ачуланды инде мине: «Менә үзең укытучы булырсың да, яхшы итеп дәрес бирерсең», – диде. Әле ул вакытта укытучы булам дигән уйның ике ятып, бер төшемә дә кергәне юк. Сүзе рас килде: мин дә шул һөнәрне сайладым. Ә балачактагы ул тәртипсезлегем өчен мин һаман да оялам.

● **ҺӨНӘР.** Мин мәктәпне 1991 елда тәмамладым. Май ахырында классыбыз белән укытучыбыз Евгения Николаевнага кунакка килдек. Ул безнең сыйныф җитәкчесе, рус теле һәм әдәбиятын да укытты. «Кем булырга телисез?» – дип сораша. Ә минем беренче сыйныфтан бирле бер генә теләгем бар – юрист булу. Юридик факультетка керү авыр булганын белеп, ярар, тарих факультетына керермен дә, барыбер юрист булырмын, дип ниятләп тә куйган идем. Укытучым хыялымны тыңлады да: «Синнән яхшы рус теле укытучысы чыгачак, филология факультетына бар әле син», – дип киңәш бирде. Бик ярата идем ул укытучымны, шуңа күрә сүзенә колак салдым. Шулай итеп, дус кызым Наилә белән Казан дәүләт педагогика институтының филология факультетына барып кердек. Уку йортына аяк атлаганнан башлап бер генә мизгелгә дә укытучы һөнәрен сайлаганыма үкенгәнем булмады.

Ә балачак хыялы... Әти-әниләр үзләре тормышка ашыра алмаган хыялларын балаларына күчерә, диләр бит. Минем очракта да шулай булды. Кызым быел



Арча педагогика көллиятенең 85 еллык тарихы бар. Уку йортында хәзер мәш килеп юбилейга әзерләнәләр – ноябрь ахырында узачак ул.

Көллият ныклы белем бирүе, бердәм коллективы, районда, республикада, Россия күләмендә яулаган казанышлары белән мәшһүр. 85 ел эчендә ул милли «Педагогик кадрлар әзерләү казаны» дип исем яулады. Көллиятне тәмамлаучылар арасында Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Яхъя Халит, Мәрьям Хәсәнова, Валентин Беркутов, Россия Герое Олег Исаев, Флера Тарханова, Дания Әхмәтова, Альберт Яхин, Мөхәммәт Гатиятуллин, Данил Мостафин, Рифә Рахман, Галинур Корбанов, Роза Шәяхмәтова, Фәнис Җиһаншин һәм башкалар бар.

Дөньяда бердәнбер булган «Әлифба» музее да педагогика көллиятендә эшләп килә. 1999 елда уку йорты базасында оеша ул, ә 2001 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы музее буларак эшли башлый. Музей үзенең фәнни эчтәлеге һәм оригиналь булуы белән аерылып тора. «Әлифба» музееның бөтен дөнья халыкларының язу системасы барлыкка килү һәм аның борынгы вакыттан алып хәзерге көнгәчә үсешен күрсәткән бай фонды бар. Музейның бу фонды хәзер 1300 дән артык экспонаттан тора. Әлифбага һәйкәл дә куелды.

2013 елда Арча педагогика көллиятенә «Милли кадрлар әзерләү үзәге» дигән яңа статус бирелә. Республикада икеү андый үзәк – Минзәләдә һәм Арчада гына. Гөлнара Фидаил кызы җитәкләгән уку йорты Татарстанның 23 районын, шул исәптән Казан шәһәрен дә үз җаваплылыгы зонасына ала. Шул районнарны методик әсбаплар белән тәэмин итү, алар өчен милли кадрлар әзерләп чыгару юнәлешендә эшли башлаганнарына ике ел гына әле. Ә нәтиҗәсе хәзердән үк бар. Директор бүлмәсендәге диварда мактаулы «Сыйфат билгесе» эленеп тора. Бөтен Россиядәге урта һөнәри белем бирү йортлары арасында ирешкән уңышка бәя бу!



PRESSA.RU





гына Казан университетының юридик факультетын тәмамлады.

Хәер, мин үзем дә өлешчә булса да хыялымны тормышка ашырдым. Ун елга якын хакимияттә эшләү дәверендә кануннарны да өйрәнәсең, юристка да әйләнәсең. Икенче югары белемем дә бар: Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте институтын тәмамладым.

Белем бирү белән беррәттән, укучы күңеленә кешелеклелек орлыкларын да салу – минем төп бурычым.

ОСТАЗ. Тормыш юлымда яхшы кешеләр күп очрады. Шуларның берсе – Наилә Диннулла кызы Миңнемуллина. 3 нче мәктәптә директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары булып эшләдек без аның белән. Менә, ичмасам, чын укытучы! Үз эшенең фанаты. Ул мине күп нәрсәгә өйрәтте. Күптән лаеклы ялда инде. Шулай да һаман элемтәдә торабыз, борчуымны да, шатлыгымны да аның белән уртаклашам.

Вакытында миңа дөрес юнәлеш биреп, укытучы һөнәренә кертеп җибәргән сыйныф җитәкчем Евгения Николаевна Глущенконы да гел рәхмәт белән генә искә алам. Безнең чыгарылыш 90 нчы елларга туры килде. Яңа авторлар, яңа әсәрләр заманы. Күпме китап белән таныштык без! Евгения Николаевна биргән белем белән аннары институтта да җырлап кына укыдык.

Район хакимиятендә эшләгәндә Алмас Әмин улы Нәзиров (хәзер Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министры) мәктәбен уздым. Ул үзе зур тәҗрибә булды.

ЭШ ПРИНЦИБЫ. Мин һәрвакыт балаларга әйтә килдем: «Иң мөһиме көндәлектәге «бишле»ләр түгел, ә сезнең яхшы кеше булып үсүегез». Әлбәттә, фәнеңне яхшы белсәләр, бик рәхәт. Тик мәктәптә «отличник» булган, ә укып бетергәч, укытучыларын «танымый» башлаганнар күпме! Балам «өчле»гә генә укый, дип борчылучы ата-аналарга да гел бер сүзне кабатлыйм: аның белем дәрәҗәсе шуннан артмый торгандыр. Аның каруы, ул яхшы күңелле, ярдәмчел. Яхшы билге артыннан кумыйча, Кеше булуны өстен күргәннәрнең берсе дә югалып калмады.

ТОЕМЛАУ. Баламны укырга кая кертим икән, дип, киңәш сорап мөрәҗәгать иткәлиләр. Укытучы булырдай бала күз карашыннан, фикер сөрешеннән үк беленә. Өч сыйфат кирәк аңа: баланы ярату, ышандыра белү, мавыктыра алу.

Көллияткә эшкә урнашырга теләп килүчеләр күп. Кеше ишектән керә, әле бер сүз дә әйтергә өлгерми, ә мин инде аны «күрәм». Кесәсендә укытучы дипломы булса да, бу өлкәгә ялгыш килеп эләккәннәр дә бар бит. Күп вакытта беренче фикерем рас килә.

КЫЗЫМ. Кечерәк чагында Иркәнең: «Әни, син гел эштә», – дип үпкәләп әйткәне булды. Шулай да мин аңа вакытымны кызганмадым. Бүген ул миңа рәхмәтле.

Үсмерлек дәверендә бала белән ата-ана арасында каршылыклар туа. Бездә дә булды ул. Тавыш күтәреп, «ярамый» дип тукып торып кына проблеманы хәл итеп булмаячагын аңладым да кызыма якын дус булырга уйладым. Эштән кайткач, кичке ашны ашарга утырабыз һәм мин кызымны сөйләштерә башлыйм: янәсе көне ничек узган, тегесе-монысы... Иркә баштарак эчләрен тырпайта иде, әкренләп ачыла башлады. Ә бүген без аның белән якын дуслар.

Бүген көллият биш юнәлештә белгечләр әзерли: балалар бакчасы тәрбиячесе, башлангыч сыйныф, музыка һәм физкультура укытучылары, программистлар. «Быел физкультура бүлегенә бер урынга дүрт кеше дәгъва кылды», – ди горур тавыш белән Гөлнара Фидаил кызы. Гимназия сыйныфлары да ачып җибәргәннәр. 7-9 нчы сыйныфка кабул ителгән 35 баланы көллият өчен әзерлиләр. Педагогик элитаны кечкенәдән үстерәләр дигән сүз бу. Татар, рус, инглиз телләре белән генә чикләнмиләр, быел кытай һәм төрек телләрен дә укыта башлаганнар.



ЭШ НӘТИҖӘСЕ. Безгә балалар йортында тәрбияләнгәннәр дә укырга килә. Беренче-икенче курста алар белән йөдәп бетәбез. Тәрбиядәге «чи» урыннар сиздерә. Ә дүртенче курста күрсәгез сез аларны! Алардан да чын укытучылар әзерләп озатабыз. Шул дүрт ел эчендә үсмернең эволюциясен күзәтү, үз тырышлыгыңның нәтиҗәсен күрү – менә шул инде безнең өчен бәхет.

Тәрбиядәге «чи» урыннарны бетерү өчен һәр укучыга аерым якын килергә кирәк. Елмаеп, җилкәсеннән кочып алсаң да баланың күңеле була. Алар бит монда әти-әни канаты астыннан чыгып килә. Салкын сулышка өйрәнмәгән!

УКЫТУЧЫГА МӨНӘСӘБӘТ. Без үскәндә авыл җирендә укытучы Алла белән бер иде. Аңа күтәрелеп сүз әйтү турында уйлап та булмый, күз карашыннан ук курка идек. Ә 90 нчы елларда без һөнәрнең абруен югалттык, югалтканны табу бик кыен. Моның өчен без – укытучылар – үзебез дә, җәмгыять тә тырышырга тиеш.

Хәзер яңа технологияләр, интерактив ысуллар заманы. Тик минем өчен укытучы һөнәрендә иң кирәкле нәрсәләр – Сүз, Акбур, Кара такта. Калган чаралар ярдәмче генә.

ЗАМАНА УКУЧЫСЫ. Ул безгә охшамаган. Без, совет чоры балалары, фикеребезне әйтергә кыймый идек. Ә хәзергеләр курыкмый, белемлеләр. Без патриотлар идек. Хәзергеләрнең ватанпәрвәрлеге футбол караганда «Россия!» дип кычкырудан узмый. Хәзерге балалар прагматик, аларга ихласлык җитеп бетми.

БУШ ВАКЫТ. Директорның эше сәгатьләр белән чикләнми. Тик мин аны шәхси вакытыма керә димим, чөнки эшемне яратам. Ул миңа яшьлек дәрте бирә.

Көллияттә миннән энергия ташып тора. Ә өйгә кайткач, үзем генә калып, тыныч кына утырырга яратам. Шулай итеп көч җыя торганмындыр. Һәр хатын-кыз кебек үк өй эшләре белән мәшгуль булырга, пешеренергә, бәйләргә яратам. Китап уку белән җенләнәм. Буш вакытым булдымы, дусларым белән очрашырга тырышам. Бик әйбәт алар минем.

УҢЫШ РЕЦЕПТЫ. Мин амбицияле кеше түгел, беркайчан да югары үрләргә омтылмадым. Менә хәзер искә төшереп утырам әле... Мәктәптә укыганда директор буласы һәм бөтен җирдә тәртип оештырасы килү... Институтта укыганда колхозга бәрәңге алышырга чыга идек. Андагы эшнең оешмаганлыгын, җитәкченең пешмәгәнлеген күреп, их, колхоз рәисе булсаммы дип уйлап куюлар... Күңел түрендә нindидер чаткылары булган, күрәсең. Тик беркайчан да җитәкче булырга телим дигән максат куеп эшләмәдем.

Мин эшләмичә тора алмыйм. Хезмәттәшләрем бу сыйфатымнан иза да чигә инде – башкалардан да шуны таләп итәм бит. Менә бу ел беткәнче көллияттә республика күләмендәге ун чара үткәрәсебез бар әле! Эшеңне яратырга һәм аңа бөтен барлыгыңны багышларга кирәк, шул вакытта гына ул да сине яратачак.

Педагоглык каныма ук сеңеп өлгергән инде.

МИН. Ачулана белмим. Балаларга да, кул астымда эшләүче хезмәткәрләргә дә беркайчан да тавыш күтәргәнем юк. Өстәл сукмыйча гына да җитәкче булып була. Яхшылап сорыйм һәм кешеләр мине беркайчан да кыен хәлдә калдырмый.

Көллияткә директор булып килгәннән соң ике атнадан капиталь ремонтны тәмамлап, уку йортын ачарга кирәк. Президент та киләсе. Коллективта 150 ләп кеше, берсен дә белмим. Барысын да җыеп сөйләштем, хәлне аңлаттым. Төнге сменага чыгарга – җыештырырга, чистартырга кирәк иде. Сезнең өчен барысын да эшлибез, киләбез, диделәр. Берсе дә гозеремне кире какмады.

Кайвакыт катырак торырга, тавышны күтәрергә дә кирәктер. Тик алай булдыра алмыйм. Мине хәзер төзәтеп булмый инде. Шуңа күрә хезмәттәшләремә дә: «Ничек бар, шулай кабул итегез мине», – дим. Рәхмәт аларга, кабул иттеләр.



Фото: Газинур Хафизов

PRESSA.RU

Гыйффәт ТУТАШ

Әнигә хат

1
Йөрәк каның белән миңа рәнҗеп,
Хәсрәтләнеп, егълап көясең:
«Төпчек кызым, изге юлдан таеп,
Азып-тузып йөри», – диясең.

Гарьлек белән тулган ана күңле
Әрни кайгы-хәсрәт эчендә.
Иренләрең тетри, күзләреңдән
Яшьләр ага көндез, кичен дә.
2
Беләм, әнкәй, беләм, авыр сиңа.
Миндән күп өмидләр иткәнсең:
Бай йортлардан килгән яучыларны,
Туйларымны өзлеп көткәнсең.

Казан-табак, аш-су тирәсендә
Маугып гомер итәр дигәнсең;
Дин-гадәтләр колы – тыйнак кына
Бер абыстай булыр дигәнсең.
3
Үтәмәдем, әнкәй, теләгеңне...
Кеше дигән гали исемне
Түбәнсетеп яшәү мөмкин түгел,
Әсир итеп ирекле хисемне.

Синең юлың мине артка өнди –
Күзгә төндәй кара тормышка.
Нәфрәт уты белән мин чыгамын
Ул тормышка каршы сугышка!

1916

* * *

Ялтырачы күктә, өмид йолдызым,
Сиңа бит төбәлгән
минем күңлем күзе.
Кайгыларымны тараттырган да син,
Алга рух бирлән караттырган да син.
Ялтыра, дим,
миңа күрсәт тугъры юл,
Алга бастыр –
син миңа ярдәмче бул!
1913

И өмид,
күгемдәге ай,
суз мөкаддәс
ак кулың!
Кил, канатландыр
минем җансыз
күңелне – очсын ул,
Бер илаһи нурга чумсын,
күктә уйнап көлсен ул.



И ӨМЕТ!

БЕР ГАСЫР ЭЛГӘРЕ КУЛЫҢА КАЛӘМ АЛЫП МАТБУГАТТА ҮЗ СҮЗЕН ӘЙТЕРГӘ ҖӨРЬӘТ ИТКӘН ШАГЫЙРӘ ЗАҺИДӘ БУРНАШЕВА ХЫЯЛ ҖИМЕШЛӘРЕН – ШИГЫРЬЛӘРЕН КҮКТӘГЕ АЙГА ТИҢЛИ.



Роза КАМАЛЕТДИНОВА

Гаять кыйммәт бәяли. Чөнки иҗат итү (һәм иректә булу!) хокукын әти-әнисенә, төрки дөнья өчен яшәү кануны саналган дини кагыйдәләргә табынмыйча, Язмыш белән көрәшеп яуларга мәҗбүр була ул.

Гыйффәт туташ – Заһидә Бурнашева хәзерге Рязань өлкәсенә кергән Әҗе авылында бай сәүдәгәр Хөсәен Бурнашевлар гаиләсендә 1895 елның 19 октябрендә дөньяга килә.

Балачактан ук кызыксынучан булуы, укуга һәвәслеге белән күп кенә яшьтәшләреннән аерылып тора ул. Башта остабикәгә йөреп, аннан авыл мәктәбендә сабак ала. Әмма башлангыч белем генә канәгатьләндерми, үзлегеннән укырга, гыйлем үрләрен яуларга омтыла. Фатих Әмирхан әсәрләре, рус әдәбияты белән танышу тәмам «күзен ача», Тукай шигырьләре тәэсирендә ул үзе дә каләм тибрәтә башлый. Унбиш яшьлек кызның беренче шигъри әсәрләре «Ил» газетасы битләрендә (Мәскәүдә Гаяз Исхакый нәширлеге һәм мөхәррирлегендә чыга) 1913–1914 елларда Гыйффәт туташ тәхәллүсе белән күренә башлый.

Әмма бу хәл – кызның китапларга мөкиббән булуы, тагын да «яманрагы» – язарга, димәк, татар кызына тәгаенләнгән язмышны үзгәртергә омтылуы «бай йортлардан килгән яучыларны, туйларын өзелеп көткән» иске карашлы әти-әнисен чын-чынлап хафага сала. «Ниһаять, минем яшерен имза белән матбугатка чыккан шигырь кисәкләрем аларга мәгълүм булгач, минем өстемә кыямәтләр купты. Әллә нинди фаҗигаләр чыкты. Әстерхан имамы Салих мулла Галимбәковның шәригать исеменнән сөйләгән сафсаталары, әкиятләре аркасында, мин ахырда анам тарафыннан тәмам өйгә ябылдым».

Әнисе аны тоткын итә: язу әсбапларын тартып алып, бикләп куя. Китапларын яндыралар, дус кызлары белән аралашудан тыялар, беркая чыгармыйлар. «Шул зинданда ничә айлар буе хаксызга җәберләндем, тиргәлдем, сүгелдем. Әллә нинди газаплар арасында изелдем». Шәхси азатлыкка омтылышын яклауларына өметләнеп, Заһидәнең җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать итүе, әлбәттә, тагын да зур гауга – тавыш кубуга сәбәпче була.

Ата-ана һәм балалар арасындагы низаг чыгу яңалык түгел. Моңа мисаллар җитәрлек. Өлкәннәр тормыш тәҗрибәсен яшьләргә мирас итәргә, күп очракта көчләп тагарга тели, ә яшь буын, борын каната-каната булса да үзенчә яшәүне хуп күрә. Бу – тормыш кануны. Әмма ләкин дини гаиләдә тәрбия-сабак алган кыз баланың баш күтәрүе...

Ирекккә омтылган җан күтәрә алмаслык хурлыкларга төшүләр, иң якын, кадерле кешеләре тарафыннан җәберләнүләр аны хәлиткеч адымга этәргән, күрәсең.

Әйе, кызның әти-әнисе – хәлле сәүдәгәр гаиләсе – яшәү максатын җитеш тормыш итеп күрә. Өсте бөтен, тамагы тук килеш ата-анага каршы бару – яман гадәт. Кырыс мөгамәләнең ахыр максаты кыз баланы укуга һәвәслегеннән биздерү була, әлбәттә. «Ләкин шулай да, күкрәгемдәге мөкаддәс теләгемә аларның куллары җитешмәде, вә андагы изге йолдызларны өзгәләп ташларга булдыра алмадылар. Ахырда, августның 12 сендә, бар нәрсәгә күз йомып, җәнабе Алла хәзрәтләренә өмид багладым да, аларның йортларын ташлап чыгарга мәҗбүр булдым. Чыкканым вакыт бер кат кием белән һәм дә политсә рөхсәте белән чыктым. Минем йорттан һичбер нәрсә алып чыкмавымны шундагы кешеләрнең күрүе һәм дә анамның: «Ул минем акчаларымны урлап чыга торгандыр!» – дип, бөтенесе алдында мине тентеп тә, миннән һичбер нәрсә табылмавы минем вөҗданымның ни дәрәҗәдә пакь икәнен белдерсә кирәк. Ләкин шулай була торып та, иртәгесе көнне анам: «Кызым минем нәрсәләремне угырлаган», – дип, приставка жалу биреп, караклыкта гаепләп. миңа нахак бәла такты. Икенче көнендә тагын: «Кызым фахеш-

PRESSA.RU

ханəгə бара, Төркиягə кача», – дип, волостной правлениегə язып бирде».

Ана белəн кыз арасындагы низаг-гауга куерганнан-куера. Икесенең берсе дə юл куярга, чигенергə телəми. Заһидə туташны мондый адымга барырга этəргəн иң зур сəбəп, мөгаен, кыз баланың хокуксызлыгы, үз-үзен яклый алмавы өчен көенү булгандыр дип белəм. 1913 елда басылган «Дустым Гайшə хатирəсе» исемле шигыре мисалында ул моны ачык аңлатырга омтыла. Назлы сабый чагында үзе сыман мəгъсүмə (гөнаһсыз) кыз белəн дус булуын, тəмле ризыклар бүлешеп, рəхəтлəнеп уйнауларын, серлəшүлəрен, əмма унбиш яшенə җитүгə сандугач күк яшь-яшь кызны алдакчы бер яучы карчыкның янчык тулы акчага сатуын, илле яшьлек – бер залимгə кияүгə бирүлəрен, шул ук кышны бəхетсез җан – мескенкəйнең үлгəнлеген, бу аяныч хəлне аның һич оныта алмавын Гыйффəт туташның шигъри калəме гаять үтемле тасвирлый. Əмма лəкин Заһидəнең əнисе кызы ничек өзгəлəнгəнен əллə күрми-ишетми, əллə ишетеп тə һич аңларга телəми. Җитмəсə, кызын вакытлыча сыендырган туганнар-дусларын да төрлечə гаеплəп, уйдырма ялалар ягып, бурлыкта гаеплəп, өйлəренə тентү кертеп, һəммəсенең теңкəсенə тиеп бетə. Бу гамəле дə нəтиҗə бирмəгəч, кешелəр аркылы кызын үз йортына кайтырга өнди. «Минем бу ифтираларым тик аны өйгə кире кайтарыр өчен, укырга бара алмавы өчен генə», – дип əйттертеп тə карый. Əмма горур кыз мондый җəберлəү, рəнҗетүлəр, ялган, нахак бəлалəрдəн соң кире кайтып керүне күз алдына да китерə алмый.

Заһидə 1917 ел вакыйгаларын шатланып каршы ала, татар хатын-кызлары арасыннан беренчелəрдəн булып яңа тормыш төзүчелəр сафына баса.

Əнисенең кыланмышлары – кызга якты чырай күрсəткəн таныш-белеш белəн дə талашып, мыскыллы сүзлəр белəн сүгеп йөрүлəре эзсез үтми, билгеле. Яшь шагыйрəне берəү дə фатирга кертми. Əле ярый, ул ярдəмчел, алдынгы карашлы сəүдəгəр Хөсəен Ширинский гаилəсеннəн чакыру ала һəм, Әҗедə торыр урын калмагач, үзлəреннəн унике чакрымдагы Богданово авылына китə. Сыеныр урын табуына шатланса да, алга таба ничек көн күрергə дигəн уй тынгы бирми. Тыныч яши, иҗат итə алмый. «Укырга китəр идем, читкə чыгарга волостной старшина паспорт бирми. Анамның ифтиралары көннəн-көн ишəя. Әҗедə үзлəрен ярдəмчел һəм тəрəккыйпəрвəр, халык хəдиме итеп танучы агай-эне, аңлырак сыйныфтан саналганнар тарафыннан миңа һичбер ярдəм кулын сузучы, вөҗдан һəм мəрхəмəт намено хакыйкатьне сөйлəр өчен авыз ачучы юк.

Минем гөнаһсызлыгымны, явызларча түктерелгəн күз яшьлəремне күрə торып та, залимнəр тырнагы астында чытырдавымны ишетеп тə, миңа Әҗе тарафыннан бер мəрхəмəт иясе чыгып, ярдəм кулы сузмагач, хаксызга җəберлəнгəн вə уку юлында бу кадəр җəһəннəм газаплары күргəн бер кызын химаягə (яклап, канат астына алырга) чакырам.

Эссе ком сахраларында сусызлыктан хəле бетеп җиргə егылган, ерткычлар алдына ташланган бер химаясез, көчсез кошчык кебек рəнҗетелгəн йөрəгемнəн өзелеп чыккан: «Ярдəм, ярдəм!» – дигəн авазымның соңгы сулышларыма кадəр нинди дə булса бер мəрхəмəт иясенə килеп ирешер өмиде белəн, бу мəкалəне миллəт нəзаренə тəкъдим итəм.

Миллəттəн ярдəм көтеп: Заһидə Бурнаши (Гыйффəт)».

«Мəрхəмəт намено бер үтенеч» дигəн ачык хат «Вакыт» газетасының 1915 елгы 6 сентябрь санында басылып чыга. Хат игътибарсыз калмый. Беренче чиратта яшь шагыйрəне алдынгы татар матбугаты яклап чыга. Петербургта укучы татар студентлары «Вакыт» газетасы аша: «Бертуктаусыз яхшылыкка вə югарылыкка омтылган шагыйрəнə күңелнең кара көчкə бирелеп, аның тырнагында кала алмаганын аңлыйбыз. Батырлыгы алдында тез чүгəбез», – дип телəктəшлек белдерəлəр. Озакламый ярдəм дə килə: Заһидəне Мəскəүгə чакырып алалар, эшкə урнаштыралар, ул хосусый дəреслəр биреп, тормышын җайлый. «Гыйффəт туташ шигырьлəре» исеме белəн 1915 елда Мəскəүдə бертуган Карамышевлар нəширлегендə беренче китабы басыла. Аннан соң, 1916, 1917 елларда, шул ук исем белəн тагын ике җыентыгы дөнья күрə. Татар хатын-кызының иске тормыш тəртиплəре белəн килешергə телəмичə, тигез хокуклылыкка, гаделлеккə омтылышын кайнар хис, реалистик буяуларда чагылдырган бу əсəрлəр шул заманның яшь буын укучылары арасында телəктəшлек таба.

1918 елда большевиклар партиясенə кабул ителгəн Заһидəне Урта Азиягə җаваплы эшкə билгелилəр. Сəмəрканд каласында үзбəк телендə чыга торган өлкə газетасында эшли. 1919–1920 елларда Төркестан Коммунистлар партиясе Үзəк Комитетының хатын-кызлар белəн эшлəү бүлегенə җитəкчелек итə. Үзбəкстан һəм Кыргызстан Республикаларындагы партия, совет оешмаларында эшлəгəн татар кызының турыдан-туры җитəкчелеге астында төрекмəн, кыргыз һəм үзбəк кызларыннан күп кенə мəдəният хезмəткəрлəре – укытучылар, җитəкче кадрлар əзерлəнə.

1952 елда, пенсиягə чыккач, əүвəл Буага, аннан Казанга күченеп кайта.

Ə шигырьлəр, дияр кемдер.

Күрəсең, шигырь күктəге ай кебек күңеллəрне нурландыручы нур – якты хыял булып кала. Дөрес, калəмне кулыннан төшермəскə тырыша: архив материалларына, замандашлары истəлеклəренə нигезлəнеп язган «Татар хатын-кызлары хəрəкəте тарихыннан» исемле китабы 1971 елда Татарстан китап нəшриятында дөнья күрə. 1977 елның 5 ноябрендə ул Казанда вафат була.

ӘБИЕМ, ӘБЕКӘЕМ!



«Казан» милли мәдәният үзәгендә узган бу бәйгегә ак шәлле, читекле әбиләр агылып килер, рәешкә генә кия торган күлмәкләргә сеңгән исле үлән, ислемай исләреннән башлар әйләнерлек булыр дип уйлаган идем. Залда тамашачының заманчасы утыра булып чыкты. Балитәкле күлмәкләр, камзуллар, калфаклар – сәхнәдә! «Ак яулыклы дәү әниләр» бәйгесе дүртенче тапкыр уздырыла. Казанның Елга аръягы зонасында тамырланган бу яхшы ниятле эш быел менә шәһәр үзәгенә килеп җиткән.

Оныксыз дәү әни була димени инде ул?! Казан мәктәпләрендә кырык дүрт ел укытучы булып эшләгән Гөлсинә Ганиеваның оныгы Марат Өметбаев, баянда уйнап, дәү әнисен җырлатып йөреп, күптән безгә таныш егеткә әверелде инде. Тәҗрибәле укытучы, кырык еллык педагоглык стажы булган Рәмзия Муллахмәтованы да оныклары Булат белән Динә шигырьләр сөйләп сөендерде. Әгәр онықларыңны әкиятләрең, бишек җырларың белән назлап үстерә белсәң, җимешләре татлы була аның.



Фәния Гыймадиеваның оныгы Әлфия белән бергәләп «Балан» җырын җырлаганда тамашачыларның күңелләре тулып киткәндер. Хәер, алар Әлфия өчен әбекәенең аеруча газиз икәнен каян белсеннәр? Казандагы сәләтле балалар укый торган 4 нче санлы интернат-мәктәптә инсафлы кыз итеп тәрбияләнүче бу чибәр кызыкай, инде җиткән кыз, балан әчесен татыгын бала. «Әнием каты авырудан вафат булганга биш ел, – диде ул, миңа гына йөрәген ачып. – Казакларга җәйләрен кайтам. Әбием миңа үләннәрнең серләрен өйрәтә, бергәләп урманга барабыз, җиләк җыябыз, серләшәбез дә инде. Бик кызык кеше бит ул. Велосипедта да йөри, спорт белән дә шөгыльләнә. Аның янына күрше авыл кешеләре дә киңәш-табыш итәргә килә. Ул миңа җиде буынга кадәр бабаларымны ятлатты. Минем Казанда да дәү әнием бар. Анысын да бик яратам».



Дәү әни татлы тел, йомшак куллар, тәмле коймаклар, мавыктыргыч хикәятләр генә түгел бит әле ул. Биредәге дәү әниләр укымышлылар. Сүзне дә күп чагында хикмәт белән әйтәләр. «Моңы барның йөрәгеннән һәрвакыт җылы чыгар» ише канатлы сүзләрне кем әйтте соң әле? Рәмзия ханым бугай. «Сөембикә» бәетен дә ул җырлады. Тәҗрибәле педагог бала-чага алдында буш сүз сөйләргә ярамаганын яхшы белә. 113 нче санлы гимназия укытучысы Гөлсинә ханым да тегү-чигү белән генә түгел, бәлки әле һаман бию ансамбленә йөри алуы белән, оныкларының шахмат уйнаулары белән матур итеп мактана. Ә менә үзе төзеп алып килгән нәсел агачы – шәҗәрә белән Арча кызы Фирая Зарипова гына мактана алды. Шәҗәрәсен ул «Васыять агачы» дип атаган. Аның нияте ифрат та изге – дәвамчылар, оныклар инде, «Васыять агачы»ның ябалдашларын мул итәргә, яфракларга татар исемнәре кушарга бурычлы. Дәү әниләре белән килгән Ислам белән Камиләнеке ишедер дип уйлыйм. Менә бу васыять, ичмасам! Васыять кенә түгел, һәр татарның хыялы.



Горурлану җәһәтеннән... Нурзидә ханымның оныклары: «безнең әби – иң сабыры» дип, Фәния ханымнықылар: «безнеке – иң сөйкемлесе» дип, Фирая ханымнықылар: «безнең дәү әни – иң уңганы» дип, Гөлсинә ханымнықылар: «иң зыялысы» дип, Рәмзия ханымнықылар: «иң зирәге» дип горурланырлар. Бәйгедә катнашкан дәү әниләрнең һәркайсы әнә шул сыйфатлар белән аерымлап куелды.

Бәйгенең берсен дә калдырмый карап бара, ярдәмләшә торган кеше – Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге рәисе Фәрит Мифтахов котлау сүзләренә сөенечен кушып, бәләкәй мактанычыбыз «Голос» проектында икенче урын яулаган Сәйдә Мөхәммәтҗанова белән бергә җырлап та төште әле сәхнәдән. Коммунистлар узаманы Хафиз Миргалимов та, «Болгар» фонды вәкиле Рәмзия Галләметдинова да дәү әниләр бәйгесен, Казан почмагыннан чыгарып, Республикакүләм хәрәкәт итеп үстерү кирәклеген искәрттеләр. «Ак калфак» хатын-кызлар оешмасы рәисе Кадрия Идрисова җәмгыять сагында торучы әбиләр-әбекәйләр белән оныклар арасындагы рухани бәйләнешне суытмау, ә бәйгеләрне тагын да колачлырак, мәгънәлерәк итү зарурлыгын искәртте.

Асия ЮНЫСОВА

16+

“Челны-ТВ” объявляет акцию:

МОЯ ЛЮБИМАЯ ТЁЩА!

Признайся в любви своей теще и выиграй приз!



ТВЦ

РЕКЛАМА

Подробности: tvchelny.ru, vk.com/tvchelny

«Сөембикә» журналы да, бу акциягә кушылып, үз сайтында һәм социаль челтәрләрдәге битләрендә шушындый ук бәйге игълан итә. Гомерлек яр итеп сайлаган кешегезнең әнисе сезнең өчен дә кадерле зат. Әниләр көне җитә. Аны – сезгә менә дигән кыз үстереп биргән ананы безнең аша да котлый аласыз. Иң матур сүзләрне, иң ихлас теләкләрне сайлап...
Без аларны сезнең фотогыз белән сайтыбызда урнаштырырбыз, иң матурларын Чаллы телевидениесе дә күрсәтер. Котлауларны түбәндәге адреска юллагыз: ssuum@yandex.ru.
Акция турында тулырак мәгълүматны безнең сайтыбыздан www.syuyumbike.ru һәм «Чаллы-ТВ» сайтыннан www.tvchelny.ru карый аласыз.

PRESSA.RU



Фото интернеттан алынды

БӘХИЛЛӘШҮ



Миңназыйм
СӘФӘРОВ

МИНЕМ БУ ДӨНЬЯДА ӘНИЛЕ БУЛЫП ЯШӘВЕМӘ НИБАРЫ ӨЧ КӨН КАЛГАН ИДЕ. ТОРМЫШ, БИЛГЕЛЕ, АННАН СОҢ ДА ТУКТАЛЫП КАЛМАДЫ. ӘММА УЛ ИНДЕ КҮНЕГЕЛГӘН, МӘҢГЕ ШУЛАЙ БУЛЫР КЕБЕК ТОЕЛГАН ӘНИЛЕ ТОРМЫШ ТҮГЕЛ ИДЕ.



Әни үзе белән күзгә күренмәгән тормыш ямен алып китте. Соңыннан мин кичергәнемне әнинең кабер ташына шигырь юллары итеп язып әйтәчәкмен:

Әтиләр – тормыш терәге,
Әниләр йөрәк икән.
Дөньяның ямен тоярга
Әниләр кирәк икән!

Әҗәл, әнине генә алып китмәгән, бәлки, күңелнең әни белән тоташкан тамырын да өзгән булып чыкты. Бу авыр хәсрәт өскә ишелеп төшкәнче әле тагын өч көн әниле тормыш бар иде.

Әнине урын өстендә күрү белән йөрәк дерт итте: аның моңарчы мине беркайчан да урында каршы алганы юк иде. Гадәттә, мин кайтасы көнне ул, шатлыгы эченә сыймаган сабый кебек, үзенә урын таба алмый йөри башлый икән. Капка төбендә көтеп арыганнан соң өйгә керә, ди. Кайтканын күрми калырмын дип тәрәзәдән күзен алмый урамны күзәтә, ди. «Абыегыз нишләп һаман кайтып җитә алмый икән инде?» – дип, бу хәлгә инде күнегеп беткән өйдәге-

ләрнең тынычлыгын ала, ди. Кызу канлы кеше булгангадыр, һәрнәрсәнең тиз һәм сәгате-минуты белән башкарылганын ярата. Китү-кайту ансат булмаган заманнарда да әни мине урман авызына кадәр озата менә иде. Хәзерге акылым белән аңлыйм: шул бер-ике чакрым араны үткәндә өйдә сөйләп өлгермәгән, йә онытылган нәрсәләрне әйтеп калу өчен генә түгел, еракка китәсе баласы белән озаграк булу җаен эзләгән икән әнием. Иң гаҗәбе – әни шул юлны минем белән бер аяктан, үзе әйтмешли, ялт-йолт атлап кына менә иде. Яше барган саен, мин адымнарны акрынайта төшә идем. Ә ул шаярткан була торган иде: «Былтыр болай түгел идем, улым, быел әллә нишләдем бит әле: атлаганда күздән яшь килә. Җитмеш биштә үк шулай булгач инде...» – ди дә көлеп җибәрә. Бу инде аның, хатын-кыз гадәтенчә, миннән комплимент, мактау ишетәсе килүдән. «И-и-и әни, җитмеш биштә шулай минем белән бер тизлектә йөри алуыңа сөенергә генә кирәк», – дим. «Шулай дисеңме?» – дип, елмаеп миңа карый. Кайткан-киткән автобусның вакытын төп-төгәл белгән шикелле, минем үз машинам белән кайтып җитәрлек вакыт та төп-төгәл булырга тиеш дип саный иде әни. Чөнки ул минем Казаннан ничәдә чыгып китүмне телефоннан белешеп, шул вакытка өч сәгатьлек юл вакытын салып куя да тынгысызлана башлый.

Бүген ул урын өстендә. Хәл эчендә икәнлеген яулык астыннан бүселеп чыккан ап-ак чәчләреннән дә, беркайчан да сер бирергә күнекмәгән күзләренең гаепле сыман карашыннан да чамаларга була иде.

– Исән-сау гына кайттыңмы, улым?

Мин бугазга килеп төелгән күз яшьләрен тыеп, җавап кайтара алмый торам. Хәлемне сизгән ана, баласына үзенең хасталыгы турында ләм-мим сүз әйтми әле. Әйтерсең, ул фәкать хәл алырга дип кенә яткан. Имеш, аңа дөньядагы һәммә нәрсә дә кызык!

– Юлларда машина күп идеме? Нинди машина белән кайттың? Агы беләнме? Оланнарның ни хәлләре бар?

Менә шулай, әни бу юлы да читен халәтне җиңеләйтү юлын бик җиңел генә тапты. Бер мизгелдән инде мин аңа бар белгәннәремне сөйләп утырам. Ни хикмәт – соңгы вакытта бераз катыланган колаклары ачылып киткән димме, ул ишетә башлаган колаклары бер генә сүзне дә кабатлап сорамады. Сөенеп куйдым хәтта, өмет чаткысы яктырып куйды: начар ук түгел икән бит әле әнинең хәлләре. Бәлки, аягына да басар? Әмма әнинең Нәҗип бабай коесыннан су соравы ул өмет чаткысын шунда ук сүндерде. Гомер буе чәйгә шул коеның суын гына тотты ул.

– Кыен булмаса, коедан хәзер генә алып кергән суны әнә теге тустаганга салып бирегез әле.

Шунда мин әнинең урманнан себеркелек күтәреп кайтып, үзе әйтмешли, бәгыре көйгәннән шул тустаганны тотырып салкын су эчкән чагын күз алдыма китердем.

– Ә-ә-әх, тәмле шул безнең су!

Бу юлы да нәкъ шулай диде ул. Аннары, азрак хәл алганнан соң, тагын дөнья хәлләренә күчте. Гадәттәгечә, күргән авырлыклары, булышкан күршеләре, бездән күргән игелекләрен, Ходай Тәгаләгә бар күңеле белән инәлепләр рәхмәт әйтеп, искә ала башлады:

– Әлхәмделилләһи шөкер, оланнар. Алланың биргәненә бер түгел, мең шөкер!

Бу сүзләрне мин моннан 42 ел элек, әти үлгән көннең кичендә лапаста сыер сауган әнидән ишетеп хәйран калган идем. Әти үлеп ята, без әнигә алты бала (олысы институтның беренче курсында укый, алтынчысы – кулда, ике яшендә) өелеп калган, ә ул күз яшьләре аша Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт укып утыра. Әни ычкынган икән дигән уй минем ушымны алды. Күзәтеп торган җиремнән чыктым да, елый-елый, әнидән сорадым:

Аллага сыену, сабыр итү – тулы бер тормыш фәлсәфәсе ул!

– Нишләп алай дисең син, әнәй?! Алла безне әтисез калдырды бит бүген! Тилердеңме әллә син?

– Юк, улым, мин тилермәдем, – диде әни, сыер савуыннан туктап. Ходай Тәгалә кайгы-хәсрәтләрне бу дөньяда үземнең иң яраткан бәндәләремә бирермен дигән. Димәк, без аның яратканнарыннан. Син әле аңлап бетермисең...

Ә бит, чыннан да, кеше мондый чакта шулай уйламаса, ачы хәсрәткә ничек түзәр иде?

– Ризыгыгыз киң булсын! Дәрәҗәгез олы булсын!

Бу теләкләре дә әнинең йөрәгеннән өзелеп төшә. Алты баласын кеше итү өчен әнинең колхозда эшләмәгән эше калмады – чүп үләне утады, кыяр, помидор кәлшәләре үстерде, тегермән тарттырды, кырда эшләүчеләрне ашатты...

Соңрак, бөтен баласын да бер өйдә, бер өстәл артында күргән чакларында, әни, тагын да шул хатын-кызларча кыланып, бездән рәхмәт, мактау сүзләре ишетергә теләп, болай дип әйтергә ярата иде:

– Нүжәли, боларның барысын да шул бер сәләмә карчык үстергән инде, ә?! Әлхәмделилләһи шөкер, оланнар!

Һәркайсыбызның йә башыннан, йә иңсәсеннән сыйпаштырып, ул үз ягына таба атлый. Без дә андый чакта әнинең нинди сүзгә мохтаҗ икәнлеген яхшы белеп бетергән инде:

– Бер дә сәләмә түгел әле, үзең кебек шәп оланнар үстергәнсең, әнәй! – дибез.

Сәләмә диюенең төбендә без генә белгән бер кызык нәрсә ята. Әни гаиләдәге күпсанлы балалар арасында беренче кыз бала булган. Ул чакта бит, әни әйтмешли, ел саен олан тапканнар. Икесе генә исән кала: әни һәм абыйсы. Соңрак тагын дүрт энесе туачак әле. Көтеп алган кызны да тирә-күршеләре озак тормас дип юрый. Бабай, шул кызым исән-сау калса, корбан

PRESSA.RU



Безнең әни, малайлар арасында үскәнгәдер инде, тегү машинасы янына утырмады, ә гармунда бик оста итеп уйнады. Үзе уйнап үзе җырлаганын магнитофонга яздырып алганым да булды. Авыр чагында да, ай алкаларын ялтыратып, яулык чөеп, камыр басканда да әни мөнәҗәтләр көйләргә ярата иде. Аларның күбесе: «Сабырлык бирсәнә, Ходай!» – дип тәмамлана иде. Үзенең холкына туры килгәнен үзе чыгардымы икән, әллә булганнары арасыннан шундыйларын сайлап җырлагандырмы, дип уйлап утырам бүген.

чалыр идем дип нәзер әйтә. Нәзер әйтмәслек тә түгел шул: бу кыз бала дөньяга лампа куыгы (бездә аны пузыйр диләр) кадәр генә булып туа. Авырлыгы дүрт кадак чамасы (хәзерге үлчәү белән бер кило да алты йөз грамм!) «Әни әйтә торган иде: сине ипи сала торган көрәккә куеп, җылы мичкә тыга торган идем. Берсендә күрше хатыны минем шулай азапланганны күрде дә: «Шәмсегаян, нишләп шулай интегәсең, барыбер яшисе бала түгел бит бу. Әйдә, өстенә мендәр генә каплыйк та...» – дип сөйли иде әни.

Борынгылар: «Әниләрнең үлеме белән җәннәтнең бер ишеге ябылыр», – дип юкка гына әйтмәгән икән шул.

Менә шул дөньяга ашыгып туган кызу канлы бала, Ходай гомерен насыйп иткәч, бүген туксанына җитеп килгәндә узган гомерен барлап ята.

– Күршеләрем, Аллага шөкер, бик яхшы булдылар. Хәсрәтләремне дә күтәрештеләр, ризыкларын да бүлештеләр. Әле дә: «Әминә әптәй!» – дип, үлеп торалар.

Хәсрәтне дә аз күрмәде безнең әни. Әйткәнемчә, башта, иллесе дә тулмаган килеш, алты бала белән ирсез калды. Ә аңа кадәр авыру кайнанасын карады. «Берегез дә урынымны Әминә кебек итеп йомшак җәя белми», – ди торган була ул әни турында. Аннары сукыр бабабызны бала карагандай бакты ул.

– Тел ачарга ярамаганын белсәм дә, сез югында бабагызны мунчага үзем алып барам, юындырам, чабам, күтәреп диярлек алып кайтам. Әткәй бик уңайсызлана, елый-елый рәхмәт укый иде. Урамыбызда аның кебек киленен мактаган кеше бүтән юк иде, урыны җәннәтнең түрендә булсын! – дип кабат-кабат искә ала иде үзенең кайнатасы турында. – Шуның теләкләре белән шундый кадер-хөрмәттә яшимдер дә әле...

Аннары, булган-булган булсын диптер инде, Ходай Тәгалә аңа бала хәсрәтен дә өстәде: озын-озак авырмыйча гына, совет чоры табибларының наданлыгы һәм битарафлыгы аркасында 19 яшьлек апабыз гүр иясе булды. Анда да шөкер итте әни. Апаның киелми калган яшел пальтосын, плащын кочаклап елаган чакларын миңа очраклы гына күрергә туры килгәләде. Андый чакларда да әни юаныргa сүз таба иде:

– Әле ярый үлеп котылды! Кияүгә чыгар иде, ире аерып җибәрсә, йә кул күтәрсә, йөрәкләрең өзелер иде. Ә баласы ятим калса...

Бу юатуларны ул бер дә уйлап чыгарып кына әйтми иде: авылда гыйбрәтләр адым баскан саен. Әнинең үзе әйтмешли, беркемнең дә эче буш түгел.

Хәле авыраеп киткәнне әнинең күзләреннән чамалыйбыз. Ләкин теле белән бер генә дә зарланмады. Әлеге дә баягы, су сорады: «Тустаган белән...» Шунда мин әнидән: «Йәсин» укысам ярыймы?» – дип сорарга көч таптым. Ул, билгеле, сөенеп риза булды. Гомеремдә кылган гамәлем түгел иде бу. «Йәсин»не мин сукыр бабамның көйләп укуыннан гына танып беләм. Нәкъ менә аныңчарак итеп укып бетергәннән соң, әни миңа кушылып дога кылды да миңа гаҗәпле караш төбәп: «Улым, каян өйрәндең шулай матур итеп укырга?» – дип сорады. Ул шушы хәл эчендә яткан чагында да соклану, баласы өчен куану кебек дөньяви хисләр өчен үзендә көч тапты. Аннары аның хәле начарайган саен, абый йә кияү белән чиратлашып, «Йәсин» чыгабыз. Хәлсез әни, безнең гамәлләрне хуплап, баш бармагын югары күтәрә дә елмаерга тырыша. Йә Алла, бирсәң дә бирерсең икән яраткан бәндәңә сабырлыкны!

Өзеләсе көнне әнинең зиһене ачылып китте. Күңелдән генә туган авылына кайтып, кемнәр күршесендә кемнәр яшәгәнлеген хәтердән саный башлады. Әйтерсең, кичә генә шунда булып кайткан. «Кемне искә алсаң – шул юк, оланнар. Мәрхүм Идият әбзәй мин килгәнне карап тора берсендә. «Сагынасыңмы, кызым, авылыбызны?» – дип сорый. Сагынмаган кеше 15-20 чакрым җиргә атлаган саен җәяү йөгерми бит инде ул». Шунда ул бүгенгегә кайта: «Бетте шул безнең авыл, ничә йортта кеше яши икән инде анда хәзер?» – дип, үз авылыннан

алдырган килененә сорау бирә. 16 йорттан төтен чыкканлыгын белгәч, тагын боегып кала: «Беткән икән шул».

Янәшәсендә утырган сеңлем, нәкъ әничә итеп, сүзне шаяруга бормакчы була:

– Яратмыйм шул авылны, дип, безгә дөресен әйтмәгәнсең икән бит син, әнәй. Ә үзең андагы хан заманы кешеләрен исемләп санап ятасың.

– Туган авыл бит ул, кызым! – ди әни бу сүзләргә тирән мәгънә салып.

Без инде аңа күп сөйләшмәскә, хәлен бетермәскә тырышабыз. Авызына кое суыннан башка ризык капканы юк дисәм, ялган буласы икән. «Мин бит әле бүген теге ак даруымны капмадым бугай», – дип, кечкенә генә сәдәфне көч-хәл белән йотып куйды. Чөнки безнең әни даруны бик ярата иде. Тиз ышанучан, ихлас кеше булгангадыр инде, даруларның шифасы барлыгына чын күңеленнән ышана, аларны беркайчан да үзенең төенчекләреннән калдырмый йөртте. «Монысы аяк-куллар сызлаганнан, монысы кан басымыннан, ә монысы...» дип, кунакка килгән саен, аларны барлап чыгар иде. Биш вакыт намаз белән бергә, сәгатен-сәгатькә туры китереп каба иде ул даруларны.

Безнең хәсрәтле чырай белән янәшәсендә утыруны әнинең күңеле өнәми иде. Башта: «Мин исән чакта абыйларыгызга хәбәр салыгыз – күрешеп калыйк», – дигән булса, икенче көнне: «Улым, син бит инде минем янда икенче көн утырасың. Эшең дә кала, орышырлар», – дип борчыла башлады. Аннары, буш утырганчы диптер инде: «Бер җыр искә төште бит әле», – диде. Җырларны әни күп белә иде. Әбидән булгандыр инде ул кадәресе. Әби дә исән чагында миңа шактый гына җырларын әйтеп яздырган иде. Ике көн буена безгә рәхмәтләрен, хатирәләрен ирештереп, җырларын көйләп яткан әни, өзеләсе көнне кинәт кенә: «Мин китәм!» – дип әйтеп салды. Тыныч кына, гадәти сүз кебек кенә әйтте ул бу ике сүзне.

– Бәхил булыгыз, – дип, барыбыз белән дә аерымлап бәхилләште. Безнең тома ятимлеккә берничә генә сәгать вакыт калып бара иде. Бер-беребезне алыштырып, «Йәсин» чыгуыбызны дәвам иттек. Әни күзләрен тутырып безгә карап ала да сизелер-сизелмәс кенә минем учымдагы бармакларын кысып куя һәм пышылдап кына иман кәлимәсен кабатлый: «Лә илаһе иллалаһе Мөхәммәде рәсүлуллаһе».

Гомере буе: «И-и-и, ул өч кенә көн авырып ятсаң икән дә, җомга көнне җир куенына керсәң икән!» – дигән теләкләре, күрәсең, Ходайның «Амин» дигән чагына туры килгәндер – барысы да үзе теләгәнчә булды. Җырлап, уйнап-көлеп яшәгән иде, шулай матур гына китеп тә барды. Матур, якты хатирәләрен калдырып, берәүне дә бимазаламый гына бакыйлыкка күчте газиз анабыз. Безнең өчен җәннәтнең бер ишеге ябылды. Инде үзебезгә дә иртәме-соңмы шунда барасы бит дигән уй гына әнисез калу хәсрәтен азрак җиңеләйткән кебек була.

Факил САФИН

Әнкәй

Юл өзеге озаккарак китте,
Әллә ничек булды кышы да...
Бик сагынгач, хәбәр салган әнкәй –
Ак болытлар башым очында...

Мең кат үтеп сират күперләрен
Бәхет эзләп йөреш дөньяда.
Әнкәйләрнең аяк асты – оҗмах,
Читтә бәхет зәгыйфь шуңа да.

Билчән утап, кышын киндер эрләп,
Бар тоемын җуйган бармаклар,
Кайтсам, беләм, шундый йомшак итеп
Чәчләремне сыйпап ардаклар.

Шул мәлдә мин –
Кояш нурын эчеп,
Иләсләнгән шомырт чәчәге.
Шушы мәлдә мин бәхетне тоям,
Шушы мәлдә әйтәм: яшәдем!

Канат ярып тыелгысыз очам,
Балачаклы аяз көннәргә...
...Гомеркәйнең бер гөнаһсыз чагы,
Оеп ятам ап-ак мендәрдә.

Әнкәй өйдә. Бисмилласын әйтеп,
Җилпуч тутырып онын или ул.
Мин уянып, эшен бүлмәсенгә
Мөнәҗәт йә бәет көйли ул.

«Барып җиткәч дәрьяга,
китерделәр кимәгә,
Газиз телләрем бәйләнде,
белмим ни сүз димәгә...»
...Мичтә янган усак утынынннан
Чәчрәп төшә кузлар идәнгә...

Бәетендә үкси Сөембикә.
Шул чорлардан үкси илкәйләр.
Шул чордан ук безнең җаннар сукбай,
Шул чордан ук – үксез әнкәйләр.

Усак утыны күк гомер яна.
Сибелә дә җилгә, чәчелә.
Җилпучтагы оннар кисәк тузгып,
Килеп яткан чигә чәчемә.

Бәхет эзләп киткән идек юкса,
Тормыш безгә никтер үчекте.
Сабырлыгы сынмас әнкәйләргә
Әйтеләсе сүзләр кичекте...

...Ак мендәрдә хәлсез ята әнкәй.
«Улым кайткан...» Әйтте пышылдап.
...Ак болытлар мөлдерәмә тулып,
Туктап калган башым очында...

PRESSA.RU



Луиза
ЯНСУАР

МИН БӘХЕТНЕ ЯЛАНАЯК КҮРӘМ

Түбәләр

Алмалар тупырдый.
Бииләр төн ката.
Түбәләр сәхнәгә әйләнгән фасыл бу.
Ай тула. Мөлдери. Коена улакта.
Тәрәздә пәрдәләр – тынгысыз,
ярсулы.
«Йокларга шикләнәм», – дисең син.
Көләсең.
Ә минем елмаю туганчы сүрелә.
Син – көчле, ышанам.
Мин – тугры үземә.
Шуңа да арада шәүләләр терелә.
Үзебез, эндәшми, тәтенгә әйләнеп,
Агабыз җай гына алмалар катына.
Ай тула. Мөлдери.
Таратып чәчләрен,
Бакчада төн буе таганда атына.
Мин сиңа бер генә,
бары бер мизгелгә
Кагылыр идем дә...
Җимерер әфсенне!
Тик ялгыш адымнан,
сүзләрдән куркамын,
Бу хискә каяндыр
әчкелтем тәм сеңде.
Син тиздән китәрсең Сентябрь
Иленә –
Яфраклар коярсың, ягарсың учаклар.
Мин монда калырмын.
Йокламам төн ката.
Терелер син теккән куяннар,
курчаклар.
Һәм мине юатыр аларның бәйләне –
Бүлмәмнән джаз качар,
без йола җырына
Кушылып биербез, көләрбез,
шашарбыз,
Ышанып дөньяның мондагы,
чынына.
Бары син яраткан көйләрдән,
төсләрдән
Тукылган Иленңдә, юк,
ялгыз булмассың.
Син, сирәк булса да, төннәрен,
юксынып,
Яңгырлар аркылы
сәламең юлларсың.
Һәм – карлар коярсың...
Ул карлар, җылытып,
Кумәрләр эзләрең, күзләрем үбәрләр.
...Мин, җиңеп куркуым,
Кагылам... кулыңа.
Алмалар тупырдый.
Шыгырдый түбәләр.

Кичү

Җылыга, җылыга күнекмә,
Күнекмә ышыкка, бушлыкка.
Йөрәкне йөрәккә ялгыйлар
Кайчакта ялгызлык кушып та.

Киектәй эзеңнән йөгерәм,
Киектәй багасың үзең дә.
Бу дөнья, мәңгелек сораудай,
Төбәлгән син булып күземә.

Мин аңа җаваплар табалмыйм.
Җаваплар, мөгаен, кирәкми.
Ирекка җибәрәм – үземне
Һәм синең талчыккан йөрәкне.

Бер – дөнья.
Ә юллар – бихисап.
Кинәнеп сулыймын март җилен...
Артыгын даулама дөньяда,
Артыгын яулама. Һәм – кимен.
Корбаны да булма кемнеңдер,
Һәм булма җанына бишек тә.
Йөрәкне йөрәккә ялгыйлар
Кайчакта сөюне кичеп тә.

Яшел диңгез

Олы болын.
Үләннәрнең
Җиңел сулаган мәле:
Иртәгесен
Ни булса да...
Бу төнгә
Исән әле.

Чык чылата
Керфекләрен.
Коендыра ай нуры...
Күрә алар:
Ызангарак
Яшерделәр
Чалгыны.

Олы болын.
Җиләк кызын
Аерганнар
Тамырдан.
Юата аны
Кырмыска:
– Тәкъдирең шул...
Сабырлан...

Безнең тәкъдир –
Дөнья йөген
Тартып бару...
Син, сеңел,
Табын яме –
Ап-ак сөткә –
Бар һушың
Белән түгел...

Йокы баскан
Чалгыларның
Төшендә –
Яшел диңгез.

...Бар да шундый дөрес монда.
Һәм бар да – шундый тигез.

Яланаяк

Мин бәхетне яланаяк күрәм.
Мин бәхетне күрәм – үтәли.
Балачагым болынында бабам
Әле һаман печән күбәли.

Әле һаман чыжлый чалгылары.
Әле һаман шул ук – иманы.
Мин ызаннар кичәм:
...Икәү... өчәү...
Тик аңламыйм һаман дөньяны.

Кануннарын аның.
Алымнарын.
Юк, аңламыйм.
Кем соң аңлатыр?!
– Бары киткәч, – ди ул, –
кемдер безне
Бүгенгедән күбрәк яратыр...

Җирдә чакта аңлау бирелмәгән,
Бирелмәгән никтер адәмгә.
И сихәтле бәхет!
Ул – хәләл дә.
Кем өчендер – үтә хәрәм дә.

Бәхет өчен туганмы соң без, дип,
Яланаяк – киртләч үрләргә...
Кирәк, бәлки, безгә тик – яшәргә.
Кирәк вакыт килгәч – үләргә.

яшел күзле...

феи августа так свободны
и так легки,
их духи немного горчат
ЛЕМЕРТ

алар бии таңга кадәр болыннарда.
сокланасың: менә ләса – яшьлек үзе!
алар елый, яшеренеп үләннәргә –
үзләредәй яшел күзле, яшел күзле.

алар көлә – кыңгыраулы үзән
буйлап
уйнап кына йөгерек җил узганмыни!
алар китә, артларыннан
эз калдырмый,
берәүгә дә үч сакламый,
кызгандырмый.

алар көтә – айга, елга сузыламы,
сузыламы бер гасырга, аннан ары...
алар кача кешеләрдән ераккарак,
сизә калса сүзләрендә ялган барын.

алар белә: югалсалар – ахыр булыр.
төсләре дә онытылыр, үзләре дә.
дөнья биер, шашып-шашып,
үз көенә,
бик иске дәрт күмерләнер
күзләрендә.
...бераз кырку тоелыр ул август төне:
нәкъ ирек һәм җуелмаган
хәтер төсле.
һәм оза-а-ак чык кипми торыр
үләннәрдә –
кемнедер бик хәтерләтеп –
яшел күзле.

* * *

«Без югалтыр һәм аннан
сагыныр өчен яратабыз...»
Синең хаттан

...һәм – һәр төндә төшләренә
кайтыр өчен –
яз катыш көз, көйгән дәфтәр бите
булып...
кашкарыйлар тотып өйдән чыга
улың,
тирбәлгәндә сәгать теле,
җиде тулып.

һәм учыңа алып учын –
син чыгасың...
парктагы эскәмиядә көтәм сезне.
син, узганда, сизгән кебек,
борыласың,
сукранасың эчтән генә, тиргәп көзне.

көтәм сине аннан мәктәп
бакчасында,
чыгасың син, кулың җиңгә
яшергәнсең.
өркетүдән куркам...
әмма, өркетмичә,
белмим, сиңа хәзер
ничек дәшәргә соң?!

син кичләрен өйдә шәмнәр
кабызганда,
сүндерүдән куркам,
тыным кагылудан...
һәм, чәчләрең тараганда,
якынаеп,
көзгеләрдә
ялгыш кына чагылудан.

син югалттың мине.
ә мин...
ә мин – таптым.
күр, улыбыз йоклый,
төше тәмле... татлы...
син дә йокла!
ә мин сакта торам.
синең
киләчәгең
минекеннән
күпкә якты.

Туым 2014*

Ишегеңә – бер уч кыңгырау-гөл,
Тәрәзәңә – карлы йомарлам...
Йолдызчылар әле берни белми,
Тик килере Аның юралган.

Декабрьнең әкият китабында –
Безгә дигән карлы пулатлар,
Очраклы бер мәҗлес табынына
Кемдер бармакларын тураклар...

Йә яндырыр чәчен... Түгәр чәен –
Кубарылыр җирдә чир-зәхмәт.
Син ваемсыз гына: «Кәтик... –
дисең. –
Ул тугач та иңәр мәрхәмәт...»

Боз шуабыз, көртләр актарабыз,
Яндырабыз шәмнәр төн ката.
Үлемне дә җиңәрбез күк хәтта –
Узгынчылар безгә шакката.

Декабрьнең әкият китабында
Юк җинаять, димәк, юк җәза...
Хәер эстәп йөргән карчыклар тик
Имәндерә: «Бирче... җеназа...»

Үлемсезлек түгел күзләрендә,
Шомлы кара дар, йә күләгә.
Сукыр тиен сузам – кемгә кайсы
Гамәлләре өчен түләнә?

Һәм кузгалам – ачам яңа битне:
Абзар. Салам. Пыскый чыралар...
Без – гап-гади адәм генә әле...
Йолдызчылар юлга чыгалар.

____

*Туым – керәшеннәрдә Раштуаны шулай атыйлар.

PRESSA.RU



Хәмидә ГАРИПОВА

САНДЫК

(Хикәя)

Кояшлы матур язгы иртәдә Сәмига карчык сандыгына таслап тутырылган үлемтекләрен җилләтергә ниятләде. Оешып, сөрсеп ятмасыннар әле. Үзе генә белгән төшкә – түр тәрәзә кашагасы өстендәге бүрәнә ярыгына кыстырып куелган ачкычын үрелеп алып, төсе уңган сандыгы өстенә иелде, корама япмасын дүрткә бөкләп, бер читкә алып куйды. Карчык кытыршы бармаклары белән сандык өстен сак кына сыпыргалады. Заманында күз явын алырлык шушы затлы җиһазны әтисе Йөгедни базарыннан алып кайтып биргәндә, өлгереп пешкән җиләк кебек кыз иде бит ул! Биленең бал кортыныкыдай нечкәлекләре, чем-кара калын толымнарының тез астына чаклы төшеп торулары! Канәфер чишмәсеннән иелеп су алганда, көмеш чулпыларының бер-берсенә бәрелеп көңелле генә чыңлап куюлары! Мөлдерәмә тулы чиләкләрен чайпалдырмыйча, кәс-кәс атлап, тар сукмактан менгән чагында, искәрмәстән, таллык арасыннан елмаеп килеп чыккан Сәлимгәрәйгә оялып кына күз сирпүләре!

Эшкә уңган иде үзе: кулы-кулга, теле-телгә йокмады. Аның пөхтәләп, затлы итеп чиккән кызыл башлы киндер сөлгеләрен елның-елында Сабан туенда беренче килгән ат муенына бәйләүләре үзе ни тора! Сөеклесе мәйданда батыр калганда, кызның түбәсе күккә тиюе онытырлыкмы, йә? Пар атларда, гармуннар уйнатып, авыл урамнарын ду китереп, Балыклыга килен булып төшүләре тагын! Дәрте ташып торган яшь кәләш, ире каршында тай сыман биеп, елмаеп кына йөри, кайнанасына ярарга тырышып, бер урынына биш баса иде. И-и гомеркәйләр, аккан судай тиз уза да соң! Сәлимгәрәй белән чәчен чәчкә бәйләгәненә алтмыш биш ел гомер узган да киткән. Кайчандыр балкып торган, зәңгәр өслеге көмешсу калай тасмалар белән бизәкләнгән сандык та кортканың үзе белән бергә картайган, коргаксыган шул инде. Вакыт – аяусыз, аңа каршы барып булмый, берни хәл итә алмыйсың...

Сәмига кортка арык аркасын иске сандыгына сөяп, уйга калды. Хәзерге тормышының ни яме бар соң? Карты җир куенында. Дүрт улы – дүрт тарафта, бишенчесе – зиратта. Ул картаймыш көнендә болын чаклы зур, коты качкан, шыксыз йортта берүзе иза чигә. Иртән торып: «Нихәл, әнкәй?» – диючесе, чирләп урынга егылса, бер чынаяк чәй ясап китерүчесе юк. Итәк тулы бала үстер дә, берсенең дә рәхәтен күрмә, имеш. Анадан ала да, кола да туа, диләр. Хак сүз. Биш бала – биш холык. Олысы Хәбибулла басынкы, эшчән иде, яшьли кул арасына керде. Тик бәхетен генә корт чакты: моннан егерме ел элек, кордоннан мунча бурасы төяп кайтканда, тайгак юлда йөк машинасы капланып, бүрәнә астында калып гарипләнде. Бәхеткә, хатыны ипле, инва-

лид ирен ташламады, бала урынына карап-тәрбияләп тора. Икенчесе – Сабиры, зур акча эзләп, Себергә китеп гаип булды. Авылда гаиләсе, алма кебек хатыны калды. Бичара Тәскирә киленнең гомере заяга узды, оланнары әтиледән әтисез кимсенеп үсте. Уртанчы малай Илдархан кечкенәдән холыксыз иде, урамга чыкса, калай әтәч сыман теләсә кемгә очып кунды. Әле берсенең авызын җимерә, әле икенчесенең башын тишә. Таш ыргытып, тирә-күршенең тәрәзәсен вату дисеңме, мишень ясап, рогаткадан атып, эт-мәчеләрнең күзләрен чыгару дисеңме... Өстеннән жалу артыннан жалу килеп кенә торадырые. Калага китеп урнашкач та мантымады, хәерсез. Эчеп алган саен, кансызланып, апаларына йодрык уйнатуына түземлекләре төкәнгәч, беркөнне кайнешләре, җыйнаулашып килеп, җизнәләренең арт сабагын укытып киткәннәр. Артыграгын кыланып ташлаганнар, күрәсең: өрлектәй ир, баш миенә кан савудан, вакытсыз җир куенына керде.

Сәмига әби, ябык аркасына таратып бәйләгән яулык чите белән яшьле күзләрен сөртте. И-и ул бала югалту ачысының йөрәкне талкулары! Дошманыңа да кичерергә язмасын! Ул хәсрәтнең тирәнлеген үз башына төшмәгән кеше аңлый аламы соң? Елый-елый сукрая язды, мие түнде. Хәзер ул иртән нәрсә ашаганын да оныта, яңарак кына кулына тоткан әйберен кая куйганын исенә төшерә алмыйча иза чигә. Дүртенче улы – Фәрвазы холкы белән бабасына тарткан – мыштым, йомыкый иде. Үскәндә ата-анасына әллә ни авырлык китермәде: ни бирсәң шуны ашады, нәрсә кушсаң шуны эшләде, теле-теше булмады. Карсак буйлы, төптән юан чыккан абыйларының берсенә дә охшамаган су сөлегедәй буй-сынлы егет, хәрби хезмәттә чагында чая Самара марҗасының үткен кармагына килеп капты. Туган нигезенә унбиш елга унбиш мәртәбә кайтып күренде микән ул? Кайткан чагында, газиз улкаеның чүпрәк сумкасында ике булкидан гайре берние дә булмасые. Әллә килене үтә дә саран, әллә улы мәнсез, белмәссең. Сәмига кортканың марҗа килен Матренаны гына түгел, оныклары Федька белән Ксюшаны күрү бәхетенә дә ирешә алганы юк. Кайсының кемгә охшаганлыгын, кайчандыр улы калдырып киткән кәртечкеләрен карап, төсмерләргә генә кала. Аның каруы, төпчекләре Сәетхан таш астыннан чыккан! Үскән чагында да берүзе бишкә торды. Чибәрлеге, чаялыгы ягыннан Сәмиганың үзенә тарткан. Ул янып торган шомырттай кара күзләр, болыттай күпереп торган дулкынлы куе чәчләр, энҗе бөртекләредәй тезелгән тип-тигез, ап-ак тешләр, дисеңме? Бер елмаеп куйса, йөзеннән күзеңне ала алмассың! Сөйкемле сөяге бар шул аның. Ул телгә осталыгы тагын! Үзенә кирәктә, сандугач булып сайрый. Ир-атка алай ук матур булмаса да ярыйсы икән кана. Шул чибәрлеге аркасында, аның төпчеге күпме хатын-кызның башын әйләндерде икән? Өйләнә дә аера, йә үзен куып чыгаралар, язгы иләс күбәләк кебек, чәчәктән-чәчәккә очып куна. Һәр ояда ятим бала калдырмаса бер хәл. Шул гөнаһсыз сабыйлар кызганыч. Аның пүтсезгә чыгуына Сәмига үзе дә гаепле бугай. Тасма теле белән ярап, Сәетхан әнисенең иркә песие булып, эш сөймичә үсте. Ире гелән ачулана килде: «Тагын мин кушканны үтәмәгән! Эшләмәгән – ашамый! Яклап бозма, азындырма малайны! Үз башыңа имгәк үстерәсең киләме?» – дип битәрли иде, мәрхүм. Кырыкка җиткәндә, бик авырлык белән тапты шул ул Сәетханын. Аның белән йөкле чагында, ризык талымлап җәфа чикте. Беркөнне кеше бакчасыннан кара чия урлап ашыйсы килде, әйтерсең, үзләренеке юк. Тулгагы да абыйларыныкыннан күпкә ачырак булды. Хатын ике тәүлек яшәү белән үлем арасында тартышкач кына, бәләкәч якты дөньяга аваз салды. Ул ничек кадерле булмасын, ди, инде! Карт сыер бозавын ялап туймагандай, Сәмига да нәни улкаен иркәләп-сөеп мәш килде, дүрт яшенә чаклы оланын күкрәктән аермавы бер киртәгә дә сыймый иде инде үзе. Урамда уйнап кергән тупырчык кебек малайның, әтисе күрмәгәндә, анасының күлмәк сәдәфләрен нәни куллары белән ычкындырып, абыйларыннан оялмыйча, чупы-чупы ими суыруын әйт син аның! Ашап туя да: «Әннә, ләхмәт!» – дип елмая. Шул сүзләрне ишетү өчен бәхетле ана әллә ни бирергә риза иде. Итәктә чакта сөйдерә, аннан төшкәч көйдерә икән шул бала кыйтысы. Юкка гына: бала-чага, димиләр. Ничек кенә чага әле! Сәетханының кыңгыр эшләре сизелсә дә, анасы ут өертеп орышмады, гел яклап, атасыннан яшереп килде. Абыйларына эләккәләгән сыек чыбык, төпчегенең сыртына бер мәртәбә дә сызгырып төшмәде...

Хатирәләргә бирелгән карчык, исенә килгәч, аякларын оетып, үзенең нишләп идәндә утыруына аптырап куйды. Кулындагы ачкычына күз төшергәч кенә, кеткелдәп көлеп җибәрде: «И-и хәтерсез Хәтирә, димәсәң. Тәмам ачы камырдай җәелгәнмен. Моңарчы әйбер-караларымны кояшка элеп бетерә язган булырыем...» Ул җай белән генә ачкычны йозак тишегенә таба шуыштырды, әмма куллары калтыраганга күрә, оясына туры китерә алмыйча интекте. Күзлеген киеп килгәч кенә, теләгенә иреште. Бала хәсрәтеннән елап, күзләре җетелеген җуйды шул, яшь чагында ай яктысында чигү чиккән Сәмига димәссең.

Кортка, әгузе-бисмилласын әйтеп, сандыкның капкачын ике куллап күтәреп, ипләп кенә диварга сөяде. Чү, бу ни бу? Кинәт карчыкның тез буыннары йомшарды. Күз алдыннан аллы-гөлле күбәләкләр биешеп узды. Карчык, өнсез калып, сандыгы янәшәсенә идәнгә лапылдап утырды. Бераздан: «У-уф!» – итеп сулыш алды. Сәмиганың юк кына пинсәсен авызыннан өзеп, ни гомер бөртекләп җыйган, ваклатып, санап, сары кәгазь капчыкка төреп салынган сәдака акчаларыннан, үлемтеккә хәстәрләп куелган сөлге-тастымалларыннан, марля, ситсы төргәкләреннән, егерме метрлы кәфенлек бөзеннән, ак җирлектә зәңгәр шакмаклы яңа йомшак одеалыннан җилләр искән... Гүя бу мизгелдә карчыкның болай да миңгерәйгән башына дәү күсәк белән ордылар. Колаклары шаулый башлады, күз аллары әлҗе-мөлҗе килде. Хәсрәт-борчулардан таушалган йөрәге калтыранырга кереште. Нәрсәдер тамак төбен ачыттырып, пешереп

PRESSA.RU

алды, күзен яшь пәрдәсе каплады, сул як яңагы тартыша башлады. Кортканың башын яман гүелдәтеп, хәвефле уйлар көтүе йөгерешеп узды: «Үлә-нитә калса, ничек күмәрләр? Салкын караңгы гүргә шыр ялангач килеш илтеп салсыннармы? Алла язмаганны! Өстендәге күлмәге белән җиргә индермәсләр ич инде? Урыслар кебек агач табутка салсалар, шәрәлеге кешегә күренмәсие күренүен. Тәүбә әстәгъфирулла! Ул бит кяфирә түгел...»

Бераз сулу алгач, карчык көч-хәл караватына барып ауды. Миен бер генә уй бораулады: кем эше? Кайсы имансызы аны кычкыртып талап чыккан? Яше сиксәнгә җитеп килүче кортканың соңгы малына кул сузарга кем җөрьәт иткән? Алла сугар дип тә курыкмаган. Ул торып утырды. Күзләрен челт-мелт йомгалады. Хәтерен эшкә җигәргә маташты. Өйгә чит-ят кеше аяк басмаганына биш былтыр. Ачкыч урынын үзе генә белә. Аның зиһене ачыла төште. Тукта, ничек була инде бу? Бикле йозакны үзе ачты лабаса! Ул идәнгә төшеп басты, аякларының калтырануын тойган хәлдә, янәдән сандыгы янәшәсенә чүмөште. Бур сандыкка ничек кергән? Ул йозакны кабаттан күздән кичерде, әмма шикле нәрсә сизенмәде. Сандыкның дивар ягындагы такталарын берәм-берәм капшарга керешкәч кенә, эшнең нәрсәдә икәнлеген чамалап алды. Кортканың кулы тигәч, коргаксыган өч такта, урыныннан кымшанып, җиңелчә шыгырдап, бер якка кыйшайды. Куш йодрык сыярлык ярык пәйда булды. Менә сиңа мә! Карак сандыкның артын каерып кергән. Менә, тырналган эзләре ярылып ята. Тимер тыгып каерганнар булса кирәк. Соңгы кайтуында Сәетханның келәттән кадак суыргыч алып чыгып килүен искәргән иде бит! Аптыраудан Сәмиганың тешсез авызы ачык калды:

– Мәлгунь! Беркем түгел, Сәетхан эше! Баш төзәтергә акча даулап маташканые. Бирмәдем. Пинсәмә утын кайтарттым. Бер тиен маям калмады, дип, абзар буендагы әрдәнәгә төртеп күрсәттем. Мунчага кереп киткәнемне генә сагалап торган, җирбит! Күзләре бәк яман тонганые шул. Чал чәчле анасын кычкыртып таламаса... Кулы корысын! – дип каргар идем, үз балам, кыйты булса да, бәгыремнән өзелеп төшкән үз җимешем. Болай да бәхетсез ич ул бичара. Ни торыр җире юньле түгел, рәтле-башы эше, гаиләсе юк. Йөри шунда чүлдәге дүңгәләк кебек, җил кая иссә – шул якка тәгәрәп... И бала, бала! Бигрәкләр дә юньсезгә әйләндең. Мин үлгәч, кемгә сыенырсың? Әле кайтып егылырга, кәйме-яхшымы, анаң бар...

Сәлимгәрәе дөрес әйткән: малаен тиешсезгә яклап, гаебен яшереп, иркәләп бозып, картаймыш көненә баш казыгы ясаган ич ул! Мине талаганны, әллә башкалар малына кул сузмаган дисеңме? Үскән чагында ук төрлесен күрсәтте инде. Сукыр Әкрәме белән икәүләп күл буендагы чирәмлектән кеше үрдәген тотып, учакта кыздырып ашаганы булды. Анасы Әкрәмнең бурлыгын белеп алгач, малаеның ыштанын төшереп, каравыл акыртып, йомшак җирен карт кычыткан белән пешекләде, ә Сәмига, төпчек улының арт сабагын укытасы урынга, ул чакта аны мунча чоланына яшереп калды...

Кортканың үтереп башы сызлый башлады. Дару төймәсе капты да ястыгына түнде. Шул чакта аңа гыйбрәтле төш керде.

...Иренең тегермәнче булып эшләгән чагы икән. Сәлимгәрәенең онга баткан фуфайкасын киеп, Бәрле буендагы таллыкка ышыкланып кына, кич кырын күз буылгач, Сәмига тегермән буасына таба элдертә, имеш. Кулында потлы чиләк. Менә ул, ялтын-йолтын карангалап, тегермәнгә керде. Дивар буйлап эрелевәклы капчыклар тезелешкән. И-и, монда күпме байлык! Һәркайсында яңа тарттырылган ефәктәй йомшак, хуш исле бодай оны. Күптән түгел колхоз хезмәт көненә ашлык өләшкәние шул. Авылдашлар шуны тарттырырга көнозын чират тора. «Учырты» җитмәгәннәрә, Сәлимгәрәйне гозерләп, ашлыкларын төнгелеккә калдырып китә дә, онын иртән иртүк килеп ала. Сәмига, тиен җитезлегендә капчыклар арасыннан үтеп, һәркайсыннан җәлт кенә берәр соскыч он батырып алып, чиләгенә сала барды. Чү, бу нинди кырык ямаулы күтәмкә тагын? Капчык димәсәң, хәтере калыр. Оны да төбендә генә. Ай-һай, моның белән генә кыш чыгулары! Кая, карыйм әле, кайсы хәчтерүшнеке икән? Яшел буяу белән М. дип язылган, каз тәпиенә охшаш тамгасы да бар. Ут күршесе Ата каз Мөнирәсенеке икән, болай булгач. Үткән язда кар суында кер чайкаганда туңып кайтуы аркасында үпкәсе кабарып, җәй буе чирләп, эшкә чыга алмый ятты шул. Шуңа тияре дә аз. Җитмәсә, балалары ишле. «Әллә аныкына сузылмаскамы?» – дигән уй баш калкытса да, чиләге тулыр-тулмас икәнлеген күргәч, Сәмиганың туймас нәфесе аек акылын бик тиз сугып екты. «Тапмасыные җиде бала, хәерче арттырып! Аның ире суга батып үлгәнгә мин гаепле түгел!» Зур соскыч сәләмә капчык төбендәге онны батырып алгач, Сәмиганың чиләге мөлдерәмә тулды. Чиләк өстенә балаитәкле чәчәкле алъяпкычын каплап, хатын кайтырга чыкты. Бәхеткә, кеше-кара очрамады, әмма ян капкадан керәм дигән мәлдә коты алынды: тешләрен яман ыржайтып, аның өстенә кап-кара сукбай эт ташланды...

Кортка саташулы төшеннән шабыр тиргә батып, куркып уянды. Озак кына исен җыя алмый яткач, аптыравыннан чак кына кычкырып җибәрмәде. Төш түгел ич ул! Моннан утыз җиде ел элек өндә булып узган вакыйга бөтен нечкәлекләре белән исенә төшкән! Иртәнге якта иренә кайнар кабартма илтергә баргач, Ата каз Мөнирәсенең елый-елый тегермәнчене каргаганы кортканың колагына янәдән ап-ачык итеп ишетелгәндәй булды:

– Ятим сабыйлар хакы тамагыгызга тыгылсын! Хәрам ашап мантымассыз! Кеше хакын тыгынып үскән залимнәрегезнең үз башыгызга тимер казык булганын күрсәмие! – дип елады бичара тол хатын.

Берни аңышмаган Сәлимгәрәй ык-мык итте. Хатынны тынычландырырга, үзенең гаепсез икәнлеген расларга маташты. Сәмига сүзгә кушылмады, башын юләргә салып, шым гына тыңлап торды. Иренә тиз генә



Рәсем: Наталья Васильева

төенчеген сузды. Хәләле аны-моны сизгәләгәнче, ай күрде-кояш алды дигәндәй, күз алдыннан гаип булды.

Кортканың миендә вәсвәсәле уйлар кайнады. Ул чакта шайтан үзе котыртып, Сәмиганы языклы юлга кертте, ахрысы. Юкса тамаклары алай ук ач түгелие лә. Авылда тегермәнчегә хезмәте өчен «көрәк оны» биреп калдыру гадәте бар. Ә ул күрәләтә каргыш җыйды. Мөнирәнең каргышы агач башына түгел, Сәлимгәрәйнекеләрнең, бигрәк тә аның гөнаһлы хатынының башына төшкән түгелме соң? Фәрештәләрнең «Амин!» дигән чагына туры килгән, күрәсең. Теге хәрам оннан пешерелгән кабартма, бөккәннәр белән төпчегенең бәби чәен үткәргәннәрие шул. Әллә шуңа Сәетхан кечкенәдән кыек куллы булдымы икән? Әллә төпчеген үзе артык үсендердеме? Малае күршеләрнең тавык йомыркасын чәлдергәндә, анасы шуны кыздырып бирде. Торна Ризваннары янган кичтә, су буеннан таптым, дип, улы корымлы җиз самавыр күтәреп кайтты. Аның бер чиләк су сыйдырышлы булуына сөенеп, Сәмига теш сындырып кергән «табылдык»ны су буена алып төшеп, ком катыш карга миләше белән белән әйбәтләп ышкып юып, көзгедәй ялтыратты да, өстәлгә менгереп утыртты. Иренә: «Мөрәле базарыннан алып кайттым», – дип ялганлады. Югары оч Тугани апалары килен төшергән көнне үсмер Сәетхан шул йорттан кодалары малаеның матаен чәлдерде. Сәмига бу очракта да үсмер улының кулына сукмады. Киресенчә, хәерхаһлык күрсәтте: аталары эштән кайтканчы, матайны сүтеп, абзар артындагы салам күче эченә яшерергә булышты. Берәр ай чамасы вакыт узгач: «Симәки урысыннан бер чирек көмешкәгә алыштырып, бер дигән матай алып калдык», – дип, иренең күзенә төтен җибәрде. «Төпчегем абыйларына охшамаган. Аяк өсте йоклап йөрми. Ни күрсә дә, өйгә ташый. Үземә тарткан. Бусы көн итә беләчәк!» – дип куанды ана.

Дөнья малы – дуңгыз каны. Кеше хакы белән мантып булмый икән. Ул чакта бигрәкләр дә ахмак булганмын инде! Ирем дә җебекнең-җебеге ие. Ни сөйләсәм, шуңа ышанып йөрде. Ул чакта: «Матайны каян алдыгыз, хәзер үк шунда илтеп куйган булыгыз! Юкса, икегезне тиң каеш чыбыркы белән ярам!» – дисә, артыгын кылана алмаслары. Улымның бәхетен кеше рәнҗеше җимерде. Терсәк якын да бит, тешләп кенә булмый. Әле ул гөнаһларым өчен, Ходай каршына баргач җавап тотасым бар. Оланыңны ник хәрамга авызландырдың? – дип, зобанилар кайнар җәһәннәм кисәве белән кай җирләремне яндырыр икән? Карак малаемның башыннан сыйпаган кулларымнымы? Әллә угрыны бәладән йолып калган тасма телемнеме? Карчыкның авызы кипте. Җиз самавырга күзе төшкәч, куркуыннан тәне чемердәп куйды. Чиләктән чишмә суы алып эчте, тик сусавы басылмады, гүя аның эче дөрләп яна иде.

Хәвефле уйлары янәдән Сәетханына барып тоташты. Кыек кулы аркасында, аны каладагы эшеннән бик тиз кудылар. Хезмәт хакы алган көнне, бергә эшләгән егетләрнең кесәсен чистартып тотылгач, өч ел «условно» чәпәделәр. Судта бәлагә тарыган улын яклап берәр җылы сүз әйтергә җыенган иде ул, әмма тимер рәшәткә

PRESSA.RU

артында башын аска кадап утырган Сәетханының усал күз карашын, кысып йомарланган йодрыкларын күргәч, авызын ачарга базмыйча, урындыгына сеңде. Әйтерсең, улы бөтен кеше алдында анасының битен ертып: «Син генә гаепле! Моннан чыгуга, буып үтерәм!» – дип, ачыргаланып кычкырырга җыенган иде.

Сәетханның өйләнүе дә кешенеке төсле булмады. Казан кызына йортка керде. «Өебез зур, хатыныңны авылга алып кайтып торасыңмы әллә?» – дип сүз катып караганые, малае анасын өреп кенә очырды. Килен кем дә, син кем, янәсе. Калада үскән былбыл баласы, салага кайтып, тавык сыман тиреслектә казынмаячак, имеш. Хәер, эш сөймәс кияүне, мул ризыклы, иркен тормышлы фатирда озак тотмадылар, ут өертеп куып чыгардылар. Дөресрәге, угры ир үз ризыгын үзе кисте. Әүвәл, кибет директоры булып эшләүче кайнанасының алтын йөгертелгән кашык-чәнечкеләрен, Кытай фарфорыннан эшләнгән бик затлы чәй сервизын ломбардка илтеп тапшырды. Хуҗалар, аны-моны сизенеп, йомгакның очын сүткән арада хатынының алтын-көмеш зиннәтләрен, кайнанасының энҗе-мәрҗәннәрен ярты бәясенә чегәннәргә аткарып, ахмак кияү лаякыл эчеп кайтып ауды. Аш атканга таш атучы имгәкнең артына типсәләр дә, судка биреп маташмадылар. Хәлле кодаларга, югалган малга караганда, кеше арасындагы абруйлары кыйммәтрәк иде, күрәсең. Тишекле бер тиен кебек ялтырап өйгә кайтып төшкән Сәетхан, атасының Сталинград фронтында кан коеп алган ике ордены белән җиде медален, кәчтүме-ние белән өйдән алып чыгып, бер литр аракыга алыштырды. Бу югалту хакында Сәлимгәрәй 9 Май көнне бәйрәмгә барырга җыенып, кием шкафын ачкач кына белде. Чарасыз калган карт, агарган сакалын йолкый-йолкый, елый-елый хәерсез улына җикеренде:

– Күз алдымнан югал, бәдбәхет! – дип иңрәде ул. – Башың төрмәдә чересен! Җеназама кайтып аяк басасы булма!

Сәмига, гадәтенчә, улын яклап сүз кыстырасы иткән иде. Юаштан юан чыга, дигәннәре хак икән: ярты гасыр бергә тыныч кына гомер иткән карты, үтә дә яман сүз ычкындырды:

– Син генә юлдан яздырдын малайны! Икегезгә дә мәңге бәхиллек бирәсем юк!

Бу җәнҗалдан соң атна-ун көн вакыт үткәндерме-юкмы, Сәетханны кулга алдылар. Үзен яңарак кына эшкә урнаштырган ашханә директорының йортын басарга кергәч, хатыны сизеп алып, полициягә шалтыраткан икән. Погонлы егетләр угрыны кайнар эздән эләктерде. Сәетхан СИЗОда суд көткән арада, хәерсез улы хәсрәтеннән Сәлимгәрәйнең башындагы кан тамырлары шартлап, гомере өзелде. Төрмә кошы атасының вафатын кырыгы узгач кына белде...

* * *

Уйлана торгач, карчыкның зиһене тәмам чуалды. Ул сихерләнгән кешедәй, ни кылганын белмичә, янәдән ачык сандыгы янына чүгәләде. Күз алдында бая төшендә күргән тум-тулы потлы чиләк, төбенә генә он салынган ямаулы капчык пәйда булды. Менә алар, өй эчен ак тузанга батырып, бер-берсен куышып, бүлмә буйлап очып йөрергә кереште. Тузгыган ап-ак он тузаны, нилектәндер, бер дә йомшак түгел икән. Шулар Сәмига тирәли өермә кебек бөтерелеп әйләнеп, рәхимсез рәвештә йөзенә бәрелә, әледән-әле аның чепи күзләренә кылчыктай кадала, борын тишекләренә тулып, сулыш алырга ирек бирмичә газаплый. Көтмәгәндә түр тәрәзә өлгесе чәлпәрәмә килде. Ә аннан яман ыржайган котсыз чырайлы алагаем зур кара эт ажгырып килеп керде. «Хәррам, хәр-рам!» – дип, яман каты өреп, ул кортканың бугазына үзенең сары тешләрен батырды. Карчыкның тыны кысылды, бераздан хырылдый ук башлады...

* * *

Күрше йортта улы-килене тәрбиясендә, кадер-хөрмәттә гомер сөрүче Мөнирә корткa, өйлә намазын укып багышлагач, ишектән кереп килүче оныгы Миләүшәгә ягымлы итеп эндәште:

– Бәбкәчем, син мәктәптән кайтышка бик тәмле итеп балан бәлеше пешердем. Кабартмаларым да бик уңган. Мин чәй яңарткан арада, шушы тәм-томны Сәмига әбиеңә кертеп чыксаңчы! – дип, ак тастымалга төрелгән җылы ризыкны елмаеп оныгына сузды. – Сәдака булсын! Бичара ялгыз карчыкны сөендергән өчен Ходай безне үзе шатландырсын! Ризыгыбызны киң, җаныбызны тыныч, тәнебезне сау-сәламәт итсен! Сиңа тәүфыйкъ-шәфкать бирсен!

Кычыткан чыпчыгыдай җитез кызчык:

– Хәзер, дәү әни! – дип, күчтәнәчне ялт кына эләктереп, күз ачып йомган арада юк булды. Ун гына яшьлек булса да, самими күңелле кыз бала, әбисе әйтмешли, үзенең игелекле эшкә яравына сөенеп, ихластан елмая иде.

Нишләптер, Сәмига күрше кичәдән бирле күзгә-башка күренмәде. Кичтән утын да кабызмады бугай. Әллә чирләп ята шунда, белмәссең, – дип сөйләнгәләп, табын корырга керешкән Мөнирә әбинең уйларын, итәгенә ут капкандай, атыла-бәрелә йөгереп кергән Миләүшә бүлдерде. Кызның куркудан күзләре зур булып ачылган, иреннәре дерелди иде.

– Дәү әни! Сәмига әби әллә нишләгән! Ул шундый куркыныч!

Ашыга-кабалана оныгы артыннан тыраклаган Мөнирә әбекәй, бусагадан эчкә узуга ук, хәлнең яманлыгын чамалады. Уң як күршесенең башы бер якка кыңгыраеп, ләхет авызыдай ачылган алагаем зур сандык эченә салынып төшкән иде. Мөнирә әби саклык белән генә Сәмига кортканың күзләрен йомдырды, көч-хәлгә караватына меңгереп салды, баш яулыгы белән ияген күтәртеп бәйләп куйды. Битенә ак яулык япты.

– Лә Илаһә Иллә Аллаһ! Иннә иләйһи рәҗигун. Йа Раббым, гөнаһларыбызны кичер! Иртәме-соңмы, барыбызга да синең каршыңа җавап тотарга барасы. Берүк Сәмига колыңны да рәхмәтеңнән ташлама!













Тәүфикъ ӘЙДИ

«Сайланма әсәрләр. 1 нче том»

Бу томда автор ның «Елан угы» романы һәм «Божра» повесте урын алган. Анда сүз большевиклар хакимиятенең үз гореф-гадәте, җае, көнкүреше белән яшәп яткан Бохара әмирлеген юк итеп, Россия «ЧК»сының анда яшәүче халыкка көчләп Бохара Совет Республикасын тагуы турында бара. Каһарманнарның килеш-килбәтен, эчке дөньясын, чит бер мохитне күзәтүләре, тормыш-көнкүреш ваклыклары аша сурәтләве белән әсәр бүген дә әһәмиятен югалтмаган.

Рәфкать КӘРАМИ

«Кая чабасың, гомер юртагы?»

Бу роман – «Олы юл да сикәлтәле» исемле трилогиянең өченче кисәге. Беренчесе шул исем белән 2007 елда, икенчесе («Сөеп туймас чакларың») 2011 елда дөнья күргән иде. Роман гыйбрәтле хәлләргә, мәхәббәт маҗараларына, тирән психологик кичерешләргә, тормыш-яшәеш хакында уйлануларга, четерекле вакыйгаларга бай. Китап, һичшиксез, киң катлау әдәбият сөючеләрнең игътибарын җәлеп итәр.

Мансур ШИҺАПОВ

«Яшьлегем эзләре»

«Әйләнеп кайтыгыз», «Туй күлмәге», «Мишәр кызы»... Аның исемен ишетүгә, колакта шушы көйләр яңгырый башлый. Һәркайсы йөрәк түреннән ургылып чыккан, һәркайсы халык җырлары дәрәҗәсендә камил язылган. Һәр җырының, шигыренең үз язылу тарихы бар. Алар белән кабат очрашу укучы күңелендә рәхәт мизгелләр генә калдырыр. М. Шиһаповның яңа бу китабына аның төрле елларда язылган җырлары, автор турында замандашларының мәкаләләре һәм әңгәмәләр дә туплап бирелгән.

Фирая ЗЫЯТДИНОВА

«Мин сине шундый сагындым»

Юкка гына шагыйрьләр «мин – әсәрләремдә» димиләр. Тормышта гап-гади, мөлаем гына булган Фирая ханым да шигырьләрендә әнә нинди киң колачлы, кайнар хисле, хикмәтле сүзле каләм әһеле булган. Аның һәрбер әсәре үзенең «мине» аша дөньяны, кешелекне ачуга багышланган. Ул үзеннән соң якты исем, нәфис шигърият, үзе турында матур фикерләр калдырып китте...
Бу китапта – шагыйрәнең төрле елларда иҗат иткән шигырьләре һәм җырлары.

Гөлназ ШӘЙХИ

«Сыналганнар – сынатмый»

Ул – журналист, һәм ул гел юлда. Дөньяда татарлар яшәмәгән илләр, төбәкләр сирәктер – кая гына барып чыкса да, милләттәшләребезнең күбесе Гөлназны якыннан белә, таный, үз итә. Бу китапка аның юлъязмалары, күренекле шәхесләр хакындагы тәфсилле очерклары тупланган. Укыйсың да, тагын бер кат инанасың: татар дөньясы гаҗәеп зур һәм бай, ә мәшһүр шәхесләребез бихисап. Гөлназның язганнары ихласлык белән аерылып тора: ул кешеләрдән һәм без яшәгән дөньядан яманлык эзләми.

Лилия ДӘҮЛӘТШИНА

«Нәниләргә бишек җырлары, бармак уеннары»

Лилия ханым – Казан шәһәре балалар бакчаларының берсендә логопед булып эшли. Балалар сөйләмендәге кимчелекләр белән ул якыннан таныш. Аларны ничек итеп төзәтү юлларын да яхшы белә. Моның өчен халкыбызның бишек җырлары, теләк-юраулары, бармак уеннары иң кулай дип саный ул. Китап балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән, ата-аналар, балалар бакчалары тәрбиячеләре өчен зур ярдәмче булачак ул.

ТӘЭСИР.



Римма БИКМӨХӘММӘТОВА, журналист



Экстремаль шартларда кешелек сыйфатларын саклап калырга мөмкинме? Авырлык, проблема туганда яки нәфесне кытыклаучы, кызыктыручы вакыйга булганда, без, шәхес буларак, йөзебезне саклап кала алабызмы? Көчлеме без, әллә авырлык каршында җебеп төшәбезме? Шарлотта Роганның «Шлюпка» романы әнә шул сорауларга җавап эзләргә этәрә дә. Кораб суга батканнан соң, диңгез уртасындагы көймәдә 30 кеше кала. Коткарырлар дигән өмет юк... Кемдер акылдан яза, кемдер башын ахмакка салуны хуп күрә, кемдер котылгысызлыкны аңлап, үз-үзенә кул сала, кемдер яшәргә омтылу максатыннан идарәне үз кулына алырга тырыша. Коточкыч хәлгә тарыгач, күңелләрнең караңгы төпкелендә яшерелгән әллә нинди куркыныч сыйфатлары калкып чыга аларның: ни эшләгәннәрен, ни сөйләгәннәрен үзләре дә аңламый. Үлем куркынычы янаганда, ничек тә булса котылу турындагы уй кешене кансыз, вәхши, рәхимсез җанварга әверелдерә. Беренче мәлдә, теге яки бу геройның гамәленә бәя биргәндә, «бу – кабахәтлек», дисең. Әмма үзең ул хәлгә тарысаң, нишләр идең? Хәер, һәлакәтләрдән башка да тормышта йөз төрле вазгыять туып кына тора. Җылы урынга кереп оялау, өскә үрмәләү, ниндидер зур бүләккә, җитәкчеләрнең мәхәббәтенә ирешү... өчен кеше башкаларның өстеннән таптап китү очракларын беләбез. Тормышта ымсынулар күп ул, тик безнең күңел аңа каршы торырлыкмы? Тарих шаһит: туганнарыннан, күршеләреннән нахакка яла ягылып, төрмәләрдә черегән, атып үтерелгән канлы язмышлар бар. Бүген: «Ул вакытта шартлары шундый иде, бүтәнчә мөмкин түгел, яшәргә кирәк иде», – дип канлы куллы җитәкчеләрне, үз көчсезлекләрен, намуссыз эш итүләрен шулай аклаучылар җитәрлек. Яшәргә кирәк, әмма кеше өлешенә кереп, аның үлемендә бәхет кору тормышмы ул?

PRESSA.RU

Мокрина Юрзук һәм Луиджи Педутто. Алар 1943 елда Австриядә, хәрби әсирләр өчен лагерьда очрашалар. Яшьлекнең үз кануннары: ул туплар гөрелтесенә дә, ачлы-туклы йөрүгә дә, кияргә матур кием-салым булмауга да карамый – егет белән кыз бер-берсенә үлеп гашыйк була... Үзләрен язмышның нинди олы сынавы көткәнен белмиләр шул. Сугыштан соң Луиджига сөйгәне белән Украинага китәргә дә, Мокринаны үзе белән Италиягә алып кайтырга да рөхсәт итмиләр... Илләр арасындагы ябык капкалар аша очып кына чыгарга канатлар юк – гомер аерым-аерым уза. Унбиш ел элек Луиджи, хатыны үлеп тол калгач, беркайчан исеннән чыкмаган беренче мәхәббәтен эзли башлый. Өметләр өзелде дигәндә, язмыш аларга соңарып кына бүләк әзерләгән булып чыга: Беренче каналдан барган «Жди меня» тапшыруы Мокрина Юрзук белән Луиджи Педуттога бер-берсен табарга ярдәм итә. Алтмыш елдан соң, икесе дә туксанга җитеп килгәндә...
Аларның гомер буена сузылган мәхәббәтләренә багышлап, Киев шәһәрендә «Мәхәббәт тарихы» дигән һәйкәл ачыла. Хәер, Мокрина белән Луиджига гына түгел, сугыш аркасында бергә була алмаган барлык парларга куела ул. Ә андый ярлар аз түгел. Бу язма да шундый тарихларның берсе турында.



«ДӨНЬЯЛЫКТА БЕРГӘ БУЛА АЛМАДЫК...»

«Яшел аклан» санаторие. Бүлмәдә бөркү. Йокы алмый. Ишекне сак кына ачып коридорга чыктым. Моң агыла, ачык тәрәзәләрдән кергән төнге җил битләрне иркәли. Тәрәзәгә якынрак киләм. Пәрдәләр артында Мөхәммәтҗан бабай моңаеп утыра.

– Йоклап булмыймы?

– Бөркүрәк шул, – дим.

Озын буйлы, киң җилкәле мәһабәт гәүдәле ир кешенең безнең районнан булуын белеп, моңарчы да исәнләшеп үтә идем.

– Сез дә йокламыйсызмы? – дип сүзне ялгарга тырыштым.

– Әйе, авыруым көчәеп китте. Үкенечле яшьлек мәхәббәтемне хәтерләп күңелем тулды әле. «Рамай» җырының сүзләрен хәтерләргә тырышам.

«Йә Хода, күңел картаймый шул, һаман яшьлек мәхәббәтен сагына», – дип көлемсерәп куйдым.

– Алай карама, кызым. Язмыш дигән нәрсә бик мәрхәмәтсез ул. Үкенгән, үз-үзен кызганган мизгелләр һәркемнең тормышында була. Күңелдә бер-бер артлы хатирәләр яңара. Иренмәсәң, тыңла, барыбер йоклый алмый йөрисең, – диде Мөхәммәтҗан бабай.

– Совет армиясендә хезмәт иткән чагым. Авылдан килгән хатта безгә мөгаллимә булып районыбызның ерак бер авылыннан чибәр кыз килүен язганнар иде. Авылыбыз кечкенә безнең, башлангыч мәктәптә бер генә укытучы укыта иде. Эх, тизрәк күрәсе иде шул чибәркәйне.

Ак карларга күмелеп тынып калган авылыбызга отпускага кайткач, туган-үскән йортыма күренеп кенә чыктым шикелле. Аякларым үзеннән-үзе дәү әниләрем йортына атлады. Теге кызның дәү әниләрдә яшәвен белә идем инде.

Нинди икән ул укытучы кыз? Менә таныш җилкапка, карлар көрәлгән, тап-такыр сукмак йортка алып килә. Ишекне ачып эчкә үтәм. Дәү әнием мич алдында коймак пешерә. Мине күрү белән «Мөхәммәт балакаем!» – дип кычкырып җибәрде, кочаклап алды, ябык куллары белән аркамнан сөя-сөя сәкегә утыртып, исәнлек-саулык, хәл-әхвәл сорашырга кереште. Үзем дәү әни белән сөйләшәм, күзләрем белән укытучы кызны эзлим. Өстәлдә китап-дәфтәрләр өелеп тора, ә үзе күренми. Самавыры кайнап чыккач, дәү әни: «Миндә укытучы кыз яши, чәй эчәргә аны көтик инде», – диде. Шунда ишек ачылып китте һәм салкын һава ияртеп, өйгә 17-18 яшьлек кыз килеп керде. Ак мамык шәлен, киемен салгач, минем белән килеп күреште. Йә Ходай, кешегә гүзәллекне биргәч бирә икән! Битләре алсу алма, кашлары – карлыгач канаты, зәңгәр күзләр, пешкән чия төсле иреннәр. Бетте баш – мин үлеп гашыйк булдым.

Киенеп клубка таба атладык. Мин армиягә киткәнче үк иске мәчетнең бинасын клуб иткәннәр иде. Ул тагын да искергән, тагын да ныграк кыегайган кебек күренде. Янында балкып торган чибәр кыз барында клубның шыксызлыгы күренәме?! Тальян гармун алып уйнап җибәрдем. Клубка кызлар-егетләр җыела башлады. Сөйләшәләр, көлешәләр. Минем йөрәк урынында түгел. Тәнгыймәнең егете бармы икән? Бию көен уйнап җибәрдем. Бик матур бер кыз атылып чыгып бии башлады. Ныклап карагач, аның Сания икәнен аңладым. Ул, биеп, минем янда утырган Тәнгыймәгә килеп басты. Тәнгыймә бөтерелеп-бөтерелеп биеде дә Нәсимҗанны чакырды. Үзем гармун уйныйм, үзем Тәнгыймәне югалттым. Миңа бик күңелсез булып китте, гармунны куясым килә, ләкин булмый, чөнки яшьләр очыпдәртләнеп бииләр. «Җитәр, арыттык Мөхәммәтҗанны», – дип, Сания туктатты уенны.

Тәнгыймәне эзли башладым, бер якта да юк, күренми. Нәсимҗан белән чыгып киттеләрме икән? Күңелгә көнче корты керде. Клубтан чыгып, дәү әниләргә таба атладым. «Мөхәммәтҗан, көт әле», – дип, артымнан Сания куып җитте, култыклап алды. Дәү әнигә минем язган хатларны укып, ул әйтеп торганнарны миңа хат итеп яза иде Сания. Мин армиягә киткәндә бәләкәй генә бер кыз иде. Нинди чибәр, кыю булып үсеп җиткән.

Санияне озатып куйдым да, дәү әниләрнең тәрәзәсендә ут яктысын күреп, тәрәзәдән карадым. Лампа яктысында дәфтәрләр тикшереп утыра иде Тәнгыймә. Әллә елый инде, әллә бик арыган, өстәлгә башын салды. Бераз шулай утыргач утны сүндерде. Йөрәгемне утка салдың син, кызыкай! Үзем Санияне озатып кайтып киләм, үзем сине уйлыйм, сине күрәсем килә.Ниләр бар икән синең йөрәгеңдә?!

Иртән балта, пычкы алып дәү әниләргә киттем. Тәнгыймә мәктәптән кайтканчы утыннарны кисеп куйдым. Мин утын яра башлагач, Тәнгыймә дә чыкты. Аңа кырыйлап кына күз салып алам. Бик оста яра иде ул утынны, ирләр эше дип тормый, авыр булса да сынатырга тырышмый, сизеп торам. Шулай әйбәт кенә берберебездән калышмый эшләгәндә бер зур гына агач түмәре Тәнгыймәнең аягына килеп бәрелде. Тәнгыймә кычкырып җибәрде.

Бер карауда аңладым – бу ул иде, мин эзләгән сылу, минем мәхәббәтем, язмышым.

Мин аны тиз генә йөгереп килеп кочаклап алдым. «И Раббым, шушы гүзәл затка өйләнеп яшәсәм иде, минем балаларымның әниләре булсын иде, иртән елмаеп безгә чәй әзерләп йөрсен иде», – дигән уйлар минем башымнан йөгереп үтте.

Икенче көнне дәү әнием Тәнгыймәнең үз авылларына кайтып киткәнен әйтте. Мин телсез калдым. Нишләп кайтып китте икән ул? Көннәребез санаулы гына бит, – Мөхәммәтҗан абый туктап калды, авыр итеп көрсенеп куйды. Тагын сүзен дәвам итте. – Сөйгәнемнең кайтып киткәнен ишеткәч, кич буе тилмереп йөрдем, үз-үземне кая куярга белмәдем. Аулак өйгә чакырдылар, бардым, ярсып-ярсып гармун уйнадым. Тагын Санияне озатып куйдым.

Иртәгәсен Тәнгыймә килде. Түзмәдем, барып кочаклап алдым.

Сөйләшеп киттек. Бик яхшы күңелле кыз икәненә тагын бер кат инандым. Мин кире хезмәткә киткәндә без Тәнгыймә белән бер-беребезне шулкадәр ярата идек, ул минем хезмәтне бетереп кайтуны көтәргә, кайткач, туй ясап, калган гомеребезне бергә-бергә тату гаилә корып яшәргә вәгъдә бирде.

Ләкин яман сугыш чыгып, өметләребезне чәлпәрәмә китерде.

Мин хезмәт иткән часть сугышка кереп китте. Тәнгыймә белән хат алышу тукталды. Саниянең хатлары буенча мин Тәнгыймәнең сугышка киткәнен белдем. Дөнья буталды. Тәнгыймәнең әниләренә хат язып, аның адресын алдым. Хат язып җибәрдем, ләкин җавап булмады.

...1944 елның көз ае. Мин авыр яраланып госпитальдә ятам. Башыма төрле уйлар килә. Сания авыл хәбәрләрен сөйләп, еш кына хат яза, кемнәр яраланып кайткан, кем үлгән. Ә Тәнгыймәдән бер хәбәр дә юк. Азрак терелеп аякка баскач, Тәнгыймәнең фотосын тумбочка өстенә куеп, шул фотога карап ята башладым. Рәсеменә караган

Фото интернеттан алынды

PRESSA.RU

саен сагынуым арта. «Кайларда йөрисең? Исәнме син, бәгърем?» – дип уйлыйм.

Бер көн идән юып йөргән санитарка фотога озак кына карап торды да:

– Яратасыңмы? – диде.

– Яратам.

– Ә бу татарочка госпитальдә ята бит. Өченче катта, баласы белән...

Кайда икәнен белешеп, аның палатасына йөгердем. Мөхәммәтҗан абый тынып калды.

– Таптыгызмы Тәнгыймәне? – дим, сабырсызланып.

– Таптым... Нинди генә булса да, алып кайтам дип, госпиталь баскычларыннан яралы аякларым белән йөгерә-йөгерә мендем. Ишекне ачып: «Тәнгыймә!» – дип кычкырып җибәрдем. Тәнгыймәне танырлык түгел: тире дә сөяк. Акыллы күзләре зураеп калган. Җир әйләнүдән туктады минем өчен. Алдымда Тәнгыймәнең яшьле күзләре, кулында – бала...

– Тәнгыймә, киен, киттек, – дим.

– Кая? – диде ул.

Мин айнып киткәндәй булдым. Чынлап та, кая алып китә алам? Нишли алам? Кулында сабые. Караватъ янына тезләнеп, Тәнгыймәне шашып үбә башладым.

Бик авыр чакларда бу дөньяда Мөхәммәтҗан бар дип юандым.

– Баланың әтисе фронтта, – дип пышылдады ул... Баланың елавы колакны ярып керә. Башны иеп әкрен генә чыгып киттем. Их, сугыш, каһәр суккан сугыш. Ниләр генә күрсәтмәдең, кемнәрнең генә язмышларын чәлпәрәмә китермәдең. Елама, Мөхәммәтҗан, кайгырма, баш исән булсын, дип үз-үземне юаттым.

Госпитальдән тагын фронтка киттем. Сугыш бетеп, елдан артык вакыт үткәч, орден-медальләр тагып, туган авылга кайту насыйп булды. Кайту белән Саниягә өйләндем. Матур гына яшәп киттек. Тәнгыймә, сирәк булса да, төшкә керде, яшь, матур булып, ләкин күзләре сагышлы, яшьле. Юк, онытмадым аны, онытa алмадым. Гомер буе авылда яшәдек. Ихата тутырып мал-туар карадык. Соңыннан умартачылык белән мавыктым. Шулай тыныч кына яшәп ятабыз. Бер көнне өй янына ят машина килеп туктады. Каршыга чыктым. Күземә күренәме дип торам – Тәнгыймә! Өстәл әзерләдек. Таллин шәһәрендә яши икән. Ире сугыш яраларыннан күптән үлгән. Балалары белән җыелып туган якларына кайтканнар. Хезмәт юлын башлаган авылга да килеп чыктык ди.

Тәнгыймә: «Уйна әле тальян гармуныңны», – дигәч, икәүләп яратып җырлаган «Рамай»ны уйнап җибәрдем.

Агыйделкәй алкын, суы салкын, Рамай, / Салкын диеп басмый калмадым. / Сөйдем сине, бәгърем, саф күңелдән, Рамай, / Аңлатырлык сүзләр тапмадым.

Сания ниндидер йомыш табып тышка чыкты. Начар яшәмәдек без аның белән. Гомер буе балалар укыттык. Тик үзебезгә Ходай бала насыйп итмәде. Башта бик көткән идек, соңыннан тынычландык.

Уфалардан кайткан акбүз атны, Рамай, / Ак каенга бәйләп куегыз. / Дөньялыкта бергә була алмадык, Рамай, / Каберебезне якын куегыз.

Тәнгыймәмә елап җибәрде. Минем күзләремә дә яшь тулды. Тәнгыймә елый, мин елыйм, безгә карап Сания елый. Шулай аерылыштык. Ул туган яклар белән бәхилләшергә кайткан икән. Берничә айдан хат килеп төште.

«Мөхәммәтҗан! Хәлләрем авырлаша, санаулы гына көннәр калып бара, – дип язган иде ул. – Йөрәктәге хисләрне бер утырып аңлаша да алмадык. Сугышта күргәннәрне сөйлисем килә иде. Караңгы төннәрдә кыз балага сакта торулары ничек куркыныч икәнен сугышта булган хатын-кыз гына белә. Аллага ялварам, үләм, Мөхәммәтҗанны күрми үләм бит, дип. Бик сагына идем сине.

Безнең командир 25 яшьлек сержант, рус егете Иван. Кызларны шаярта, юата. Без дә аны хөрмәт итә, азрак шүрли дә идек. Снаряд ярчыгы тиеп нык кына яралангач, ул мине күтәреп госпитальгә илтте, яныма килеп йөри башлады. Коточкыч сугышта минем яклаучым, ышанычым булып китте ул. Күп тә үтми хатыны булдым... Госпитальдә синең белән очрашканнан соң, баламны алып авылыма кайтып киттем. Иван Украинадан иде, беркайчан да анда бармыйм, авылда яшим, дип кайттым. Эшкә урнаштым. Авылыбызда укыта башладым. Сугыш беткәч, Иван мине алырга кайтты. Әти юк, әни, зур апа, гарип сеңелкәш, бала белән мин. Башта бармыйм, шушы тормышка ризамын, дидем. Әни: «Барасың, ир хакы, бала хакы бар, балаңны ятим итмә!» – дигәч, Иванга ияреп туган илдән киттем.

Мөхәммәтҗан! Гомер буе сине яратып яшәдем. Исәнлегеңне теләдем. Яшисе гомер үтеп тә киткән. Синең алда гаебем булса, кичер. Син белергә теләгән сорауга җавап язам. Ни өчен теге вакыт сиңа әйтмичә авылга кайтып киткәнне аңламадың. Мин әнидән сиңа кияүгә чыгарга рөхсәт сорарга кайткан идем бит. Риза булмады. Ашыкма, хезмәтен бетереп кайтсын дип кенә куйды. Бик яраткан идем шул сине. Ни өчен кайтканымны сиңа әйтергә оялдым...

Бәхил бул, Мөхәммәтҗан! Хәтерлисеңме? «Дөньялыкта бергә була алмасак, Рамай, / Каберебезне якын куегыз», дип җырлый идек. Кая ул каберләр бергә булу?! Нишлисең, Ходай шулай кушкандыр. Тагын бер тапкыр, мең тапкыр бәхил бул, Мөхәммәтҗан! Бу хатымны мин үлгәч җибәрерләр».

Менә шулай, кызым. Карт бабай моңаеп утыруы сиңа мәзәк тоелгандыр. Инде сугыш булмасын. Яшьләр без күргәннәрне күрмәсен. Яратканнар кавышсыннар. Әйе, күп хыялларым, эчкерсез ниятләрем тормышка ашмады. Тик гомеремне барыбер заяга узганга исәпләмим.

Санаторийда ямь бетте. Озак кына уйланып йөрдем. И бу дөньяның сөеп-сөелеп тә кавыша алмаган бәхетсез ярлары, үлгәнче бер-берсен сөйгән, ярата белгән җаннар. Урыннары җәннәттә булсын.

Фирүзә БӘДАМШИНА

АНА МӘХӘББӘТЕ ТУРЫНДА ЕШ СӨЙЛИБЕЗ. МӘХӘББӘТНЕҢ БУ ТӨРЕ БӘХӘСЛӘРГӘ УРЫН КАЛДЫРМЫЙ КЕБЕК. ЛӘКИН, СИРӘК БУЛСА ДА, АКЫЛ ЫШАНМАС ХӘЛЛӘР ДӘ БУЛЫП КУЯ. БУ ВАКЫЙГА ДА АКЫЛ ЫШАНМАС ХӘЛЛӘРНЕҢ БЕР МИСАЛЫ.

Асия
СӘГЫЙТОВА

СЫЕР КАРГЫШЫ

– Бервакыт тәүфыйклы гына йөргән сыерыбыз үзгәрде, – дип сөйләгән иде апам. – Көтүдән кайтып саудыра, алдына куйган суны эчеп, сыйны бөкләп куюга ихатадан чыгып кача башлады. Таң алдыннан гына әйләнеп кайта бу. Йокы күрми, ял күрми, кем әйтмешли, малкай. Ә без, хуҗалар, элеккеге кебек чиләк тулы сөт күрми башладык. Кемдер савып кайтарамы соң? Берничә кич шулай булды. Без әле тәҗрибәсез хуҗалар булганбыздыр. Ярый әле шул көннәрдә Назиф абзый кунакка килде. Бик тә зирәк абзыебыз иде ул. Шул әйтә куйды: «Сыерыгыз көтүдә бозаулаган булыр. Бозавы янына китә бу. Артыннан барып карагыз». Шулай иттек тә. Нәкъ «Әбугалисина» әкиятендәгечә. Төн уртасы җиткәндәрәк урман читенә барып җитте сыер. Шым гына күзәтәбез. Кем килеп чыгар икән, дибез. Бу сыерны кем үзенә ияләштерде икән, дибез. Бер мәлне безнең Малинабыз, ягымлы гына мөгрәп, өн салды. Ул да булмады, ешкынлыктан тагын да назлырак мөгрәгән тавыш ишетелде дә алдыбызга нәни бозау килеп чыкты. Бәхетле ана белән сабый бозау кавыштылар. Бозау имеп, әнкәсе ялап туйганнан соң, сыер бозавын иплләп кенә төрткәләп, кабат шул ешкынлыкка кертеп җибәрмәкче булды. Инде сер ачылгач, без ни эшләсен белә идек. Ак маңгайлы матуркайны арбага салдык. Сыер янәдән авылга таба үзе теркелдәде.

Кара инде без сантыйларны – сыерның бозаулаганын да аера белмәгәнбез. Көтүчеләр дә абайламаган. Андый наданнар бер без генә дә



түгел икән. Күп еллар узгач, шушы рәвешлерәк чамалый белмәү авылдашлар арасында низаг чыгуга сәбәп булды. Быел да көтүдә ике буаз сыер йөргән. Буаз сыер хуҗалары көтүчегә алдан ук гозерләнеп куя бит инде ул. Имеш, минем малны игътибарла әле, дигән булып.

Бер көнне көтүче куаклыктан ике бозау табып алган. Мантыйк гади – ике буаз сыер бар иде, ике бозау. Ике сыер хуҗасы ике бозауны ике йортка алып киткәннәр. Тик бер сыерның хуҗасы, күрәсең, тәҗрибәлерәк хөҗәин булгандыр: «Бозауларның икесе дә безнең сыерныкы», – дип чат тора икән. Икенче хуҗа да үзенә тигән бозауны бирергә ашыкмый. Югыйсә сыерының әле бозауламаганын, мөгаен, белгәндер ул. Бөтен кеше дә без түгел бит! Әйе, белгәндер, чөнки сыерының җилененә сөт төшмәгәнен күрә – бозауга сөтне сатып алып эчертә. Тик сер бирми.

Бүтән берни дә түгел, комсызлык галәмәте инде бу. Югыйсә яхшы күршелек кануннары бер бозау бәһасе генә торамы?! Гафу сорау кая да, уңайсызлану кая! Югыйсә әнкә сыерның алар турыннан үткәндә гасабиланып мөгрәүләрен ишетеп-күреп торган ла бу хуҗа. Хәстәрчән инде. Үз сыеры ничегрәк бозаулый бит әле. Үле бозау салуы да бар. Монда бозауның бер дигәне. Булып торсын!

Бер-ике көннән икенче сыер да бозаулый. Инде бәхәскә нокта куела. Теге аерылган бозауны анасына кушалар. Чит бозауга кызыккан комсыз адәм бозауга эчергән сөт акчасын даулап килә. Ала да! Шул акчага үз сыерына кыш чыгарга җитәрлек печән кайтарта. Күп итеп!

Бер кичне хәрам акчага сатып алынган шул печән – кибән-кибән коры печән дөрләп янып китә. Сварка эшен саксыз башкарганда очкын чәчрәгән, диделәр. Авыл өстенә таралган кара төтен авылдашларны шомга сала. Шомланырсың да – җәй уртасы бит! Ике көн тоташ көйри печән кибәннәре.

Ике көн тоташ авыл өстендә төтен тора. Янгын чыгуның сәбәбен авылдашлар бер дә сварка очкынына да, ваемсызлыктан да күрми. Аларның фикере аңлаешлы һәм катгый: «Ходай биргән җәза бу!» Икенче төрлерәк фараз да бар: «Сыерның гына каргышы төште. Ана каргышы! Әллә баласының мөгрәгәнен ишетеп торып, чит капка турыннан узып йөрүләре җиңел булганмы малкайга?»

Сыер булып сыерның каргышы шулай төшә торган булгач, аналарныкы ничек төшмәсен?! Рәнҗештән сакланыйк! Рәнҗемик тә.

PRESSA.RU



БАЛА КАРАГЫ

ЧИТ ИЛ КЕШЕСЕНӘ КИЯҮГӘ ЧЫГУ ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАНУЧЫ ХАТЫН-КЫЗЛАР АЗ ТҮГЕЛ БЕЗДӘ. ИНТЕРНЕТ АША ГЫНА ТАНЫШКАН КЕШЕГӘ ИЯРЕП ЧИТ ИЛГӘ ЯШӘРГӘ ҮК КИТЕП БАРУЧЫЛАР ДА БАР.

Ике йөрәкледер дим мин аларны. Шулай булмаса, телен, илен, мәдәниятен, һәм иң мөһиме – кешесен юньле-башлы белми торып, бу адымга ничек бармак кирәк?! Билгесезлеккә атлау бит бу! Әгәр ул кеше дөньяның бер юньсезе булса? Ул очракта кемгә таянырга? Кануннарын да, гореф-гадәтләрен дә рәтләп белмәгән илдә берьялгызың калсаң нишләргә? Тагын да яманы – үзәгеңнән өзелеп төшкән балаңны чит илдә калдырып кайтырга мәҗбүр булсаң?



Лилия ГӘРӘЕВА

Мәктәп ишегалдында Нурияне очратырмын дип башыма да килмәгән иде. Ә ул менә очрады! Университетны тәмамлаганнан соң Нурияне беренче күрүем. Ничек күрешәсең?! Укып бетеругә Германиягә китеп барды бит ул! Тормышы начар булмагандыр. «Вконтакте»дагы фотолардан бәхетле ханым елмая иде. Кызык, чит илдә бәхетлеләр яши дигән фикер нәрсәгә нигезләнгән икән ул? Андагылар бездән баерак яшәгәнгә шулай уйланыла микән соң? Беренче соравым башымда түгел, телнең нәкъ очында ук яралды: «Озакка кайттыңмы?»

«Бөтенләйгә кайттым, – диде Нурия. – Улымны Германиядән урлап алып чыктым». Мизгел эчендә күзалдымда детектив сурәт пәйда була: Нурия, баласын җитәкләп, аэропортка килә. Башында – парик.

Кулында – ялган документлар (кинода шулай күрсәтәләр!). Полиция аэропортка бәреп кергән мәлдә, Нурияне коткарасы самолетның шассилары җирдән аерыла... Әкият, билгеле. Тормышта алай булмый инде. Ә шулай да, бала тикле баланы ничек чик аша урлап алып чыга алды икән?

«Берни дә сорама, барыбер сөйләмим. Ул хакта искә дә төшерәсем килми», – диде ул. «Гайбәт түгел, гыйбрәт итеп сөйлә. Синең хатаны бүген никадәр хатын-кыз кабатларга җыена», – дип, бик озак үгетләргә туры килде аны.

«Әлегә беркем белән дә аралашасым килми. «Фейсбук» белән «Вконтакте»дагы сәхифәләремне дә бетереп аттым, – диде Нурия. – Бер төн тыныч йоклаганым юк. «Интерпол»дан килделәр. Ирем безне халыкара эзләтүгә биргән икән. Хәзер безгә Россиядән беркая чыгарга ярамый. Ярар, чит илләргә бармый да торып була. Анысы өчен исем китми. Ул кешенең (ирем дип әйтәсем килми) болай кылануы ачуны китерә. Безне эзләтүе дә баланы яратудан, аны сагынудан түгел бит. Бала кирәкми аңа. Шул бала аркасында янга каласы акчалар гына кирәк. Германиядә балалы кешеләрдән салымнарны азрак түләтәләр. Әнә шул акчалар өчен нишләргә белми. Әле дә ярый үз илемә кайтып кала алдык. Кайта алмасам, белмим, нишләп беткән булыр идек. Соңгы вакытта бик экстремаль шартларда яшәргә туры килде шул».

Булачак ире белән танышу сайты аша табышкан алар. «Минем яңа гына университет тәмамлаган чак, – дип, әрнү катыш үкенү белән искә ала ул көннәрне Нурия. – Хыяллар зурдан. Үземне әллә кайларда, әллә кемнәр итеп күрәм. Чит илләргә дә китәсе килә. Шуңа да бу танышуым бик вакытлы иде. Азрак аралашып, берберебезне ошаткан кебек булдык. Бер-ике тапкыр үзе дә минем янга килеп китте. Соңгы килүендә язылыштык. Тагын җиде айдан Дрезден аэропортына кунган Боинг трабыннан төшә идем инде. «Ура! Бүгеннән минем бәхетле тормышым башлана!» – дип мәтәлчек атты иләс күңел. Ирем дигән кешенең мине каршыларга сыңар чәчкә генә булса да тотып килмәвенә дә, төнге бердә ике сәгать буена электричкада кайтуыбызга да исем китмәде. Аны уйларлык түгел иде халәтем.

Тормышымның яңа этабы – Германия чоры башланды. Әмма... бәхетле чор дип әйтеп була иде микән аны?

...Аның минем кеше түгеллеген бик тиз абайладым – менталитетларыбыз ук башка. «Тибешкәндә тиңең булсын» дигән мәкальнең асылын менә кайчан аңладым мин! Борылып китәсе иде шул чагында. Ә мин яшәп карарга булдым. Шулай тиз генә бирешәсеңмени инде, дидем үз-үземә. Килгән-килгән, телне дә ныгытып өйрәним, дидем. Телне белмәүчеләрне даими яшәү урынына теркәмиләр анда. Барысына да кул селтәп кайтып китәргә беркайчан да соң түгел ул. «Идеаль кеше юк, яши-яши күнегелер. Аның каруы, син хәзер чит ил кешесе», – дип тукыдым үземә. Иллюзиягә алдандым. Аннан улым туды. Хәзер инде уйласам да, җайлы гына кайтып булмаячак иде.

Әйтәсе дә юк, бала үстерү өчен Германия уңай ил. Балаларга хөкүмәт артык кашык итеп карамый – ай саен 184 евро түләп тора. Баласына өч яшь тулганчы, әниләр түләүле декрет ялында утыра ала. Социаль яктан кайгырту көчле. Балага кирәкле дарулар бар да бушлай. Врачтан рецепт кына кирәк. Балаларның хокукларын бик нык саклыйлар. Кибеттә тегене ал, моны ал дип идәнгә ятып елаган баланың артына берне чәбәкләп кара! Хәзер полиция килеп җитә. Баланың берүзен генә өйдә дә калдырырга ярамый. Белеп алсалар, баланы Jungedamt – балаларның хокукларын яклый торган берләшмәгә алып китәләр. Бернинди проблемалар юк дию дә дөрес булмас. Германия җәннәт түгел. Анда да баланы бакчага урнаштыру – үзе бер бәла. Урыннар җитешми. Урнаштыра алсаң да, балаңны яхшылап карарлар дигән ышаныч юк. Яшь ярымлык кына балаларын ясленләргә бирүче әниләр дә бар. Кайда да эшләмичә булмый шул. Пенсиягә чыккач, рәхәт яшисең килсә, Германиядә бик күп эшләргә кирәк. Чит илләрдән килгәннәрне эшкә алырга атлыгып тормыйлар. Безнең дипломнар анда чүп кенә. Эшкә урнашыр өчен башта телне яхшылап өйрәнергә, аннары аларның уку йортларын тәмамларга кирәк. Чит ил кешеләренең бик кечкенә генә пенсиягә тилмереп яшәгәннәрен күрдем. Немец халкы тәртипле, бөтен җирләре чиста дисәләр дә, кеше кайда да кеше инде ул. Эшкә барган, эштән кайткан чакларда аларның да автобусларына баш тыккысыз була. Әбиләрнең урын өчен кычкырышканнарын да күргән булды. Ватык шешә, аунап яткан кәгазь аларда да бар. Әмма калырга мөмкинлегем булган булса, калган булыр идем.

Чит ил кешесенә кияүгә чыгып аерылган ханымнарга кайчак бик зур хак түләргә кирәк була. Үзәгеңнән өзелеп төшкән бала белән түләнә ул хак.

Ирем – токарь иде. Аена уртача 2000 евро хезмәт хакы алып эшли. Салымнарны тотып калгач, кулына 1700 евро тия. Фатир үзеңнеке булмаса, анда бу акчага гына яшәп булмый. Ә безнең фатир, әлбәттә, арендага алынган. Ничек кенә булса да, миңа эш табарга кирәк иде. Эзли торгач, пекарняда эш таптым. Югыйсә ирем асрау кызга караган кебек карый башлаган иде. Хәер, эшкә урнашкач та аның мөнәсәбәте үзгәрде, тырышлыгым аз булса да бәяләнде дип әйтә алмыйм. Бушка эшли торган хезмәтчесе идем мин аның. Иремнең һәр сүзендә, һәр ымында: «Син хәерчегә ярамаган тагын. Сиңа болай да бик бата. Үзеңнең кайдан килгәнеңне оныттың мәллә?» – дигән мәгънә ярылып ята иде. Бернинди мәхәббәт турында сүз дә юк. Минем яктан баштарак аңа карата ниндидер симпатия бар иде. Торабара ул да бетте. Телне дә өйрәнеп була, халкына, андагы гадәтләргә дә күнегелә. Әмма бер нәрсәгә һич

PRESSA.RU

күнегеп булмый икән: сине икенче сортлы кеше итеп күрүләренә! Эшкә урнашыйм дисәң дә, иң аз хезмәт хакы түләнә торган, иң авыр эшләргә генә урнаша алачаксың.

Ирем белән ике арадагы ермак тирәнәйгәннән-тирәнәя барып, берзаман упкынга ук әверелде. Мин – аны, ул мине ишетми идек инде. Тормыш алып баруы бик авырлашты. Хәтта искә алырга да оят, Германиядә ярлылыкның чигендә яшәдем мин. Ирем үз акчасын үзенә генә тота, уртак янчыкка кушмый. Чиргә әверелгән саранлык иде анда. Минем тапканым бары тик гадәти азык-төлек алырга гына җитә. Әле бит бала да бар. Аны киендерергә кирәк, уенчыгын алырга, бакчасына түләргә... Якында гына бер гаилә яши иде безнең. Хатыны, минем кебек, Россия кешесе. Бик авыр булганда, шул хатынга барып сыена идем. Балаларының кечерәйгән киемнәре белән дә ярдәм итте ул. Улым аның балалары белән уйнап үсте, шулай рус теленә өйрәнде. Монысы Россиягә кайткач, бик кулай булды.

Германиядә яшәп калсак, улымның язмышы бөтенләй башкача булыр иде. Аның уңышына, бәхетенә юлны япмадыммы икән дип шикләнәм кайчак.

Кайнана-кайнаталарым безнең тормышка кысылмады. Балага анда-санда берәр бүләк алудан гайре, башкача ярдәмнәре булды дип әйтә алмыйм. Үпкәләп булмый, аларда гадәт шундый – яшь гаиләнең тормышына кысылмыйлар. Начар кешеләр түгел иде алар үзләре. Германия исемә төшсә, мин иң элек аларны сагынам. Алар үз улларының холкын яхшы белә, шуңа да гел минем яклы булдылар. Үзләренчә, мине ярата да иделәр кебек. Баштарак сагаебрак калганнар иде калуын. Бер дә онытмыйм: «Туганнарың синең монда икәнеңне беләме? Алар синең бу шөгылеңә каршы түгелме?» – дип сорый беркөн кайнанам. Аптырап киттем: «Нинди шөгылемә?» Бичаракаем, Германиягә мине фахишәлек белән шөгыльләнү өчен килгән дип уйлый икән. Кызганыч, болай уйлаучылар бер ул гына түгел иде шул.

Түзим-түзим, дип, еллар үтте. Баламның укырга керер вакыты җитте. Анда мәктәпкә алты яшьтән баралар һәм 12 ел укыйлар. Укырга кергәнче хәреф таныган, саннарны белгән балалар аз. Барысына да мәктәптә өйрәтәләр. Миңа алга таба тормышымның кайсы юлдан китәсен хәл итәргә кирәк иде. Һәм бу көтмәгәндә-уйламаганда, үзеннән-үзе хәл ителде. Ирем, миннән аерылып, баланы тартып алу белән яный башлады. Сабыр савытым тулган соңгы тамчы шушы булгандыр инде. Уйласа, ул бит баланы чынлап та үзендә калдыра ала иде. Кайтып китү уем көнләп түгел, сәгатьләп ныгыды. Без моңарчы да әти-әнием янына ел да кайтып йөрдек. Иремнең баланы чик аша алып чыгу өчен биргән рөхсәт кәгазе бар. Әмма Германия законнары буенча, әгәр дә ул, хатыным баланы чит илгә бөтенләйгә алып чыгып китәргә ниятли дип әйтсә, баланы чик аша үткәрмәскә дә бик мөмкиннәр.

Ирем аны-моны абайлап, юлны ябып куймасын өчен, хәйләгә барырга булдым. Имеш, Германиядән һич тә китәсем килми. Анда кайткач та, әйләнеп киләсе көннәремне минутлап санаячакмын. Хәтта фатирга ремонт та башлап җибәрдем. Юри, әлбәттә. Башланган эш – беткән эш, хәзер башлап куябыз да, мин кайткач, төгәлләрбез, янәсе. Иремне изрәттем шулай. Безнең бөтенләйгә китү уе башына да кермәсен! «Германия кадәр Германияне калдырып кем китсен инде!» – дип уйлагандыр ул, мөгаен. Бу илдә сыңар туфлиемне дә калдырасым килмәсә дә, бөтен нәрсәмне төйи башласам, шик уятачак идем. Киемсалымнарның яхшы дигәнен генә алдым. Шулай да чемоданнар шактый җыйналды. Ирем безне озатып мәшәкатьләнмәскә булды. Саубуллашырга кайнанам белән кайнатам килде. Кайнанам әле бер чемоданга, әле икенчесенә карап-карап торды да: «Син әллә бөтенләйгә китәргә уйлыйсыңмы?» – дип сорап куйды. Каушаудан, кулымдагы әйберем төшеп китә язды. Ниятемне аңа сиздерергә ярамый иде. Бала баласы һәркем өчен татлы. Булышу, кайгырту, кызгану кадәресе булмаса да, әбисе улымны ярата иде. Кайнанамның шиге күңел бусагасыннан ары узмады. Шуның өчен генә булса да, рәхмәт аңа.

Россия безне туып килгән алсу таңы белән каршы алды. Мин моны яхшыга юрадым. Туган илемдә миңа да, балама да куркыныч янамый иде инде. Германия генә түгел, Россия дә үз гражданнарын һәм алардан туган балаларның хокукларын яклый белә.

Әмма күңелнең кичерешләрен шулай тиз генә сызып ташлап булса икән ул! Баланы алып калырлар дигән курку психикамны шактый ук какшаткан булып чыкты. Казанга кайткач та бер ел буена гел бер төш күреп уяндым. Имеш, аэропортка килгәнмен, ә анда мине полиция көтеп тора. Кулларымны каерып, төрмәгә алып китәләр. Валерьянка эчеп, көчкә тынычлана идем.

Көннәрдән бер көнне Германиядән посылка килеп төште. Кайнанам калдырып киткән киемнәремне һәм баланың уенчыкларын салган. Хатын-кыз кайда да хатын-кыз шул. Шул посылканы кочаклап, илереп бер еладым. Германиядә уздырган алтынга тиң яшьлегем өчен дә, андагы кимсенүләр өчен дә, әтисен бер күрергә зар булып үскән балам өчен дә, кителгән язмышым өчен дә иде ул күз яшьләре...

Ирем безне берничә тапкыр хәйлә белән Германиягә китертмәкче булып талпынып карады. Юк инде. Бардым, күрдем, җитте! Чит ил кунакка барганда гына яхшы икән ул.



ХӘСӘНОВА Лилия

Казан дәүләт университетының механика-математика факультеты.

Кияүдә, ике бала анасы.

Карьера:
Казан шәһәренең 32 нче урта мәктәп директоры.

Тормыш шигаре:
«Ваклыкларын аның юк дип белсәң,
Дөнья матурлыгын күрерсең!»
А. БЛОК

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Хезмәтенә күрә – хөрмәте!

Күптән түгел «автомобильчеләр көне»н билгеләп үттеләр. Шул бәйрәм вакытында ирем Рөстәмгә Россия Президенты В. Путин имзалаган Мактау кәгазе тапшырдылар. Ул инде күп еллар 2 нче ПАТПда тәэминат бүлеге башлыгы булып эшли. Бик тырышып эшли! Автобусларга запас частьлар табу аның өстендә: чит илләрдән дә, Россия буйлап та эзли, алып кайта ул аларны. Автобусларның ватылмыйча йөрүендә, вакытында рейска чыгуында иремнең дә өлеше бик зур.


Дөньяны ачуны үзебездән башлыйк!

Каникул вакытында коллектив белән Тәтешкә бардык. Авыл җирендә ни күрербез инде дисәк... Тәтеш – биек, текә тау башында урнашкан, ә аста – чал Идел ага. Табигатьнең матурлыгы! Кайчандыр Казан губернасының чиге шушыннан узган. I гильдия сәүдәгәр П. Серебряков йортына урнашкан крайны өйрәнү музее шул чор экспонатларына бик бай. Экскурсияне директор Наталья Понедельникова үзе алып барды. Аның ничекләр йөрәккә үткәзеп сөйләвен ишетсәгез икән! Без ул көнне ук-җәядән дә атып карадык, борынгы җырлар да тыңладык...

Без бертөрле уйлыйбыз!

Мәктәбебезгә Казан мәктәпләрендә инглиз теле укыта торган Канада, Испания, АКШ укытучылары кунакка килде. Борчылган идек. Америка белән безнең ил арасында соңгы вакытта мөнәсәбәтләр киеренке бит – бу безнең аралашуга тәэсир итәрме, юкмы? Киеренкелек берничә минут кына булды. Үзебез турында сөйләдек, аларны тыңладык, өчпочмак, ит бәлеше белән сыйландык... Кыскасы, якын дуслар булып аерылыштык. Сәясәт – сәясәт инде, ә гади кешеләрнең аралашуы башка ул. Сугыш, низаг ише нәрсәләр гади халыкка кайда да кирәк түгел: аларга да, безгә дә.

сөендерде








көендерде

сөендерде







көендерде

сөендерде



көендерде

Наз җитми...

Соңгы вакыт мәктәптә гел бер нәрсәгә игътибар итәм: укучылар, җай чыккан саен, укытучының кочагына керергә тырыша. Кочаклап та алабыз, яратып, баланың аркасыннан да сөябез – безгә кыен түгел... Әмма хикмәт бит башкада: димәк, балаларга өйдә ярату, җылылык, наз җитеп бетми. Әти-әнинең моңа вакыты юк. Кыз баланы яратып кочагыңа алып тору, ир баланың һичьюгы башыннан сыйпап узу, аңа кагылу бик кирәк. Психологлар да шулай диләр. Яратуны тоеп, сизеп үскән балалар бөтенләй башка була алар.

Сагындыра...

Август аенда Туфан абый Миңнуллин тууына 80 ел булганын әйтүем... Мин 3 нче татар гимназиясендә эшләгәндә ул безгә еш килә торган иде, ел саен балаларга үз премиясен биреп килде. Премьераларында булганнан соң, гел шалтырата идем – гади тамашачы фикере кызык иде аңа. Берәр сәгатьләп сөйләшәбез, сорау арты сорау яудырам, ул җавап бирә... Шул сөйләшүләр җитми миңа, сагынам аны, юксынам. Эшем, бездәге яңалыклар турында сөйлисем килә, киңәшләрен ишетәсем... Хәер, миңа гынамы, бөтен татар дөньясына җитми бүген Туфан ага!

Гаеп – һәрберебездә

Европа һәм Россия яшьләренең – егет һәм хәтта кызларның Сүриягә китеп, ИГИЛ сафларына кушылуы борчый мине. Димәк, без аларны дөрес тәрбияләмибез, дөрес үстермибез. Ни өчен алар ак белән караны аера алмый? Ни өчен кеше үтерүне иң зур гөнаһка санамый? Югыйсә ислам дине дә, христианнар да, католиклар да – берсе дә кеше үтерергә өндәми. Ни өчен без яшьләргә диннең шушы нечкәлекләрен өйрәтмибез? Димәк, бездә – мәктәптә тә гаеп бар. Дәүләттә дә. Дин әһелләрендә дә.

PRESSA.RU



ЯРАТЫРГА ИНДЕ СОҢ

Марсель ГАЛИЕВ

Яшь шагыйрь – университетның бишенче курс студенты (ул чакта Казанның бердәнбер һәм чын университеты) борынгы йортның икенче каттагы шыр ярлы бүлмәсендә, акшарлары купкан мич капкачын ачып куйган, каен утынына ут дөрләткән дә ялкын телләренә карап, моңсуланып утыра. Күптән түгел генә өйләнгән, дөньясы тарайган. Бүтән инде мәңге гашыйк була алмас, гөнаһ булыр, ярамый, дигән самими уйлары читлектәге йөрәген юата алмый. Учактан дуамал очкыннар чәчри. Күмер араларыннан, әрнеп, шигырь юллары төшә.

Урманнарда яна,
яна,
яна сары балкыш,
Сизелми дә җиткән көз дисең.
Үзең әле һаман кырлар буйлап
Яшеллеген җәйнең,
яшеллеген җәйнең эзлисең.

Шулай итеп мин, җыр өчен дип, махсус шигырь язып утырам. Гадәти дүртьюллыклардан аермалы булсын дип, сүзләремне бүлгәләп, композитор хыялына, үзгә бер ритмга мөмкинлек калдырам, имеш. Тәҗрибәсез башым белән чамалыйм: чытырманлы фикерне җыр өнәми, көйгә салынасы шигырьдә сүз аз булырга, җиңел истә калырга тиеш.

Кем бу җырга җан өрер? Кем көйчесе булыр? Бу турыда уйламыйм да бугай. Кыюланып, кайсы да булса композиторга шигыремне бирү хакында уйларга да куркам. Чөнки мин аларның берсен дә якыннан белмим.

Зур концертларда сәхнәгә тыйнак кына чыгып, пианинода җанга ятышлы итеп уйный торган музыкант ханым – Мөнирә Хәбибуллина (шагыйрь Мөнир Мазунов кызы) белән радиокомитетта танышкач, аңа әлеге шигырьне бирдем. Тиз генә кемнәндер яздырып алыр да, бу көй тиз арада бөтен Казанга таралыр – үземә калса, шулай уйлаган булам.

Менә шул шигырь аркасында инде мин чорыбызның мәшһүр композиторы Рөстәм ага Яхин белән танышу бәхетенә ирештем. Мөнирә ханым радиокомитетның кием элгече

Көзге моң

Урманнарда яна,
яна,
яна сары балкыш,
сизелми дә җиткән
көз дисең.
Үзең әле һаман кырлар
буйлап
яшеллеген җәйнең,
яшеллеген
җәйнең эзлисең.

Яшьлекнең дә мәңге,
мәңге,
мәңге булырына
ышанмадыкмыни –
ышандык.
Ә нигә соң
синең күзләреңдә
көзләр нуры кергән,
көзләр нуры кергән
уйчанлык?

Таҗын өзеп соңгы
чәчәкләрнең
киләчәгең юрап карыйсың.
Яратмаска сине
мөмкин түгел,
яратырга инде,
яратырга инде
соң, дисең...

янында Рөстәм аганы «эләктереп» алган. Ничаклы җаена төшәргә тырышса да, Рөстәм ага ул сузган кәгазьгә борылып карарга да теләмәгән. Аптырагач, Мөнирә ханым: «Ярый, алмассыз, менә шушында укып кына карагыз инде, зинһар», – дип, ялынып диярлек үтенгәч, Рөстәм ага шигырьне теләр-теләмәс кенә алган, плащының сыңар җиңен кигән килеш туктап калган да... Мөнирә ханым аны болай дип сурәтли:

– Үзе укый, үзе башын селкетә. Зур башлы иде бит Рөстәм ага. Сизеп торам, көй аңарда шигырьне укыганда ук туа башлады. Шуннан укып бетерде дә, бер сүз дә әйтмичә шигырьне кесәсенә салып куйды. Берничә көннән инде әзер романсны тотып миңа килде.

Хәтеремдә, бу хәбәрне ишеткәч, мин бер дә сөенмәдем. Шундый мәртәбәле композиторны кузгатырга кирәкми иде. Искечә итеп, саллы көй язгандыр. Ә мин бүген студентлар табынына бәреп керәсе яшьлек ритмын көткән идем, дип үкенечле уйлап та куйдым бугай.

Танышканда Рөстәм ага йомшак кулын минем кул ихтыярына бирде. Артык ипле, төгәл, пөхтә – зыялы икәнен бөтен рәвеше әйтеп тора. Ә минем, рәтле тәрбия алмаган егетнең, бу әчпошыргыч бертөрле җәмгыятьтә «почмаклы» буласы килү маһирлыгының баштан ашкан чагы. Әмма Рөстәм ага каршында мин югалып калдым. Ни таләпчән композиторның шигыремдәге бер генә сүзне дә үзгәрттермәве мине чарасыз калдырды. Тынлыкка таянып басып торабыз шулай...

– Мин сезне олы яшьтәге кеше дип уйлаган идем. «Яратырга инде соң дисең...» Сезгә болай әйтергә иртәрәк бит әле... Кызык...

– Мин аны чын күңелемнән, ышанып яздым, – дип акланырга керештем.

Гомереңнең актык сулышында да мәхәббәтнең соңы соңгы булып тоелмыйдыр, дигән кебек, Рөстәм ага сизелер-сизелмәс кенә киная белән елмайды.

– Көй бик тиз язылды. Андый очрак сирәк була. Гадәттә, мин бик озак йөртәм. Тагын шигырьләрең бармы, җыр өчен дип язылганнары?

– Юк, Рөстәм ага. Монысы да үземне сынап карар өчен генә. Бүтән язмыйм!

Рөстәм ага бер мәл сәерсенеп карап торды. Иҗат галәмендә күпне күргән, күпне кичергән аганың күзләре: «Ай-һай, мондый авыру бер керсә, туктый алырсың микән, егет...» – дигән фикерне яшермичә эчтән елмая иде...

«Көзге моң» дип исемләнгән романсны танылган сәхнә осталары – Эмиль Җәләлетдинов, Рафаэль Сәхаби, Хәйдәр Бигичев пластинкаларга яздырдылар, зур тамаша залларында башкардылар. Хәйдәр Бигичев бу романсны янә бер башка күтәрде һәм зыялы-зәвыклы катлауның күңелен яулап алды. Мин дә шулар белән бергә әкренләп «тәрбияләндем», җырны ярата башладым.

Бервакыт Ирек мәйданында олуг шагыйребез Сибгат Хәким белән очраштык. Мин концертка бара идем. Ул һава суларга чыккан. Сибгат ага гадәтенчә йомшак кына итеп, сүзләрен мәгънәле өзә-өзә фикерен башлады:

– Яхин кичәсендә булмадың. «Көзге моң»ны Бигич җырлады. Мин күп җырлар язган кеше. Көнләштем. Җыр беткәч, зал бер мәлгә тын ала алмыйча торды. Аннары... шартлады. Алкышлар биш минут буена сузылгандыр. Сезнең ул романс калачак.

Үз гомерендә танылган композиторлар белән гаҗәеп җырлар язган аксакалның шулай әчкерсез әйтүе күңелемә шифалы уелып калды...

Хәйдәр Бигичевнең, зур оркестрга кушылып, «Көзге моң»ны искиткеч итеп җырлавын мин Мәскәүнең Колонналы залында тыңладым. Шыгрым тулы залда Мәскәү татарлары гына түгел, руслар да, чит ил кунаклары да бар иде. Бу шигырьгә Рөстәм аганың шулкадәр дә тирән мәгънәле көй язуына мин шунда ышандым. Күңелне әйтеп бетергесез горурлык хисе биләп алды. Алкышларның кодрәте турында әйтеп тә тормыйм.

Әлбәттә, бу романс Рөстәм аганың күпкырлы һәм бай иҗатында бер тамчы гынадыр. Әмма минем өчен ул тарихи тамчы. Шигырь һәм көй бердәй тәңгәл килгәндә генә җыр гомерле була, диләр. Шулайдыр. Кешелекле шәхес буларак, Рөстәм ага минем беренче әсәремә игътибар итте, җан иңдерде, мәрхәбә, дип, олы сәнгать дөньясына кереп китәргә сәбәпче булды. Шуңа күрә аңа рәхмәтле хисләрем артыграк китсә дә гөнаһ түгел.

Рөстәм аганың фортепианода уйнаганын хәтерлим. Клавишаларга алай ук та сак-иркә кагылып, бармакларын тигезер-тигезмәс йөздереп кенә уйнаган музыкант тагын бар микән?! Яхин моңы – мөлаем-назлы моң.

Фото: Марс Шабай, Луиза Батыр-Болгари, Рөстәм Яхин һәм Марсель Галиев.

PRESSA.RU

16+

ЯРАТУНЫ ИСБАТЛАРГА КИРӘКМИ



Атлас ГАФИЯТОВ, журналист;
өйләнгән;
гаилә стажы — 30 ел;
ике бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Дөресен генә әйткәндә, болар бөтенесе берьюлы күзгә ташланадыр инде ул. Чөнки тышкы бизәкләр бит. Ә инде хатын-кызның акылы аның белән сөйләшкән вакытта ачыклана.

Яшермим, яшьрәк чакта иң элек мин кызларның күзләренә карый идем, аннан соң – чәчләренә. Һәм, ни өчендер, миңа аларның озын толымлылары ошый иде. Студент чакта гашыйк булып йөргән бер чибәрне озын толымын кистергән өчен ташладым да әле. Толымын кистергәнче минем белән киңәшмәгән, янәсе. Хәзер исә бу хакта искә төшергәндә үз-үземнән көләм: без бит ул чакта әле бернинди вәгъдәләр бирешмәгән, дуслашып кына йөргән чак иде. Ә ни өчен ул чәчен кистерергә миннән рөхсәт сорарга тиеш иде соң?

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Күптер инде андый сыйфатлар. Чөнки Аллаһы Тәгалә гүзәл затларны ир-атларга караганда физик яктан бераз көчсезрәк, нечкә күңеллерәк итеп яраткан. Гәрчә хәзер гүзәл затларыбызның байтагы элегрәк бары тик ир-атлар гына башкара торган авыр эшләрне дә эшлиләр, спорт өлкәсендә дә алар чыгыш ясамаган өлкәләр бетеп бара. Югыйсә Борынгы Грециядә аларны ярышта катнаштыру түгел, хәтта ир-атлар ярышканын карап торырга стадионга да кертмәгәннәр. Ә хәзер әнә алар рингта тукмашалар, штанга күтәрәләр, хоккей уйныйлар... Мин менә боларын аңлый алмыйм инде. Кайсы сыйфатларны гафу итәргә була дигәндә, хатын-кызның берәр җиргә бара башласаң, озак җыенуын, телефоннан сәгатьләр буе ләчтит сатуын кичерәбез инде.

3 Ә нәрсә өчен сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

Хыянәт һәм ялган өчен. Хәер, болар икесе гел бергә яши торган сыйфатлар. Дөресрәге, алар бер-берсенә ялганадыр.

Бүген телевизор экраннарында, кинофильмнарда булсын, бер-берсенә хыянәт итүче парларны еш күрсәтәләр. Ире бер якта хатынына хыянәт итә, хатыны – икенче якта. Иң кызыгы һәм кызганычы шунда: бер-берсенең хыянәт итүен белсәләр дә, бергә яшәүләрен дәвам итә болар. Аларның шулай бер-берсен алдап яшәүләре тора-бара балаларына да күчәргә, алар моны үрнәк яшәү рәвеше итеп алырга да мөмкин бит. Тормышта менә шулай икейөзләнеп яшәүдән сакланырга кирәктер.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручылар... Сезгә аның кайсысы якынрак?

– Сез әйткән тип хатын-кызның икесе дә. Тик алар – хатын-кызлар – икегә генә бүленмиләрдер дип уйлыйм.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Була аладыр. Әмма ир-атның да хатыны белән бүлешми торган серләре була. Ир-ат дуслар белән генә уртага салып сөйләшә торган темалар бар, уртак мавыгулар дигәндәй.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?

– Детальләренә кадәр хәтерләмим дә инде. Теге, киноларда күрсәтелә торган романтик шартларда булмагандыр ул дип кенә беләм. Булачак тормыш иптәшем белән танышып, ел ярымнар тирәсе очрашып йөргәннән соң ясадым мин ул тәкъдимне. Фидания – Кукмара кызы, Казан авыл хуҗалыгы институтының икътисад бүлеген тәмамлаган. Әмма шунысын ачык беләм: йөри башлагач та, әллә Кукмара Казанга якынрак булганга, башта алар ягына кайттык, аннан соң гына безгә – Әлмәткә кайтып килдек.

Ярату ул күздән, хис-тойгылардан, кылган гамәлләрдән үк күренеп тора, аны исбатлап тору кирәк тә түгелдер. Шуңа күрә минем тәкъдим сөйгәнем өчен дә әллә ни зур яңалык булмагандыр.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Андыйлар да бардыр, әйтә алмыйм. Әмма мин үзем алай сайламадым. Тик булачак тормыш иптәшемне алып кайтып күрсәткәч, әтигә дә, әнигә дә ошаганын яхшы беләм. Әти Фиданиягә «килен» дип түгел, «кызым» дип дәште. Чөнки ул төс-кыяфәте белән минем апа-сеңелләргә бик охшаган. Җәйге ялларга кайткан вакытта үзе генә суга яки кибеткә барса, кайбер авылдашларым аңардан: «Син Хәмидулланың кайсы кызы соң әле?» – дип сорыйлар иде.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар... Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Гадәттәгечә тотарга тиеш. Бүген хатыннары ирләреннән күбрәк хезмәт хакы алган гаиләләр бар гына түгел, бик күп. Әмма бу бит ир кеше булдыксыз дигәнне аңлатмый. Килешәм, андыйлар да бардыр, әмма гаиләдә икең дә җигелеп тартканда, мондый аерма сизелми дә.

9 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта.

– Әгәр ир-ат үзе дә менә дигән буй-сынлы, булдыклы икән – куркытмый торгандыр. Булдыксыз, җебегән, мәхлүк ирнең хатыны чибәр икән, монда инде ул ир тарафыннан көнләшү, үзен бераз кимсетеп тоту кебек гадәтләр барлыкка килергә мөмкин.

10 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Алар бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

– Җавап бит сорауның үзендә үк яшеренгән. Әгәр Аллаһы Тәгалә ир-атны һәм хатын-кызны бер үк төрле итеп яратса, яшәүнең бер кызыгы да калмас иде. Ир-атның мантыйгы аның үзе кебек бик гади, ә хатын-кызныкы бераз катлаулырак, серлерәк дип уйлыйм.

11 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңлаумаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен, үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Тулаем алганда, үзара килешеп, киңәшеп яшибез без. Тик бөтен гаиләләрдәге кебек, фикер каршылыклары килеп чыккан, аңлашмаган чаклар да булгалый. Әйтик, кыз белән малай икесе дә мәктәптә укый башлагач, хатыныма: «Әйдә, өченчесен дә алып кайтыйк инде», – дип тәкъдим ясаган идем. Риза булмады. «Үстерергә көч җитмәс», – диде. Хатын-кызның кайбер нәрсәләрнең ахырын алдан ук начарга юрап куюын берничек аңламадым инде мин. Сәбәбе дә юк бит! Ул да биш балалы гаиләдән, мин дә. Инде кем әйтмешли, тормыш та күпмедер дәрәҗәдә җайга салынган, балалар да матур гына үсеп киләләр – энекәшләрен яки сеңелкәшләрен карауда ярдәм итәрләр иде. Хәзер үкенә әнә...

12 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез? Үзегезнең хаклы булуыгызны исбатларга тырышып карыйсызмы, әллә инде юл куясызмы?

– Күп очракта юл куям. Әгәр мин хаклы булсам да, ул әле шул мизгелдә генә үзенең ялгышын танымаска мөмкин. Ә ялгыш иртәме-соңмы барыбер күренә бит ул. Гомумән алганда, хатын-кыз белән бәхәсләшү, аның хаксызлыгын исбатларга тырышу юк әйбер дип саныйм.

13 Шундый очракны күзаллыйк әле: арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым, дип, диванда кырын ятып тора.

– Мондый очракта мин тиз генә үзем берәр нәрсә пешерер идем. Безнең өйдә шундый язылмаган канун яши: кем эштән иртәрәк кайта, ашарга шул пешерә башлый. Атна уртасында мондый «бәхет» күбрәк миңа эләгә. Ә шимбә-ял көннәрендә хатын пешерәнә инде. Ашын да әзерли, өчпочмагын, бәлешен, пилмәнен дигәндәй. Гомумән, мин үзем балыкны, бәрәңгене, шашлыкны өйдәгеләргә караганда әйбәтрәк кыздырам дип саныйм. Токмач яки ярма салмыйча, бәрәңге генә турап, итле шулпа пешерергә дә яратам. Ә кафеда туклану мәсьәләсенә килгәндә, өйдәнерактарак булганда, ачыксаң, кафега да керергә туры килә инде. Тик барыбер өйдә үзең пешергән ризык тәмлерәк!

14 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

– Хатынны мактарга ярамый дисәләр дә, мактыйм әле: мондый хәлнең булганы юк. Ә менә минем бер дустымның хатыны: «Унбиш минуттан чыгам», – дип әйтеп тә чыкмагач, машинасына утырып Казаннан Башкорстанга кадәр үзе генә кайтып киткән иде. Шул очрактан соң хатыны ник бер тапкыр соңга калсын! Хатыннар бит алар берәр җиргә барасы булса, ашарга пешереп яисә кер юып соңга калмый, ә бизәнеп тоткарланырга мөмкиннәр. Минем хатын ул яктан уңайлы: озак бизәнми һәм сайланып торырга 15-20 күлмәге дә юк. Дөресен генә әйткәндә, соңгы вакытта бергәләп кино-театр, концертларга да барган юк, хатын-кыз, гадәттә, шундый җирләргә барганда озак бизәнә бит...

15 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Инә дә бүләк, дөя дә бүләк дигән кебек, мин үзем, нәрсә бүләк итсәләр дә, шатланам гына. Монда бит эш бүләктә түгел, ә сиңа күрсәтелгән игътибарда, хөрмәттә. Үзем дә башкаларны кечкенә генә булса да бүләк биреп шатландырудан ниндидер канәгатьләнү хисе, шатлык алам.

Соңгы вакытта хатыным, балдыз-сеңелкәшләрем туган көнемә яисә 23 февральгә күлмәк, футболка, оекбаш, ислемай кебек гел кирәк әйберләр генә бүләк итәләр. Ә кирәкле әйбернең ошамаганы булмыйдыр инде аның.

PRESSA.RU

ҺАВА ҠЕБЕК ЙОМШАК

Россиядә гомер-гомергә мех яраталар. Элегрәк һәр даирәнең үз мехы да булган хәтта. Сәүдәгәрләр — кондыз, дворяннар кеш, сусар, тиен тиресеннән тегелгән туннарны хуп күргән. Бу өлкәдә без чит илләрдән һич тә калышмыйбыз, Armani, Fendi кебек исемле җитештерүчеләр кулланган заманча технологияләр белән бергә атлыйбыз. ЭКСПО Милан-2015 кысаларында узган Италия—Россия форумында, шулай ук Мәскәүдә узган көз-яз-2015 Мода атналыгында Татарстан кызы Маша МОРОШЕК та катнашты. Бизнесына да, үзенә дә зур бәя бирә торган факт бу. Каян килеп чыккан исем соң әле ул? Аны кем һәм нәрсә таныткан? Безгә нилләр тәкъдим итә ала? Җир йөзендә киенеп-ясанып йөрергә яратмаган хатын-кыз юктыр ул. Матур кием игътибарны гел җәлеп итеп тора. Ә инде кием яхшы мехтан да тегелгән булсамы! Алып кия алабызмы-юкмы, кышкы мода тенденцияләре белән сезне дә таныштырасы иттек.

Маша Морошек белән танышканнан соң, мин аның нык ихтыярлы, үз юлыннан тайпылышсыз баручы кеше булуын искәрдем. Нәкъ менә Маша кебекләр зур уңышларга ирешәләр дә инде. Чөнки танылу өчен талантлы булу гына аз – сәләтеңне үстерү, дөньяга күрсәтү өчен гел эшләргә, эзләнергә, яңа үрләр яуларга кирәк. Мария Морошек үзен-үзе үстергән шәхес. Бервакыт ул үзенә килешсез тун ала. Шул тунны үз зәвыгына яраштырып кабат текkәнннән соң, аңарда мех белән ныклап торып шөгыльләнү теләге уяна. Шул көннән

Бу юлы модель булырга чибәр һәм мөлаем Лиана Сәетованы чакырдык. Ул Туризм буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты рәисе урынбасары, «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе.

РЕКЛАМА

Маша кешеләргә җылылык, шатлык, сыйфат һәм рәхәтлек бирүче мех киемнәр белән мавыгып китә. Мехны тукыма, күн, төрле аксессуарлар һәм башка төрле кызыклы детальләр белән яраштыра белү, шул рәвешле заманча образлар тудыру сәләте дә ул – талант!

Маша командасы кием-салым теккәндә үзгә технология белән эш итә. Бу технология шактый авыр һәм начар сузылучы җәнлек тиресен дә өрфиядәй җиңел һәм дулкынланып торган кебек итә. Алар тылсымлы, алар күпереп тора, алар сулый. Маша Морошек стиле – үзен үзгәртү турында хыялланган ханымнар өчен.

Тун сайлый һәм тунны башкалар кызыгырлык итеп киеп йөри беләбезме соң? Барлык хатын-кызлар да уңай җавап бирер дип уйламыйм. Чын мехтан булган тун арзанлы кием түгел, кеш тиресеннән тегелгән тунны һәркем дә сатып ала алмый. Әмма арзан мехлы туннар да сезне шундый итеп күрсәтергә сәләтле ки, нинди гүзәл, дип, күз явын алырлык! Мехтан тегелгән киемнәр сайлаганда гади генә берничә кагыйдә бар. Яшь-яшь кенә кызларга чәшке тиресеннән тегелгән туннар сайламаска кирәк. Яшьләргә катлаулы фасондагы, төрле җәнлек тиреләрен бергә яраштырып тегелгән киемнәр килешле була, ә менә урта яшьләрдәге ханымнарга андый туннар бик килешми дә.

Чәшке, кеш, сусар, ак төлке, төлке – болар хатын-кызларга килешә торган мехлар. Эре сөякле, тулы гәүдәле ханымнарга ак төлке, төлке, кара төлкенең йөнтәс мехыннан тегелгән киемнәр отышлы түгел. Алар гәүдәне тагын да тулырак итеп күрсәтә. Үз төсеңне дөрес сайлый белү дә бик мөһим. Әгәр дә җылы төсләргә өстенлек бирәсез икән, сезгә табигый төсләр – көрән, җирән, кызгылт көрән мех киемнәр килешәчәк. Әгәр дә инде тиенкы төсләрне яратасыз икән, кара, көлсу, зәңгәрсу мехлар – сезнең өчен. Мода тудыручылар ясалма мехтан, синтепоннан тегелгән куртка, пуховикларны никадәр генә мактасалар да, мехтан тегелгән киемнәр беркайчан да өстән төшмәс. Бездәге салкын климатта мех киемсез булмый да. Никадәр генә кыйммәт булмасын, кешеләр нәкъ менә мехтан тегелгән кием сатып алырга тырыша. Мех кием тиз генә тузмый, һәм аны алыштырырдай башка төрле тукыма әлегә уйлап табылмаган да.

Россиянең үзендә мех киемнәр тегелүгә карамастан, сыйфатлы мехлар Италия һәм Грециядән кайтарыла. Хәер, соңгы елларда Канадада тегелгән туннарга да тел-теш тидерерлек түгел. Мех базарына әле Кытай да килеп керде. Россия базарын уртакул мех киемнәр белән тәэмин итә ул. Бүген исә гардеробында тун эленеп тормаган бер гаилә дә юктыр.

Маша Морошек ачкан мода йортының нигезендә – оригиналь лекало белән киселгән, халыкның күпчелеге ошатырлык һәм сатып алырлык югары сыйфатлы мех киемнәр тегү идеясе ята. Мех киемнәр нәкъ менә урта яшьтәге ханымнарны аеруча затлы, бай һәм зәвыклы итеп күрсәтә.

P. S. Бу санның тышлыгын төшерүдә күрсәткән ярдәмнәре өчен рәхмәтебезне белдерәбез.

Рәмзия КАШАПОВА

Киңәш.

Тунны ничек сайлау, ничек саклау серләре турында Маша МОРОШЕК киңәшләре:

■ Мехның кыйммәте аның куелыгы, озынлыгы, йомшаклыгы һәм елкылдавы белән билгеләнә. Сыйфатлы мехны төсенә, куелыгына һәм йомшаклыгына карап бик җайлы аерырга мөмкин. Тунның тискәре ягына карап тиреләрнең сыйфатын, мәйданын, җөенең чыдамлыгын ачыкларга мөмкин. Югары сыйфатлы мехка һәрвакыт клеймо сугалар. Ярлыгы булу да мәҗбүри.

■ Мех салкынны ярата. Шуңа да мех киемнәрне 2 градустан алып 6 градуска чаклы салкын урында саклыйлар.

■ Туннар саклана торган бүлмәдә дымлылыкның да тиешенчә булуы шарт. Иң яхшысы – 40–65% тан ким булмасын. Коры һавада тире кибүчән. Кояш нурлары кирәгеннән артык яктылык та мех өчен файдалы түгел. Кояшта аның төсе уңа, сыйфаты китә. Мехны караңгы урында сакларга кирәк.

■ Ара-тирә туннарны салкынга чыгарып, җилләтеп алырга да онытмагыз. Мехта төрле бөҗәкләр үрчемәсен, көя төшмәсен өчен туннарны ара-тирә 5–10 градус салкынга чыгарып элəләр. Агулы препаратлар белән эшкәрткәнче, паразитлардан бу рәвешле котылу күпкә отышлырак. Моның өчен гап-гади туңдыру камераларыннан файдаланырга да була.

■ Мех киемнәр иркен урын ярата. Мех «суларга» тиеш – шкафта һава йөрерлек булсын. Тунны, башка киемнәрдән 30–35 см ара калдырып, иңсәләргә элəләр, барлык сәдәфләрен дә каптыралар.



VOZDУХ Казан, Спартаковская урамы, 2 нче йорт, «Suvar Plaza» сәүдә-офис үзәге.

PRESSA.RU

Без исләр дөньясында яшибез. Һәрберебезнең үзе генә яраткан хуш исе бар. Көндәлә якты хисләр кабызган ул ис сине гел озатып йөрсә, яхшы да бит. Әмма хушбуй сөртсәң дә аның исе бер-ике сәгатьтән очып бетәргә мөмкин. Бүгенге мастер-классыбыз хуш исләргә багышланган — ислемай ясарга өйрәнербез. Гади ислемай түгел. Бу — түгелми торганы, гел үзең белән йөртә торганы! Кайбер исләрнең хасияте турында да сөйләшербез. Тиздән Әниләр бәйрәме. Әле вакыт бар, без өйрәткән бу хушбуйны әниләрегезгә үзегез ясап та бүләк итә аласыз.



Мастер-классны Лилия ГӘРӘЕВА үткәрә.



КОРЫ ИСЛЕМАЙ







Кирәк:

- чиста балавыз (кәрәзне эретеп, кайнар килеш тукыма аша сөзеп чистартырга мөмкин);
- иссез үсемлек мае (бәдам, жожоба, йөзем...) Без исә өрек мае кулландык;
- хуш исле эфир майлары;
- әзер хушбуйны салу өчен кечкенә матур савыт (буш медальоннар кулай);
- шприц.

Эш барышы:

■ чиста балавызны вак угычтан уабыз. (Кәрәзне эретеп, балавызны үзегез ясарга уйласагыз, аны кайнар килеш бер савытка сөзеп, катырып алырга кирәк булыр.) Бер аш кашыгы уылган балавызны пыяла яки балчык савытка салабыз. Тимер савыт кулланырга ярамый, чөнки балавызга тимер исе сеңеп, хушбуебыздан да шул ис килеп торачак.

■ Уылган балавызга аш кашыгы ярым өрек мае өстибез. Әйткәнебезчә, башка төрле май да кулланырга мөмкин – исле генә булмасын. Андый майларны даруханәләрдән таба аласыз.

■ Балавызлы савытны суга утыртып, утка куябыз. Микродулкынлы мичтә генә дә эретергә була. Игътибарлы булыгыз: балавызлы савытка су кермәсен!

ХУШ ИСЛӘРНЕҢ ҮЗ СЕРЕ

Теләсә кайсы иҗат эше кебек үк, хушбуйларның да үз кәефе бар. Хушбуйлар өч төрле искә таянып ясала – «баш», «йөрәк», «нигез» дип йөртәләр бу исләрне парфюмерлар. Барлык хушбуйлар да шушы кагыйдәгә буйсына.

Борынга иң беренче булып бәрелүче исләргә хушбуйның «башы» дип әйтәләр. Болар – үтә дә җиңел эфир майлары. Кибеттә хушбуй сайлаганда, без нәкъ менә шушы исне үз итәбез.

«Баш» исләргә әфлисун, рәйхан, бергамот, вербена, лиметта, лимон, мандарин, нероли, бөтнек исләре керә.

Хушбуйның «йөрәге» – һавага озаграк таралучы исләр. Үзегезнең дә игътибар иткәнегез бардыр. Бик ошатып сатып алган хушбуй кичкә таба бөтенләй башка төрле ислегә әйләнә. Димәк, «баш» ис очып беткән, хәзер сез хушбуйның «йөрәген» тоясыз. Болар инде бераз авыррак эфир майлары: чабыр үләне (тимьян), яран, иланг-иланг, иссоп, мирт, лимон бөтнеге (мелисса), кипарис, артыш (можжевельник), мөшкәт исле шалфей, шалфей, лаванда, мөшкәт чикләвеге, бәбрия (розмарин), алма үләне (ромашка), пальмароза.

Тәнгә сөрткәннән соң иң озак саклanучы исләр хушбуйның «нигезе» була, диләр. Болар бик тотрыклы эфир майлары. «Нигез» исләргә ясмин, роза, сандал, роза агачы, канәфер, пачули, эрбет (кедр), ваниль, имбир, мирра, дарчин, кассия, ладан, шәрык тәмләткечләре һәм шәрык җимешләре исе керә.

Нинди исләрнең ошаганын ачыклар өчен, чиста кәгазьдән тар тасмалар кисеп, һәр тасмага 1 тамчы эфир мае тамызып чыгалар. Кайсы иснең кайсы майныкы икәнен бутамас өчен гади карандаш белән исемен дә язып куярга кирәк.

Иң әүвәл хушбуйның «йөрәге» табылырга тиеш. «Йөрәк» майлары тамызылган кәгазьләрне берәм-берәм иснәп, күңелегезгә хуш килгәнен сайлагыз. Бер түгел, берничә майны да бергә кушарга мөмкин.

Киңәш: майларны 1:2:3 нисбәтендә куллану отышлы. Хушбуйның «башы» булган май 1 өлеш алынса, «йөрәге» – 2 өлеш, «нигезе» 3 өлеш кирәк. Бергә кушылган майларны тукыма кисәгенә тамызып, кичкә кадәр калдыралар. Кичкә хушбуйның исе тәмам ачылачак. Ошаса, майларның күләмен арттырырга була.

- Әнис исе – күңелле, баллы, җылы.
- Әфлисун – яңгыравык, җиңел, салкынча, якты, чак кына баллы.
- Рәйхан – әчкелтем, хуш исле, бөрештергеч.
- Бергамот – әчкелтем-бөрештергеч, серле, нечкә.
- Ваниль – җилкендергеч, нәфис, баллы, җылы.
- Вербена – үтә нәфис, саф, бөрештергеч.
- Канәфер – ачы, җылы, бөрештергеч, айныта торган, ачык.
- Яран – сусыл, әчкелтем, майлы, нәфис, җылы, бөрештергеч.
- Ясмин – затлы, тере, нәфис, җиңел, чак кына салкынча, тыныч, йомшак.
- Иланг-иланг – тирән, ягымлы, җилкендергеч, баллы, җылы.
- Имбир – үткен, әчкелтем, җылы, экзотик.
- Эрбет – әчкелтем, саф, сумала исле.
- Лаванда – саф, җиңел, нечкә, салкын.
- Лимон – әчкелтем, саф, салкын.
- Мандарин – күңелле, ачык, майлы, салкынча, якты, баллы.
- Мелисса – әчкелтем, саф, җиләс, салкын.
- Мимоза, ак сәрви, шомырт, юкә – артык баллы.
- Артыш – саф, сумала исле, әчкелтем.
- Бөтнек – күңелне күтәрә, саф, нечкә, салкын.
- Пачули – әчкелтем, сумалалы, җилкендергеч, тәнге.



■ Эрегән балавызга бер-бер артлы хуш исле майларны кушабыз. Иң элек – «йөрәк», аннан – «нигез», ахырдан гына «баш» ис кушыла. Безнең очракта хушбуйның «йөрәге» – 5 тамчы иланг-иланг, «башы» – берәр тамчы әфлисун белән бергамот, «нигезе» – 7 тамчы ясмин мае; берәүгә ошаган икенче кешегә ошамый, шуңа күрә күңелегезгә хуш килгән исләрне сайлагыз. Майларны кушканнан соң, балавызны нечкә таякчык белән болгатабыз.



■ Әзер хушбуйны буш шприцка суыртып, кечкенә матур савытка агызабыз. Җәһәтрәк эш итмәсәң, балавыз бик тиз ката. Катып китсә, балавызлы савытны кайнар суга утыртып, кабаттан эретеп алырга була. Хушбуй саклanасы савыт белән шприцны да бераз җылытып алсаң, эшләве җиңелрәк.

■ Хушбуйның исе берәр атнадан соң гына – исләр бер-берсе белән тәмам «дуслашкач» кына тулысынча ачылып бетә. Яраткан исегез хәзер инде гел үзегез белән булачак! Хушбуйны медальонга салган булсагыз, аны хәтта тәнгә дә сөртәсе юк, хуш ис кирәк кадәр генә үзе таралачак.

PRESSA.RU

29 ноябрь — Әниләр көне. «Артур—Марат дуэты» егетләре (Артур Минһаҗев һәм Марат Галимов) бәйрәм табынына бик тәмле торт әзерләргә өйрәтмәкчеләр. Аны әзерләү өчен хәтта мич тә кирәк түгел. Махсус шушы тортны сайлаган егетләр: «Әле мич кабыза белмәүче мәктәп укучысы да үзенең әнисенә сюрприз ясый алсын, дип уйладык», — диләр. Дуэт үзе яңа гына оешса да, Артур белән Марат тамашачыга күптәннән таныш. Элгәре «Казан егетләре» төркемендә җырлады алар. Дуэтның иҗат юлы бик өметле күренә. Бу мастер-классны төшергән көннәрдә дә егетләр яңа җырлар яздыру белән мәшгуль иде. Уңышлар телик без аларга. Ә егетләр әзерләгән торт искиткеч тәмле килеп чыкты. Сез дә әзерләп карагыз әле. Әниләрегезгә бер сюрприз булсын!



БАНАНЛЫ ТОРТ







Кирәк:

- 0,5 кг печенье (уалыбрак торганы яхшы).
- 6 банан;
- 2-3 шәфталу (аны башка җиләк-җимеш белән дә алыштырырга була);
- 2 әфлисун;
- 1 лимон;
- 10 данә кара карлыган (катырылганы да ярый, компоттан алсагыз да була);
- 2 кап шәфталу желесы;
- 1 кап җиләк желесы;
- 2 аш кашыгы атланмай;
- төбе алына торган таба (андый табагыз булмаса, гадәти табаны да кулланырга мөмкин).

Эш барышы:

■ Әфлисуннарны яхшылап юып, урталай кисәбез һәм тирәнрәк берәр савытка сутын сыгабыз. Сут сыккычыгыз булса, бигрәк тә уңай.

■ Печеньеларны берәм-берәм шушы сутка манып, таба төбенә ике кат түшибез. Табаның төбе күмелсен.

■ 5 бананның кабыгын чистартып, ваклап турыйбыз. Бананны тирән эчле савытка салып, ярты лимоннан сыгылган сутны өстибез һәм блендер белән бик яхшылап издерәбез. Блендер булмаганда тукмак белән төяргә мөмкин. Изелгән бананны табадагы печенье өстенә бушатабыз.

■ Кәстрүлгә ярты стакан су салып, кайнатып чыгарабыз, атланмай өстибез. Су чак кына суынгач, 2 кап шәфталу желесын салабыз, шикәре эреп беткәнче, бик яхшылап болгатабыз. Шушы сыеклыкны банан өстенә коябыз һәм табаны 2-3 сәгатькә суыткычка куеп торабыз. Озак көтәргә вакытыгыз булмаса, ярты сәгатькә генә туңдыру камерасына куеп алырга мөмкин.

■ Калган бер бананны кабыгыннан чистартып, юка гына тәгәрмәчләп турыйбыз. Шәфталуны исә ярым тәгәрмәчләп турарга кирәк. Шәфталу урынына хөрмә кулланырга була.













Фото: Ксения Богданова

Банан гына тезеп чыксагыз да ярый. Монда инде кем нинди җимеш ярата, шуны куллана ала, фәкать каты җимешләр генә булмасын.

■ Туралган банан белән шәфталуны торт өстенә матурлап тезәбез. Араларына кара карлыган тезеп чыгабыз.

■ Тулыр-тулмас 1 стакан суны кайнатып, шунда җиләк җелесын салабыз. Шикәре эреп беткәнче, яхшылап туглыйбыз. Чеметеп кенә кызыл ризык буявы кушарга мөмкин.

■ Желены торт өстенә коеп, янә суыткычка тыгабыз. Инде безгә желеның куерганын гына көтәсе калды. Шулай да, бу торт икенче көнне аеруча тәмле була икән. Шуңа күрә аны бер көн алдан ясап куйсагыз яхшырак.

Дөньядагы иң газиз кешеләребез – Әниләр көне белән котлыйбыз сезне!

Бәйге



Аш-су конкурсыбыз дәвам итә. Чираттагы катнашучыбыз — Зәй шәһәрендә яшәүче Марина ДМИТРИЕВА «Кунакларны шаккаттыр!» дип аталган бик тәмле ризык тәкъдим итә. Марина ханым үзе балалар бакчасында музыкаль хезмәткәр булып эшли. «Аш-су әзерләгәндә җаным ял итә, илһамым уяна», — ди ул. Аның хәтта үзенең рецептлар сайты да бар. Белгәнен башкалар белән дә бик рәхәтләнеп уртаклаша.

Кирәк

(ике кеше өчен):

- 500 г тавык түше;
- 2 кишер;
- 2 баш суган;
- 1 кызыл болгар борычы;
- 1 сары болгар борычы;
- 1 аш кашыгы кукуруза мае;
- 1 йомырка;
- 3 чәй кашыгы горчица;
- 3 чәй кашыгы көнҗет орлыгы;
- тоз-борыч;
- 1-2 сабак петрушка.

Эш барышы:

■ Уңайлык өчен тавык түшен чак кына катырып алабыз һәм юка гына катламнарга бүләбез.

■ Һәр кисәккә горчица ягабыз, тоз-борыч сибәбез.

■ Кишерне – саламлап, суганны ярым боҗралап турыйбыз.

■ Яшелчәләрне кукуруза маенда кыздырабыз.

■ Йомырканы бер савытка сытып, күпертәбез.

■ Артык зур булмаган турыпочмаклы табаның төбенә фольга җәябез. Чит-читләре таба кырыеннан чыгып калырлык булсын.

■ Фольга өстенә бер-берсенә терәп, тавык түшләрен тезеп чыгабыз. Иткә күпертелгән йомырканы ягабыз. Аның өстенә кыздырылган яшелчәләрне салабыз. Ит катламнарының чите яшелчә астыннан чыгыбрак торсын. Тагын бер кат ит тезәбез. Ризыкларны шулай чиратлаштырып, берсе өстенә икенчесен салабыз. Иң өске катка йомырка сылыйбыз һәм көнҗет орлыгы сибәбез.

■ Бу ризык 200 градус кызулыктагы мичтә 40-50 минут пешә. Пешкәч, астындагы фольгасын читеннән тотып тартып алабыз. Таба төбендәге шулпасын түгәбез. Ризыкны зур яссы тәлинкәгә күчереп, петрушка һәм мүк җиләге белән бизибез.

Искәртәбез: бәйгегә тәкъдим ителгән ризыкларда «Пестречинка» ҖЧҖ продукциясе файдаланырга тиеш.

PRESSA.RU



ХАТЫН-КЫЗ ЙӨРӘГЕ



2015 ел Татарстанда йөрәк һәм кан тамырлары авыруларына каршы көрәш елы дип игълан ителде. Журналыбызны укучыларга медицинаның бу җитди өлкәсе, бигрәк тә хатын-кыз йөрәге хакында мәгълүматыбызны киңәйтүне үтенеп, югары категорияле табиб Анна СЕМЕНЫЧЕВАга мөрәҗәгать иттек.

Уяу булыгыз

Элегрәк климакс яшенә кермәгән хатын-кызларга йөрәк җәһәтеннән борчылырга сәбәп юк, аларны махсус гормоннар – эстрогеннар саклый дип уйланыла иде. Фәкать 50 яшьләр тирәсендә генә аларның инфаркт алу ихтималы ир-атларныкы белән тигезләшә иде. Ләкин хәзер инфаркт куркынычы ун елга иртәрәк ишек шакый. 40 яшь тулып килгәндә организмда гормоннар нисбәте үзгәрә. Һәм хатын-кыз, ирләр кебек үк, хәвеф зонасына эләгә. Шулай итеп, табигать тарафыннан салынган саклык чарасы йомшара, тик менә еллар дәвамында ваемсызлыкка иялөшкән хатын-кыз гына яклаучысыз кала. Хәтта ки кайбер табиблар әле

һаман йөрәк авырулары ирләр өчен генә хәтәр ул дип саный.

Йөрәк өянәге була калганда хатын-кызларда үлем-китем очрагы ешрак күзәтелә. Миокард инфаркты булганнан соңгы бер елда хатын-кызлар бер ярым тапкырга күбрәк үлә.

! 40 белән 50 яшь арасындагы хатыннарда миокард инфаркты яки башка төрле йөрәк-кан тамырлары авырулары килеп чыгу тагын бер сәбәп аркасында игътибарсыз кала. Бу сәбәп — йөрәк саусызлыгының климакс вакытындагы билгеләр белән бик тә охшаш булуы.

Хатын-кызларга еш кына «климакс вакытындагы «невроз», «дисгормональ кардиопатия», «дистония» кебек диагнозлар куела. Югыйсә җентеклерәк тикшерү уздырганда аларда ишемия билгеләре табылыр иде. Нәкъ шул яшьләрдә хатын-кызлардагы инфарктның билгеләре гадәтидән аерылыбрак тора.

Сарык тиресе ябынган бүре

Диагноз куючы табибка авырту булганда диагноз кую җиңелрәк. Ләкин бу очракта авыртуның күкрәк һәм йөрәк тирәсендә туплануы мөһим. Гадәти стенокардия өянәгеннән аермалы буларак, авырту бик көчле була. Әгәр дә авырту урыны үзгәреп тормый, ягъни ул сул кулга, калак сөяге тирәсенә, җилкәгә бәрә икән, бу очракта диагноз ачык. Авырту уң кулда яки ике кулда да, ике калак сөяге арасында, аскы теш казналыгы, муен тирәсендә, сул аякта сизелә икән, диагноз кую озаккарак сузыла. Инде килеп, шушы билгеләр булып та, йөрәк үзе авыртмаса, йөрәк өянәген артрит, остеохондроз, яңак нервысы ялкынсыну белән бутарга мөмкиннәр.

Кайвакыт йөрәк саусызлыгы астма рәвешен алырга да мөмкин. Әгәр сез башкалар зарланмаган вакытта бинада һавасызлыктан буыла башлыйсыз икән, бу хакта табибка хәбәр итәргә ашыгыгыз.

Байтак очракларда инфаркт алды халәте ашказаны чире, агулану, гастрит, ашказаны җәрәхәте рәвешендә күзәтелергә мөмкин. Күңел болгану, эч китү, косу, кикерү, эч күбү кебек билгеләр була. ЭКГның үзгәрешләре панкреатит кискенләшкән вакыттагы кебегрәк булучан. Ике очракта да лейкоцитлар саны нык артып китә.

Миокард инфаркты булганда еш кына баш миендәге кан әйләнеше бозыла. Бу очракта кеше аңын җуя. Һушын җуяр алдыннан ул хәтта косып җибәрә, аның башы әйләнеп китә. Аңына килгәч, кеше үзе белән ни булганын аңламый тора, тирән хәлсезлек кичерә. Хәтта җиңелчә генә һуштан язу очрагы хакында да табибка хәбәр итү зарур. Бу халәт тиз арада тиешенчә бәяләнергә тиеш. Стенокардия өянәге булу ихтималы да бар бит. Һәрхәлдә, җентекле тикшеренү узарга кирәк.

Хәтта барысы да аңлаешлы кебек тоелганда да диагноз куюда ялгышлар булгалый. Күп вакыт ялгышлар авыру кешенең түземлеге, ваемсызлыгы аркасында, аның «узар әле», «әлек тә мондый хәлләр булгалый иде» дип үзен дә, табибларны да тынычландыруы сәбәпле килеп чыга. Табибны еш кына үз гомере өчен җан тырмашып көрәшергә тиешле хатын-кыз буташтыра.

! Табибка саусызлыкның билгеләрен тасвирлаганда «әллә ни булды әле миңа» дип тормагыз, ә кай төшегез авыртканны ачык итеп әйтеп бирегез. «Йөрәк тирәсендә авырту бар», «күкрәк, җилкә тирәсе кызыша» кебегрәк әйтеп, конкрет урынны күрсәтегез.

Йөрәк тирәсендәге авырту һәрвакытта да йөрәк-кан тамырлары авырулары белән бәйле булмаска мөмкин. Кардиалгия – бүре тиресе ябынган «сарык» кына ул. Кардиалгия – миалгия, остеохондроз, йөткылык кысылганда, бөерләр кадаганда, ашказаны җәрәхәте ачылганда да күзәтелә. Бәхеткә күрә, бу төр чирләр миокард инфарктына карaганда ешрак очрый. Шуңа күрә һәр «сарык»ны да «бүре»гә санарга ярамый.

Күп кенә очракларда миокард инфаркты башланыр алдыннан стенокардия өянәкләре ешая һәм авыррак уза башлый. Күкрәк читлегендә кысу, кызышу, өю кебек билгеләргә игътибарлы булырга кирәк. Хатын-кыз шундый кеше инде ул – йөрәк тирәсендәге моның ише сигналларга исе дә китми аның.

! Хөрмәтле хатын-кызлар, тагын бер тапкыр кардиологка барып кайтырга һич кенә дә иренмәгез. «Сәер билгеләр»нең гадәти ОРЗ гына булып чыгуы да бар анысы. Сезнең бурыч — йөрәкне саклап калу. Моның өчен даими рәвештә (35 яшьтән узгач, елга бер мәртәбә булса да) кардиограмма төшертеп алу. Әгәр сез стенокардия белән интегәсез икән, табибка аена бер мәртәбә күренеп тору бик мөһим. Онытмагыз: миокард инфарктының беренче билгесез уза торган очраклары да, сирәк булса да, күзәтелә. Аның якынлашуын фәкать бик җентекле тикшерүдән соң гына ачыкларга мөмкин.

Төгәллек – сәламәтлек сакчысы

! Йөрәк өянәге кузгалды дип шикләнәсез икән, поликлиникага ашыкмагыз. «Ашыгыч ярдәм» чакырыгыз да, урынга ятыгыз. Табиб килеп җиткәнче... аспирин кабып куегыз. Элек нитроглицерин киңәш итә идек, хәзер аңардан баш тарттык.

Өйгә килгән табиб сезнең кардиограммагызны алырга тиеш. Аннары ул сезне стационарга озатыр. Хастаханәдә канда инфаркт вакытында гына барлыкка килә торган махсус ферментлар булу-булмавын тикшерерләр, лейкоцитлар санына игътибар итәрләр.

PRESSA.RU

Сүз уңаеннан бер мисал китереп үтәсем килә. Рауза ханым төнлә ашказаны нык авыртканга уянып китә. Косасы килә. Аны ниндидер курку тойгысы биләп ала. Әнисенең дә инфаркты шулайрак башланганын исенә төшереп, ханым «Ашыгыч ярдәм» чакырта. Ләкин кардиограмма берни дә күрсәтми. Стационарда лейкоцитларга анализ шикле күренсә дә, кардиоферментлар үзгәрешсез чыга. Шуңа күрә Рауза ханымны гастроэнтерология бүлегенә күчерәләр. Ханым туганнарына шалтыратуларын үтенә. Туганнары ханымны махсус клиникага күчерәләр. Һәм бик вакытында! Чөнки җентекле тикшеренүләрдән күренгәнчә, коронар артерия тыгылган булып чыга. Бу ханымда әле генә инфаркт булганлыгы ачыклана. Вакытында чарасын күреп, инфаркт нәтиҗәләрен минимумга калдыру мөмкин була. Бер айдан ханым инде эшкә чыга ала.

Кызганыч ки, һәммә кешенең дә ярдәмгә атлыгып торган туганнары булмый. Ләкин һәр хатын-кыз организмда гормональ үзгәрешләр барганда кардиоферментларга тестның бик үк төгәл булмавын белеп торырга тиеш. Бәхәсле очракларда тестны кабатлауны сорагыз. Алай да булмаса, махсуслашкан клиникага күчерүне таләп итегез. Әгәр инде сездә чыннан да инфаркт икән, стационар шартларында исән калу ихтималы күпкә артыграк. Илнең танылган клиникаларында инфарктка шик булган чагында йөрәк-кан тамырларына коронографик тикшерү уздыралар. Бу вакытта аларда тромб булу-булмавы, булса, кайда урнашканлыгы ачыклана. Аннары турыдан-туры коронар артериягә тромбны эретә торган матдә кертәләр. Шулай эшләгәндә миокард инфаркты күләмле булып җәелми. Ашыгыч ярдәм күрсәтелгәндә, кан килмәү сәбәпле, йөрәк күзәнәкләре бик күп үлми. Димәк, тиздән пациент әйбәт кенә терелеп чыгачак. Кардиологлар арсеналында төгәл тикшерү үткәрү өчен бүтән төрле чаралар да бар. Әйтик, алар рентгенга төшергәндә ялтырап күренеп тора торган изотоплар кертеп, йөрәктә үлгән тукымалар булу-булмавын ачыклый алалар.

! Йөрәкне контрольдә тотуның тагын бер ысулы — йөрәк ритмын төгәл күзәтеп тору. Моның өчен берничә көн дәвамында кардиограмма төшереп торыла. Бу ысул бик күп гомерләрне саклап калды инде.

КИҢӘШ

ДОШМАН № 1 — ХОЛЕСТЕРИН

Әгәр ул нормадан күбрәк булса, йөрәккә янаган куркыныч бермә-бер арта. Иренмәгез, кандагы холестеринны тикшертеп торыгыз. «Начар» холестерин микъдарын белеп тору аеруча мөһим. Анализлар әйбәт түгел икән, майлы ризыклар ашамаска тырышыгыз. Бигрәк тә терлек майлары зарарлы. Актив хәрәкәтләнегез. Спорт белән шөгыльләнүче хатын-кызлар «ялкау»ларга караганда дүрт мәртәбә сирәгрәк авырый.

ДОШМАН № 2 — ЮГАРЫ КАН БАСЫМЫ

Нормада кан басымы 120/80 булырга тиеш. Аны үлчәп кенә торыгыз. Шушы ике санның берсе генә булса да өскә таба үрмәләсә, бу хакта үз табибыгызга әйтегез. «Гипертония» дигән диагноз куелган очракта гәүдә авырлыгын киметергә тырышыгыз, тозлы, майлы ашамагыз. Көнгә ике чакрым җәяү йөрү дә инфаркт ихтималын 25 процентка киметәчәк.

ДОШМАН № 3 — ТӘМӘКЕ ТАРТУ

Бөтен сәбәпләр бертөрлерәк булган чагында да тәмәке көйрәтүче хатын-кызларга куркыныч 2-4 мәртәбә ешрак яный. Тәмәкене ташлаган көннән куркыныч кими барачак һәм өч елдан соң ул тәмам юкка чыгачак. Дөресрәге, тәмәке тартмаган кешеләрнеке белән бер дәрәҗәдә булачак.

ДОШМАН № 4 — АЛКОГОЛЬ

Тормыш проблемаларын шешә ярдәмендә хәл итәргә тырышмагыз. Хатын-кызлар хәмердән ир-атларга караганда күбрәк зарар күрәләр. Даими рәвештә «каба» торган биш хатын-кызның икесе йөрәк-кан тамырлары системасы авыруларыннан интегә.

ДОШМАН № 5 — ДИАБЕТ

Шикәр авырулы кешеләр йөрәк чире белән башкаларга караганда 3-7 тапкыр ешрак авырыйлар. Бу куркынычны сызып ташлап булмый, әмма аны киметергә мөмкин. Моның өчен симермәскә, спорт белән шөгыльләнергә, диета сакларга кирәк.

ДОШМАН № 6 — НӘСЕЛДӘНЛЕК

Әгәр нәселегездә йөрәк чирле кешеләр бар икән, бу хәл сезнең табибны сагайтырга тиеш. Кемгә кемгә, ә менә сезгә табибка сукмак салырга кирәк. Сәламәт яшәү рәвеше сезнең өчен кагыйдәгә әйләнергә тиеш.

Битлеген салган дошманнардан тыш, әле тагын яшерен «дошманнар» да бар. Болар исәбенә психологик халәт, күңел төшенкелеге, аралашмый яшәү, дошмани хисләр тоткынлыгында булу кебек халәтләр керә. Ә бит күңел төшенкелеге кичереп яшәүче кешенең йөрәктән үлеп китү ихтималы шат күңелле кешенекегә караганда 3-4 мәртәбә ешрак. Күңел төшенке чагында мидәге серотонин матдәсенең микъдары нык кимеп китә. Шунлыктан кеше йөрәк чирләренә каршы тору сәләтен югалта.

Проблемаларыгызны хәл итәргә өйрәнсәгез, чиргә бирешмәссез. Табиб киңәшләре ярдәмгә килер. Дусларыгыз, җилкәсенә башын салып елап була торган якын кешеләрегез булу да бик әйбәт. Күз яшьләре белән бергә күңелсез уйларыгыз да агып китәчәк.


КУЧКАР. Айның беренче атнасы ниятләрне чынга ашыру өчен уңай вакыт. Бик тә перспективалы ай. Мөһим карарларны ай башында кабул итәргә тырышыгыз. Айның икенче яртысында кичектергесез эшләр килеп чыгарга мөмкин, әзер торыгыз.


ҮГЕЗБОЗАУ. Чып-чынлап тылсымлы ай булыр бу сезнең өчен. Нәрсә турында хыяллансагыз да, тормышка ашар. Шулай да бик үк иркенәеп китәргә ярамас. Эштә киеренкелек булуы ихтимал. Ел ахыры бит, барысына да өлгерергә кирәк.



ИГЕЗӘКЛӘР. Рухи киеренкелеккә, ыгы-зыгыларга әзер торыгыз. Үзегезне вулкан өстендә яшәгәндәй хис итәрсез. Шулай да йолдызбагарлар артыгын тынгысызланмаска куша. Тыныч булсагыз, күп кенә проблемалар бөтенләй дә көлке кебек кенә күренер.


КЫСЛА. Шикле гамәлләрдән, бәхәсләрдән сакланыгыз. Әгәр дә үзегезгә игътибар итүләренә өметләнәсез икән, ул фәкать сезнең тырыш хезмәтегез өчен генә булырга мөмкин. Ел ахырында нindидер бер кызыклы кеше белән очрашырсыз.


АРЫСЛАН. Бер яктан, көчегезнең артуын тоярсыз, икенче яктан, гел бер урында таптанган кебек тоелыр. Сезнең белән кызыксыналар, шуңа күрә гел формада булырга тырышыгыз. Нindидер мөһим мәгълүматны белми калуыгыз ихтимал, игътибарлырак булыгыз.


СӨМБЕЛӘ. Тормыш шартларыгызны яхшырту белән мәшгуль булырсыз. Планнар кору өчен яхшы вакыт. Ел башыннан ияреп килгән проблемалар җиңел генә хәл ителер. Өстәмә акча табу форсаты килеп чыгар.


БИЗМӘН. Тормышта үзләрен актив тотучылар өчен яңа капкалар ачылачак. Куйган максатларга бару юлы аерымачык күренер. Хезмәт баскычында үсү ихтималы бар. Ерак сәфәрләргә чыкмый торыгыз.


ЧАЯН. Сүзе үтә торган танышларыгызның ярдәмен тоярсыз. Үзегезне күрсәтү форсаты чыгачак. Дәрәҗәлерәк вазыйфага күчерүләре ихтимал. Тормышка аек күз белән карагыз, буш хыяллар корудан туктагыз.


УКЧЫ. Гел читкә куя килгән эшләрне тәгәлләми булмас. Кумәк башкарыла торган эшләрдә катнашмый торыгыз. Туганнар һәм җитәкчеләр белән очрашу өчен дә кулай вакыт түгел. Ә менә көнкүреш мәсьәләләре бик җайлы хәл ителер.


КӘҖӘМӨГЕЗ. Елны тыныч кына тәгәлләрсез. Әлегә зур вакыйгалар көтелми. Көчегезне бушка сарыф итүдән сакланыгыз, кирәге шуның кадәр генә кешеләр белән аралашмаска тырышыгыз. Ай ахырында оптимизмыгыз артачак.


СУКОЯР. Күңелле вакыйгаларга, кызыклы очрашуларга бай ай. Яхшы хәбәр ишеттерерләр. Тормышыгызда уңай үзгәрешләр булуы ихтимал. Яңа эшләр башлап җибәрсәгез, отарсыз. Хезмәттәшләрегез алдында дәрәҗәгез артыр.


БАЛЫКЛАР. Ирешкән дәрәҗәгезне саклау өчен нык кына тырышырга кирәк булыр. Теләкләрегезне мөмкинлекләрегез белән тәңгәлләштерсәгез, эшләрегез майлаган кебек барыр. Шулай да мөһим эшләрне ай ахырына калдырмагыз.

Ноябрьдә кабынган йолдызлар

Татарстан



Наилә Гәрәева (18.11.1940) – **Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты.**
Казанда туа. Качалов театры каршындагы студиядә белем алып, 1960 елда Камал театрына эшкә килә. Сәхнәдә тәүге башкарган роле – Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт» спектаклендәге Рәхилә. Бу әсәр авторның да, режиссер Рәфкать Бикчәнтәевнең дә (Наилә Гәрәеваның булачак ире) сәхнәгә куйган беренче спектакле була. Шуннан соң Наиләгә бер-бер артлы Ч. Айтматовның «Гүзәлем Әсәл»ендә – Әсәл (бу роле өчен артистка 1967 елда ТАССРның Тукай премиясенә лаек була), Ш. Хөсәеновның «Зөбәйдә – адәм баласы»нда – Зөбәйдә, Х. Вахитның «Рәхим итегез»ендә Зәйтүнә рольләрен тапшыралар. Ул әле дә сәхнәдә. «Зәңгәр шәл» (К. Тинчурин), «Бабайлар чуагы» (И. Зәйниев), «Яшь йөрәкләр» (Ф. Бурнаш) спектакльләрендә уйный.

Россия



Нонна Мордюкова (25.11.1925–6.07.2008) – **кино һәм театр артисты.**
Украинада туа. Артист булырга хыялланып үсә. «Богдан Хмельницкий» фильмында төп геройны уйнаган Николай Мордвиновка гашыйк булып, аңа хат яза. Мордвинов Мәскәүгә килергә һәм үзен эзләп табарга куша. 1945 елда Нонна Мәскәүгә килүен килә, тик актерны таба алмый. Бернинди әзерлексез ВГИКка укырга керә. Кинодагы тәүге роле – «Яшь гвардия» фильмында Ульяна Громова. Бу роль өчен аңа Сталин премиясе бирелә. 1950–1991 елларда «Киноактер» театр-студиясендә эшли. Иң соңгы эше – Денис Евстигнеевның «Әни» фильмы. Төрле елларда басылып чыккан өч китап авторы да әле ул.

Чит илләр



Вупи Голдберг (13.11.1955) – **актриса.**
Үз исеме – Кэрин. Вупи – тәхәллүсе. Нью-Йорк шәһәрендә туа. Сигез яшеннән экспериментал театр сәхнәсендә уйный. Актерлык осталыгына ул бары тик шушында гына өйрәнә. 1974 елга кадәр, Сан-Диегода яңа ачылган театрда эш тапканчы, каравылчы да була ул, кирпеч салучы да, моргта мәетләр киендерүче дә. 1983 елда «Өрәкләр тамашасы» дип аталган яңа проект оештыра. Ул куйган моноспектакльләрне режиссёр Майк Николс күреп ала һәм Вуппины Бродвейга чакыра. Актрисаның зур экранга юлы әнә шуннан башлана. Бүген ул «Оскар», «Грэмми», «Эмми», «Тони» премияләре иясе, Йолдызлар аллеясында аның исемендәге йолдыз бар.

PRESSA.RU





МИЛЛИ ҖӘҮҺӘР

Күкләр сафлыгын һәм кышкы көн аклыгын сурәтләп бирү аңа берни тормый! Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Бакый Урманче исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Равил Заһидуллин бу күренешләрне үзенең милли, тарихи романтизм юнәлешендә иҗат ителүче картиналарына һәрчак өсти. Әсәрләрендәге адәм балалары – үзе кебек үк тыныч холыклы, уйчан карашлы, салмак адымлы. Бер ише сабан белән җир сөрә, киек кош аулый; икенчеләре мәчеткә бара; өченчеләре Сабантуйда бил алыша... Сугыш баталияләре сурәтләнгән картиналар да яза рәссам, чөнки ул гомере буе борынгы Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы тарихы белән тирәнтен кызыксына, әлеге чорның тарихи вакыйгаларын өйрәнә.

Аның «Өйлә намазы», «Падишаһ авы» әсәрләре Россия Илбашы резиденциясен бизи, ә «Җомга» һәм «Болгар аучылары» картиналары Татарстан җитәкчелегенең шәхси коллекциясендә саклана. Күп эшләре Венгрия, АКШ, Франция, Төркия, Мисыр, Кувейт, Израиль, Нидерланд, Бөекбритания, Австралия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә шәхси тупланмалар буенча таралган. Чит ил сәяхәтчеләре рәссамның шактый картиналары белән Болгарда таныша. Күргәзмәгә килгән сәнгатьсөярләр аның яңа эшләрен һәрчак көтеп ала.


Соңгы елларда Равил Габделбәшир улы пыяла өслегенә шәмаил язу алымын кулланып, декоратив-гамәли әсәрләр иҗат итү белән мәшгуль. Алар – рәссам иҗатының иң кызыклы юнәлеше. Бүгенге көндә бик сирәкләр генә пыяланы шулкадәр сокландыргыч төгәл бизәкләү белән шөгыльләнә. «Моның өчен гаять зур сабырлык, чиктән тыш төгәллек һәм шулкадәр күп вакыт таләп ителә ки, ясап бетергәч, аларны инде һич кенә дә сатып җибәрәсе килми. Бу эшләрнең күбесенә, гадәттә, башка милләт вәкилләре игътибар итә», – ди оста. Алардагы купшылык, матур төсләр чишелеше аерым игътибарга лаек. Һәм бәһасез икәнлекләре бер караштан ук аңлашыла. Бу декоратив-гамәли әсәрләрне музей залларына берәм-берәм элеп куярлык! Иҗатчының әле үзен дә милли җәүһәр дип зурлау һич ялгыш булмас! Равил Заһидуллин тулысынча татар халкы тарихына мөкиббән булган, тырыш, фидакарь рәссам ул. Казанның меңьеллык юбилее уңаеннан иҗат ителгән башкаланың каллиграфик эмблемасын ирекле рәссам үзенчә чишкән: Казан – югарыда, хөрлек хозурлыгында очучы горур кош. Бу эмблема әле дә киң кулланыла.


«Хәзинә» милли сынлы сәнгать галереясының даими күргәзмәсенә куелган «Авыл мәчете белән шәмаил»е үзе генә дә ни тора! 1991 елда иҗат ителгән әлеге шәмаил катлы-катлы пыялалар тезеп ясалган! Казан сынлы сәнгать училищесын уңышлы тәмамлаганнан соң, олпат рәссам Бакый Урманче белән дуслашуын аерым җылылык белән искә ала ул. Бу чорда үзе дә берничә шәмаил язган.

Остаханәдә яңгыраган догалар рәссамга илһам бирә, ахрысы. Тагын бер кат диварлардагы картиналарны күздән кичерәм: бер якта – «Иске Таш мәчет» сурәте һәм тыныч илдәге кышкы ялан. Рәссамның кылкаләме чиста төсләрнең иген-чиген белми – ялан-кырда мең төсмерле аклык! Икенче якта – «Колһуаллаһ» язылган шәмаил. Хыял офыклары аны урта гасырларга алып китә. Киндерләрдә – йөзләрчә мәчетле Казан елмая, мәһабәт ханлык хакимлек итә!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА









РАВИЛ ЗАҺИДУЛЛИН

PRESSA.RU

Газета-журналга язылган өчен iPad!

1 **Язылыгыз**
30.12.2015 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә өч басмасына язылыгыз *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласыз).*

2 **Җибәрегез**
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәрегез *(телефон номерыгызны күрсәтергә онытмагыз)*: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт яки podpiska@tatmedia.ru

3 **Отыгыз**
Айпад, фотоаппарат һәм башка бүләкләр отарга ашыгыгыз!

Акциянең спонсоры

KUKMARA «КУКМАРА МЕТАЛЛ САВЫТ-САБАЛАР ЗАВОДЫ»

Kukmara

Сделано в России

2016 елның 12 феврале

БҮЛӘКЛӘР УЙНАТУ





Акцияне үткәрү вакыты: 1.11.2015–10.03.2016.
Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында.
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84, өстәмә номер – 1261.

16+
Реклама

«Сөембикә» журналына үз темагызны тәкъдим итегез һәм бүләк отыгыз!

Аның өчен журналыбызның 19 нчы битендәге анкетаны тутырып, 15 декабрьгә кадәр редакция адресына җибәрегез. Тулырак мәгълүмат www.syuyumbike.ru сайтында.